Эльмира Шәрифуллина

# Тамды яшем...

Шигырьләр, поэмалар

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2012

УДК 821.512.145-1
ББК 84 (2Рос=Тат)-5
Ш95

**Шәрифуллина, Э. М.**
Ш95 Тамды яшем... : шигырьләр, поэмалар / Эльмира Шәрифуллина. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2012. – ... б.
ISBN 978-5-298-02311-5

УДК 821.512.145-1
ББК 84 (2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-02311-5

с Татарстан китап нәшрияты, 2012
с Шәрифуллина Э. М., 2012

**Туар балам бишегендә**
**Туган илем ишеге…**

**Ата хакы, ир хакы**
*(Мөнәҗәт)*

Ата хакы – олы хак ул, белегез сез,
Ата хакын хаклау юлын күрегез сез.
Ата хакын хаклап яши өйрәнсәгез,
Рәхәт тормыш кичерерсез күбегез сез!

Ир-ат хакы – бик олы хак, белик шуны,
Ирле кеше җиңеп чыгар утны-суны.
Тәрбия итик ир баланы, ир-атаны,
Яшик гөрләп, тотынышып кулга кулны!

Ата-баба нигезләрен саклый белик,
Ата-баба хәтерләрен хаклый белик!
Угланыбыз Ата булсын, Бабай булсын,
Нәселебез ышанычын аклый белик!

**Хәерле нигез**

Өй алганчы, күрше сайла,
Хәерле нигез булсын.
Өегезгә имин тормыш,
Кояш нурлары тулсын!

Иманлы, имин нигездә
Ипле ул-кызлар тусын...
Һәрберсе нәселен саклар
Ныклы нигезен корсын!

Йортыгызга хәләл дәүләт,
Хөрмәт, мәрхәмәт тулсын.
Ата-анагыз түрдә булсын,
Тынычлап дога кылсын!

Хәерле нигезләр булсын,
Һәр ниргәгә кот кунсын.
Өй туйлары бәхет белән
Шатлыктан гөрләп торсын!

**Яңа өйдә**

Нарат өйдә сагыз исе аңкып тора,

«Әтием!» – дип, сабый йөзе балкып тора.
Сине өзелеп яратканын хатыныңның
Телдән түгел, күзләреннән карап сора.

«Җаным!» – диеп эндәшергә бу хатынга,
Үчти-үчти сикерергә бу балага,
«Улым!» – диеп горурланыр ата-анага:
Ир булып та,
Ата булып,
Бала булып,
Тик Син кирәк!
Тик Син кирәк!!
Һәм бик кирәк!!!

**Өеңдә көтсә ярату***
*(Җыр)*

Көтсә өеңдә ягымлы күзләр,
Каршы йөгерсә кадерле сүзләр –
Елмаер кояш кара төнеңдә,
Җылы тоелыр салкын көне дә.

Көтсә өеңдә ихлас ярату,
Мөмкиндер анда кайгың тарату.
Авыр уйларың качар, онтылыр,
Шундый бер көнең мең алтын торыр.

Көтсә өеңдә тәрбия, терәк,
Син диеп типсә анда һәр йөрәк.
Бәрәкәт иңәр бердәм нигезгә,
Тәгәрәр дөньяң төздә, тигездә.

Көтсә өеңдә кадер вә хөрмәт,
Сиңа дип пешкән ләззәтле нигъмәт. –
Үрнәк алып бу тату тормыштан,
Тәрбия күрер бала тумыштан!

-----------
* Илназ Баһ көе.

**Өй туе**

Бүген сезнең өй туе,

Өстәлләрдә туй сые.
Киленебез яшь булса да,
Өйрәсе тәмле, куе.

Бүген сезнең өй туе,
Өстәлләрдә туй сые.
Һәр кунакның күңелендә
Зурлап өй котлау уе.

Бүген сезнең өй туе,
Өстәлләрдә туй сые.
Ихластан теләгән теләк
Саклансын гомер буе!

**Тормыш яме**

Бисмилламны әйтеп токмач кисәм,
Ак яулыгым ябып башыма.
Тел өстендә генә тотарлык ул,
Туганнарым килсен ашыма.
Билләремдә чиккән ак алъяпкыч,
Кош телләре кисәм кыйгачлап.
Күпереп пешсен, сары майда йөзеп,
Күзегез кызсын, үзегез туйгач та.
Бәлеш салам, белгәнемне укып,
Каз итеннән, кайнар, шулпалы.
Чөкердәшеп чәйләп утырыйк соң,
Күршеләрем дәшим, туктале.
Бер сөйләрлек булсын, аш-суының
Теш төбендә калды тәме, дип.
Кардәш-ыру, дус-иш белән яшәү
Дөньяларның яме, гаме бит!

**Ипи пешә**

Кичке авыл мичләрендә
Утын яна эчләрендә:
Дөрли генә яркалары,
Сикерә ут алкалары,
Очып-очып китә шартлап,
Бабам тора мичне мактап,
Сырхау әбием терелә,
Йөзкәеннән нур түгелә.

Кинәндереп һәр күңелне
(Мәшәкате дә күңелле),
Бар кайнарлыкны сеңдереп,
Ипи пешә бөтерелеп.

**Каз өмәсе**
*(Җыр)*

Каурый чәчәм су юлына,
Ишле булсын казыгыз.
Өмәләрдә эш күрсәтеп,
Ярлар табып калыгыз.

Бии-уйный сылу кызлар,
Чыңлый чулпы төймәсе.
Борынгыдан килгән йола –
Татарның каз өмәсе.

Каз мамыгы яшь киленгә –
Түшәк, ястык, юрганга...
Дәртләнерсең, мамыктай кул
Иңнәреңә «кунганда».

Юл аягы – каз коймагы,
Сыйлансаң – суык тимәс.
Каз йолка белмәгән кызны
Егет солтаны сөймәс.

Бии-уйный сылу кызлар,
Чыңлый чулпы, төймәсе.
Борынгыдан килгән гадәт –
Татарның каз өмәсе.

----------------

* Риф Гатауллин, Зиннур Мөхәммәтдинов, Гөлсинә Гәрәева, Мәсгут Исхаков көйләре.

**Чиккән сөлге**

Чиккән сөлге – яшьлек истәлегем:
Яз гөлләре, моңлы гөрләвек.
Чиккән сөлге – минем гомер юлым:
Кышкы буран, җәйге күлләвек.

Чиккән сөлге – яшел алан, урман,
Көзге сагыш, кышкы бозлавык.
Чиккән төсләремә карыймын да
Эндәшалмый торам беравык.

Чиккән сөлге – бүләк балаларга,
Күзләремнән күчкән нурларым.
Ничәмә төс, ничә җыру анда –
Һәркайсында минем кулларым.

Чиккән сөлге – әниләре төсе,
Сагынганда искә алырлар.
Янып торган яз бизәге чиктем,
Гомер үтәр,
Гөлләр калырлар!
--------------
* Рамил Курамшин, Ильяс Гыйләҗетдин, Мәсгут Исхаков көйләре.

**Сәке**

Сәке безнең өстәл иде,
Сәке – безнең караваt.
Кирәк икән, чәй эч шунда,
Кирәк икән, кырын ят.

Сәке безнең сандык иде,
Каз оясы сыярлык.
Сәке асты сарай иде,
Ярган утын куярлык.

Сәке түренә өелгән
Түшәк, ястык, мендәре.
Сәке – әби-бабаемның
Намаз укыр мөнбәре...

Йорт-җиремнең төп җиһазы
Сәке булган элгәре.
Әйтерсең шунда төйнәлгән
Җир һәм Җиһан егәре!

**Чөгендерле катык**

Безне сыйлап йөри әбекәем,

Нурлар сибеп кояш шикелле.
Балачакка кайткан кыз баладай,
Бит очлары алсу, сөйкемле.

Йөгереп кенә кар базына төшә,
Өзелеп тормый һич тә катыктан.
Катыгы да чөгендерле катык –
Сагындыра хәтта актыктан.

Коштабакка агач кашык белән
Катык сала балчык чүлмәктән.
Чөгендерле кызыл катык кертеп,
Җил-җил атлап, юка күлмәктән,
Кыстый-кыстый сыйлый әбекәем, –
Кунак килүенә шатлана.
Куе сөттән чөгендерле катык
Элек дәверләрдән хаклана!

**Әбиләр биеклеге**

Туган телем,
Син җанымны
Шигырьле, нурлы иттең.
Үстердең, үсендердең дә,
Күңелне җырлы иттең.

Әбием куллары булып
Сыйпадың, иркәләдең.
«Әкият әз сөйләдең», – дип
Турсайдым, үпкәләдем.

...Сөйләрләр әле әкият,
Берне түгел, икене.
Тик әбиләр мөнбәрендә
Яшәү – безгә икеле...

**Өзелде буыннар**

– Исәнме, әбекәй,
Күзләрең
Нигә соң моң баскан бу кадәр!
Җаныңны ни-нәрсә телгәли,
Алдыңмы куркыныч бер хәбәр?

Сизәм ич, үтәли күрәм ич,
Яшьләнгән күзләрең, яшьләнгән.
Ак яулык яшергән чәчләрең
Яшеңнән иртәрәк бәсләнгән.
Ни кайгың,
Әйтсәнә, әбекәй,
Улларың, кызларың исәнме?
Бармы соң оныклар-татлылар,
Авырмый сәламәт үсәме?
– Барын бар,
Барын бар оныклар,
Әмма дә җибәрдек зур ялгыш.
Шул ялгыш ясаган гариплек –
Гүрләргә кергәнче гел сагыш.

И белсәң?!
Ашкынып,
дәртләнеп,
яшәреп
Беренче оныкны көтүләр.
Кемем бар,
Күрегез дигән күк,
Урамнан ирәеп үтүләр!..
Булмастыр, дидем мин шул чакта,
Бәхетнең моннан да олысы.
Булмастыр,
Башкада һич булмас
Сабыйның моннан да нурлысы!

Яраттым,
уйнаттым,
оныгым
Заманнан бер адым калмасын.
Үзебез белмәдек,
Ул белсен –
«Мама» дип әйттердем анасын.
Үзем дә анынча пупалап*,
Бала бит, үпкәли күрмәсен,
Ваттым да җимердем инде мин
Урысның бичара җөмләсен.

Тел белү зыянга китермәс,
Өйрәнсен «зур агай» сабагын.

---

* Охшатып сөйләргә тырышу *(диал.)*.

Ә алар
Мәктәпне яптылар,
Ачтылар пивноен,
кабагын...

Яптылар
Гел татар мәктәбен,
Туган тел укыту вәссәлам.
Кем сорап торды соң атадан
Кай телдә укытыйк, мәсәлән?

Балама ятлар баш булды да
Телемнең тамырын кистеләр.
Ни татар, ни урыс булмаган
Имансыз төркемнәр үстеләр.

Бу безнең фаҗига, кадерлем,
Кайтарып ал идең – эш узган.
Өзелде буыннар,
Беркем юк,
Беркем юк,
Өч онык – өч кыздан.

Байлык соң байтак бит күңелдә:
Әкият,
мөнәҗәт,
такмаза,
Әткәем, әнкәем җырлары –
Әманәт.
Хуҗа юк, ни маза?..

Ым кагып
Йә төртеп күрсәтеп
Аңлатам үземә кирәкне.
Гарип бит,
Телсез бит оныклар –
Шул телә,
Шул телә йөрәкне!

**Сөйләшәмен үз телемдә**

Туган телеңне өйрәнүгә кем комачаулый?..

Үз балаларын туган телләренә өйрәтә алмаган килеш, бөтен халык алдында милли сәясәт турында сүз куертучы кешеләр өчен оят миңа.

*Р. Н. Миңнехановның «Уфимские ведомости» газетасына биргән интервьюсыннан (Мәдәни җомга, 25.02.2011).*

Ана телен, туган телен
Хөрмәт итмәсә инсан,
Тик чит телләргә табынса,
Үз теле булса кысан –
Оялам андыйлар өчен;
Башкага биреп көчен,
Татарлыгыннан хурланып,
Читкә очыра күчен...

Кем комачаулый кешегә
Үз телен өйрәнергә?
Кем өйрәтә газиз телен,
Чүп тел, дип сөйләнергә?

Кем кирәксез тел дип саный
Газиз туган телкәен?
Хөрмәт итми, димәк, үзен,
Ата-анасын, илкәен.

Санламаганнардан телен
Милләткә нинди файда?
Сөйләшәмен үз телемдә,
Киртә күрмим беркайда.

**Туган телем – шиңмәс гөлем**

Туган тел бер генә була,
Ул – минем татар телем.
Ул – минем газиз әнкәем,
Газиз әткәем теле!

Туган тел бер генә була,
Ул – чишмә суы кебек.
Ул – якты Кояш сыман бит,
Нурларын тора сибеп.

Туган тел бер генә була,
Ул – минем тәмле телем.
Ул – минем баллы, ширбәтле,
Ул – минем назлы телем.

Туган тел бер генә була,
Ул – Туган җир шикелле.
Туган тел кадерле була,
Балаң кебек сөйкемле.

Туган тел бер генә була,
Ул – минем горурлыгым!
Ул минем күңел сазымда
Чирттереп җырлар кылым.

Туган тел бер генә була,
Ул – минем бөек телем!
Үзем белән бергә шыткан
Иң асыл, шиңмәс гөлем!

**Бүленгәнне бүре ашар**

Уңнан – сулга,
Сулдан уңга
Язып,
Укып карадык.

Уңнан язсак –
Сулны хурлап,
Сулдан язсак –
Уңны хурлап
Сүз куерттык,
Аңладык... –
Үзебез чәчтек,
Үзебез урдык,
Үзебез тектек –
Үзебез сүттек,
Карасын да,
Ак табын да
Кызыл белән
Ямадык... –
Гасырына
Өчәр тапкыр
Шытты
Шушы «яңалык»...

Көннәр туар,
Туар тагы
Белеклеләр,

Башлылар:
– Гарәпкә күч!
– Латинга! – дип,
Такыр башны
Кашырлар...

...Юк тынычлык
Бу татарның
Үзенә, язмышына.
Сан алалар: мишәр, типтәр...
Милләтем йөзгә сына.

Сындыралар, сындырталар
Чөйләп тә көйләп кенә.
Яшәтәләр, яшьнәтәләр
Чәйләп тә мәйләп кенә.

Инәлеп тә, игәлеп тә,
Келәнеп тә кинәнеп,
Күкрәк суга «милләтпәрвәр»:
Мин дә мин, дип кизәнеп...
Бушны сөйләп,
Йодрык төйнәп,
Кесәсендә йөрткәндә,
Ашка каршы аш булыр дип,
Майлы калҗа көткәндә,
Чәйнәмичә йоткан чакта
Хагын да, нахагын да,
Кычытмаганны кашытып
Кирәкмәгән чагында –

Бүлеп-бүлеп бүреләргә
Бирмәк карар корырлар:
Аерылганы – аюларга! –
Тезелеп чират торырлар.
...Кемгә кирәк безнең кайгы,
Ниенә безнең язмыш?
Рәхмәт әйтерсең, киләчәк,
Монгол, димәсә ялгыш...

**Әдәбият**

Тамырында «әдәп» сүзе,
И матур әдәбият,

Иман качкан битләреңне
Укырга хәтта оят.

Зәвыклы бул, акыллы бул,
И матур әдәбият.
Син безнең яшәү үрнәге,
Әдәпле әдәбият!

Милләтемә хас булмаган
Төпкелләрдә казынма,
Чит ил үрнәген бирәм дип,
Яткан җирдә азынма!

Билдән түбән хисләр белән
Шыр-шәрәгә калдырма,
Заманага ярыйм диеп,
Әдәбеңне яндырма!

Тамырыңда «әдәп» сүзе,
Син – матур әдәбият!
Иманга, фәһемгә өйрәт,
Яктырсын илаһият!

**Шагыйрь йөрәге**

Йөрәгемнән кошлар очырам...
*С. Сөләйманова*

Шигырьләрем – йөрәгемдә
Канат ярган кошларым.
Кайсы оча иртә язда,
Кайсы оча кышларын.

Кайсы оча җилгә каршы,
Кайсы күкләргә аша.
Кайсы сайрый былбыл булып,
Кайбере сулкылдаша.

Кайсы яши җылы җәйдә,
Кайсы кар-буран гизә:
Бәбигә тәпи китерә,
Кайсы хәвефне сизә.

...Кошлар оча йөрәгемнән,

Очырган гына белә!
Кайгысы да, шатлыгы да
Шагыйрь йөрәген телә...

**Китап нуры**

Китап калынмы, юкамы –
Сүзе энҗедәй булсын!
Китап сүзе сеңгән күңел
Рәхмәти нурга тулсын!

Гыйлем нуры – якты кояш,
Китап эче – затлы сый.
Гомер буе укы китап,
Гомер буе гыйлем җый!

**Үче юк**

Яр да яр,
Бар да бар,
Уйлаган уйларның очы юк.
Шигырь дип җенләнгән беркатлы бәндәнең
Ни синдә, ни миндә эше юк.

Эше бар,
Бик тә бар,
Аннан да күп уйлы кеше юк.
Иҗатка күмелгән хыялый затларның
Ни синдә, ни миндә үче юк.

**Әйтерсең**

Йөрәгем – хисләр казаны,
Ә күзләрем – суыткыч.
Суыткычтан керсез энҗе
Дәфтәр битенә тамды.
Агач кәүсәсе-каләмгә
Әйтерсең яңгыр яуды...
Каләмем шифа алды да
Бар серен әйтеп салды.

**Әмма ләкин**

Иҗатыма ак төс хуҗа.
Шул аклыкны исбатлыйм дип
Чигәм нужа...
Әмма ләкин кара кошны,
Ак иде, дип әйтә алмыйм,
Зинһар, бума!..

**Кайта-кайта**

Дәвер вөҗданына сыдырылып,
Томырылып аккан бу моңнар
Кайта-кайта бимазалар әле,
Кайта-кайта күңел җыр тыңлар.

Кайта-кайта табып терелтербез
Диварларга сеңгән аһәңне.
Моңлы сазлар булып сызлан да син,
Белмә, имеш, җирдә бәһаңне.

Белмә, имеш, җирдә кемлегеңне,
Ыруыңда Тукай, Мусалар,
Сәйдәшләре, Бакый, Илһамнары
Сәгать саен берәү тусалар,

Моңлы булмас идек бу кадәрле,
Җырлы булмас идек, кем белә?
Йолдызларның, ерак киткән саен,
Көлтә булып нуры бөркелә.

Без дә килеп беркөн атылырбыз
Йә упкынга, яки галәмгә...
Бүген бары сезгә шигырь язам,
Куәт бирсен җанга, каләмгә!

**Танып калсыннар**

Такыя чигәм асылташ белән,
Нәкыш бизәге – көмеш каш белән.
Кисеннәр аны яхшы күңелләр:
Җитү кыз-кыркын, чая киленнәр,
Кыңгыр салсыннар назлы сеңелләр.

Такыя чигәм асылташ белән,
Нәкыш бизәге – энҗе таш белән.
Киеп йөрсеннәр нечкә биллеләр,
Ирсезләр кисен, кисен ирлеләр,
Якын килмәсен керле күңелләр.

Такыя чигәм асылташ белән,
Нәкыш бизәге – җәүһәр каш белән,
Шөһрәт казансын изге канлылар,
Милләтен сөйгән туташ-ханымнар,
Илһам алсыннар шагыйрь җанлылар,

Такыя чигәм асылташ белән,
Нәкыш бизәге – алтын каш белән:
Кашлары җем-җем торадыр көлеп,
Танып калсыннар, кемлекне белеп,
Сәлам бирсеннәр, ерактан күреп!

**Мәхшәр көне**

*(Режиссёр Элем Климовның «Иди и смотри» исемле кинофильмын караганнан соң)*

Яшәү белән үлем фәлсәфәсе
Канга батып кергән сәнгатькә.
Башларыңны алып олагырсың,
Түзалмыйча ике сәгатькә.

Кара тавыш – үзе әҗәл монда,
Кара тавыш – үзе җан ала.
Өерелеп үлем өермәсе
Мигә тула, тәнгә тарала!

Тынны кыса янган мәет исе,
Күзне кисә төнге яктылык.
Кыса... Кисә...
Мин аңыма киләм,
Уйлар, шөкер, кайта яктырып.

Без үлемгә һич тә омтылмадык,
Мәхәббәткә,
Әйе, ымсындык.
Терелербез!
Көннәр, айлар үтәр,
Еллар үтәр –

Кайтыр чын тынлык!

...Тораташ булып каткан гәүдәмне мин
Көчкә алып чыгам бинадан...
Үлем кертмәс өчен зур сәнгатькә,
Без туарга тиеш яңадан!

Без туарга тиеш,
Рухи биеклеккә
Ия булган изге Анадан!!!

**Очрашу**

Кышкы суык.
Мәктәп бинасында,
Гөл-чәчәкле якты бүлмәдә
Шигърият белән очрашу,
Шагыйранә биек мөнбәрдә.

Әле шигырь,
Әле җыр агыла,
Кагыла-кагыла һәрбер балага,
Кереп тула нәни йөрәкләргә,
Сыялмас моң иркен далага...

Өнсез калган берәү:
Аерылып,
Каерылып җырга текәлгән.
Мин күзәтәм.
Димәк, моңның
Вазифасы бүген үтәлгән.

Кара,
Ничек йотылып тыңлый белә,
Суырылып шигырь сеңдерә.
...Әмма дөнья кемгә кояш элә,
Ә кемгәдер шәмен сүндерә...

Сискәндереп, күршем хәбәр бирә,
Күзем төшкән кызны күрсәтеп:
«Чүп-чар савытыннан табылган ул,
Әйтеп куйыйм әле, искәртеп.

Тудырганы нинди кавемнәндер,

Табып алган татар хатыны.
Шаярта да кайчак: «Урам-чокырларны
Себергәндә тапкан «алтыным».

Мин кабаттан кызга текәләмен,
Очкынланып яна ике күз...
Йөрәгемне кысам учларыма:
«Яшь чыгарма, шагыйрь, чыда, түз!»

«Их син, дөнья,
Буялгансың йонга!» –
Дип әйтәсе килә, көрсенеп.
Гөл-чәчәкләр,
Җыр-моң арасыннан
Әче язмыш чыга бүселеп!..

Кышкы суык.
Мәктәп бинасында,
Гаҗәп җылы, якты бүлмәдә
Гүя Үлем – Яшәү арасында
Очрашу иде бу мәлдә...

**Изге нәрсә бармы бу дөньяда?**

Калкынып,
Кайгымны җитәкләп,
Юл алдым иркәем янына.
Бер килсәм, ап-актан кабере,
Бер килсәм, чат чәчәк ябына.

Кайгыдан җиңелеп, йөгенеп,
Тез чүктем сабыем алдына:
– Мәрхүмәм, каберең кайда соң? –
Күз салдым кыйбла ягына.

Җилләрдән җитез бу уйларым
Сагаеп, саегып калдылар.
Ә җилләр, сызгырып, ыжгырып,
Йөрәккә шом-шөбһә салдылар:

– Куптарып чардуган-коймасын,
Урлады сәрхушләр, явызлар.
Эзләмә!
Эзен һич тапмассың,

Түзем бул, яшеңне агызма...

Йа Аллам!
Кемнәргә сыеныйм? –
Уйларым дөньяны буйлады.
Егылып иркәем янына,
Тәгәри-тәгәри еладым:

– Сиңа әйтәм...
Кызыбыз... кабере! –
Уйларым башыма сыймады.
– Ни изге бу җирдә? Әйтегез?! –
Мәрхүмәм гүяки сорады...

Кайгымны җитәкләп йөгердем,
Югалыйм кайларга?
Авылга!
Коткарды нигезем,
Җанымның
Ярасын юды да явымда...

...Үткәрдем монысын да хурлыкның –
Кара кан йотарга өйрәнгән.
Ни гаҗәп?!
Ни газап – дөньясы
Сабырны сытарга көйләнгән...

...Исәннәр ярамны күрмәсен,
Уйларым таш булып күмелде...
Әрнүле күз яшем җиремә
Гөл булып шытарга түгелде!..

## Тетрәүләр

Табигатьтә тетрәү дулкыннарын
Фәлән баллы диеп сөйлиләр.
Килгән зыян, күргән афәтләрне
Бөтен илләр бергә көйлиләр.

Дәүләткүләм уйлап торгызыла
Җимерелгән, упкан урыннар.
Чагыштыр син,
Кеше җанындагы
Тетрәүләргә нинди чыгым бар?

Нинди керем,
Нинди бирем,
Нинди сизем бар?..

**Шаһитлык бирмә!**

Ул – бик тә әйбәт кеше,
Киңәшкә – олы кеше,
Җавапка – туры кеше!
Ул – бик тә әйбәт кеше...

Сыналмаган «әйбәт»ләргә
Шаһитлык бирмә, кеше!

**Аксакал**

Аксакаллар кеше йөзен ертмас,
Мәслихәтләп әйтер, киңәшер.
Аксакаллар бугаз киермәсләр,
Алдан күреп, җайлап сөйләшер.

Аксакаллар шөһрәт өчен түгел,
Халык кирәгенә кузгалыр.
Әләк белән дуслыклары булмас,
Ялагай да кискен «юк» алыр.

Мин-минлектән һәрчак ерак торып,
Намус кушкан юлдан төз барыр...
Шушы кануннарны тоткан егет
«Аксакал ул» дигән ат алыр.

***

Күрше хакы – Тәңре хакы...
Кайвакыт онытылабыз.
Бер-беребездән узмак булып,
Каядыр омтылабыз.

Ипле генә, ансат кына
Көн ага, еллар ага.
Ишекләргә күрше түгел,
Битараф юлчы кага.

Өйдән өйгә, җаннан җанга
Шатлык керер чагында,
Япа-ялгыз, нәүмиз булып
Утырабыз табында...

**Кодалар, кодагыйлар**

Туй ясап бәйрәм итәбез
Кодалар, кодагыйлар.
Киләчәктә дә мул булсын
Табыннардагы сыйлар.

Киленнең дә, кияүнең дә
Күрик игелекләрен.
Бирсен Ходай балаларның
Бәхет, тигезлекләрен.

Яшь гаиләнең бәхете –
Безнең җылы тылыбыз.
Олыгайгач, түрдә булсын
Сезнең дә урыныгыз.

Үзе шатлык-муллык белән
Теләп үткәргән туйлар.
Гомер буе бергә булыйк,
Кодалар, кодагыйлар.

Түбәнсетми, түбәнсенми,
Бер-беребезгә юл куеп.
Чөкердәшеп яшик шушы
Түбә астына сыеп.

Бер-беребезгә юллар куеп,
Бер-беребезне аңлап,
Олыларны олы итеп,
Яшик яшьләрне санлап.

Туй ясап бәйрәм итәбез,
Кодагыйлар, кодалар.
Дәвам итсен кыз төшерү
Кебек матур йолалар.

Киленнең дә, кияүнең дә
Күрик игелекләрен.

Бирсен Ходай балаларның
Бәхет, тигезлекләрен.

**Килен җыры**
*(Җыр)*

Вәгъдәләшкән туй көнебез бүген,
Рәхмәт дуслар, килүегезгә.
Бәхет табар, бәхет бирер өчен
Иңдем шушы күркәм нигезгә.

Кушымта:
Пар аккошлар кебек яшәп
Бизәрбез бу нигезне.
Тигез мәхәббәтләр биреп,
Тигез мәхәббәтләр биреп
Бүләклә, Аллам, безне!

Вәгъдәләшкән туй көнебез бүген,
Яшь гомернең гүзәл мизгеле.
Яратышып, сөеп кавыштык без
Ике гаиләнең тиң гөле.

Кушымта.

Вәгъдәләшкән туй көнебез бүген,
Сикәлтәсез булсын юлыбыз.
Мирас булып күчсен балаларга
Парлап бергә язган җырыбыз.

Кушымта.
Вәгъдәләшкән туй көнебез бүген,
Җиңел булсын гомер итүе.
Сизелми дә калсын балаларның
Туып-үсеп буйга җитүе.

Кушымта.

Вәгъдәләшкән туй көнебез бүген,
Хәләл ярым булсын гел бергә.
Шатлыкларны уртаклашыр өчен
Рәхмәт сезгә килүегезгә!

Кушымта:

Челтәрләп, чигеп тегелгән
Ак ефәк туй күлмәгем.
Күлмәгемдәй аклык белән,
Күңелемдәге шатлык белән
Төшкән йортны бизәрмен!

**Заманмыни?**

Үзем җирдә, уем күктә,
Хыялларым далада.
Уйларым күктә булса да,
Эшем җирдә – калада.

Хыялым очса да иңләп
Дөньяны, далаларны.
Җиремдә үстерәм ич мин
Тудырган балаларны.

Җиремнән илһам аламын,
Җиремдә гомер юлым.
Җиремне сөям, кочаклыйм,
Канаттыр ике кулым!

Җиремне зурлап яшәүдән
Яшәрә күңелләрем.
Заманмыни?!
Дип, заманның
Кырмагыз күңелләрен!

**Заман баласы**

Куе булып үскән кара чәчем
Сибелеп-сибелеп очты җилләргә.
«Яулык бәйлә, балам, башың сызлар,
Чәчкәеңне җилгә җибәрмә», –
Диде әнкәй. Яулык бәйләмәдем,
Чәчләремне кошлар апкитте.
Шуңадырмы башым гел сызлады.
Бер үпте дә дөнья, ун типте.

Типте дөнья, кагып-сугып йөртте,
Уй корабым комга утырды.
Әйбәт итеп сөйләрлекне бирәү

Гайбәт итеп дөнья тутырды.

Күңелемнең бетте тынычлыгы,
Башым сызлый, юктыр чамасы.
Без шул чәчне генә түгел, ана сүзен
Җилгә очырган заман баласы.

**Атка мәхәббәт турында кыйсса**

Шәкүр карак ярлы-ябага малына тимәгән. Аның исеменнән ат урлаган бер төркемнең искиткеч акыллы атка юлыгуын күреп, кире иреккә җибәрткән, имеш.

*Халык телендәге риваятьләрдән*

...Үрчеделәр заман шәкүрләре –
Көтү белән атны куалар...
Ә Шәкүр ул иң кәттәсен чүпли,
Барон аты анда
Йә паннар!..

...Гамбургка сәфәр чыкмак иде...
Ташлап барлык мөһим эшләрен,
Карак законнарын бозучының
Үзе «коймак булды тешләрен»...

«Мин атларны төсе белән түгел,
Исе белән хәтта аерам.
Беренче кат, – диде Шәкүр карак, –
Кеше ышанмас хәлгә тарыгам.

Атларның гел асылларын «чирттем»,
Асылларда кодрәт, ялкын бар!
Хилафланып куган бу көтүдә
Нindидер сер,
Гайре шаукым бар.

Күргән көннән башлап күзәтәмен
Арандагы ярсу Байталны.
Йә хуҗасы,
Йә ат үзе изге –
Җибәр, үрдәккәем[*], бу малны».
Аратадан чыккач, мәгърур Байтал
Ат патшасы Шәкүр каракка

[*] Шәкүр Рәхимовның яратып әйтә торган сүзе.

Башын какты...
Аннан кешнәде бер
Ат көтүе торган тарафка.

Йөгереп килде Бурлы бия белән
Алмачуар сылу колыны.
Әмер булды,
Чыкты алары да...
Чап та кит бит
Табып юлыңны.

Күз яшенә чумган Байтал шунда
Ни эшләде диеп уйлыйсың?
Тезләренә чүгеп башын орды,
Өйрәтелгән ат дип торырсың!

Аннан килеп,
Горур башын чөеп,
Шәкүрнең ул
Күзләренә тутырып карады.
Абзаңны бу тәмам уйга салды,
Ат теленме әллә аңлады?

Сакчыларга тагын ым ясады,
«Чыгарыгыз, – диде, –
Барсын да!
Рәнҗетсәң, әллә ни күрерсең,
Кеше акылы бар бит монсында...

Насыйп булса кайтып җитәрләр, шәт,
Ара ерак инде ерагын...»

...Дөньядагы җиде могҗизаның,
Берсе булган кебек бу «фалның»
«Сере нидә икән?
Белеш әле!», –
Диеп, мине юлга чыгарды.

...Һәммә атның исәнлеген күреп,
Юлаучыбыз күңелен «тугарды»:
«Мәхәббәт ул әнә шундый була!
Ә кешенең соңгы атына?..
Кагылмый ул,
Киресенчә, ярдәм кулы суза,
Ятим-җилпе, сырхау-бахырга.

Ат җанлы ул...
Сөйгән атларының
Алтын-көмеш нукта – башында!

...Караклыктан өстен Сөю хисе,
Мал-мөлкәт – чүп Сөю каршында!»

**Үгез елы**
*(2009 елны каршылаганда)*

Алдагы ел – Үгез елы,
Кызыл төс уйнатмагыз!
Сабырлыгын сындырмагыз,
Ярсытып дулатмагыз!

Алдагы ел – Үгез елы,
Саллы, егәрле булсын!
Гайрәтле егетләр кебек,
Аягында нык торсын!

Алдагы ел – Үгез елы,
Үзебезнең мал үгез.
Сөзмәсен,
Тәхетле итсен
Маңгайдагы пар мөгез!

**Улым, ничек хәлләрең?**

Буйларың өрлектәй, кадерлем,
Син идең өметем, терәгем.
Никләргә бу картлык көнемдә
Калмады икән соң кирәгем?

Җаныма тынычлык табалмыйм,
Утларга салдың бит, балам син.
Кояштай күләргә теләдем,
Тәгәрәп еладым, дала тиң.

Бал-майда үстердем, кадерләп,
Хәзер соң киңәшем ник көчсез?
Баласы аеклар – генерал,
Баласы сәрхушләр – бер мескен.

Таңнарда тетрәнеп уянам,
Килер дип ни ачы хәбәрең?
Фикерең, гамәлең аекмы,
Улкаем, ничек соң хәлләрең?

**Бәһалик Ана сүзен!**

Бөек Җир, татлы яшәүдән
Китәбез берәм-берәм.
Газиз инәкәем, сине
Җәннәттә итеп күрәм.

Туган җир, туган нигезне
Яктырткан синең нурың.
Тормышка – ямь, җанда илһам
Кабызган синең җырың.

Синең янда булган, әнкәй,
Кояшның якты чагы.
Җанның телгәләп сызлаткан
Бер кылы артты тагы...

Кадереңне белдек микән,
Рәнҗепләр китмәдеңме?
Мин соң, әнкәй, синең алда
Бурычым үтәдемме?

Киңәшләрең, әйткәннәрең
Исемә төшә бүген.
Исән чакта, бергә чакта
Таптамыйк Ана сүзен!
Бәһалик Ана сүзен!

**Кайт исән чакларымда!**

Газизләрдән газиз күреп
Үстергән улым бит син.
Гомеремне дәвам итәр
Җыр-моңлы юлым бит син,
Кадерле улым бит син!

Гәүдәм җирдә йөргән чакта

Кайтмасаң яннарыма,
Шәүләм йөрер бимазалап,
Үлгәч күз алларыңда,
Кайт исән чакларымда!

Син кайткач дәртләнеп китәм,
Яшим тагын яңарып.
Кайт син исән чакларымда,
Ана хакын алга алып,
Ата хакын алга алып!

Бәхет телим, бөртегенә
Кадәр чәчем агарып.
Хәерле юл сорыйм сиңа,
Ходаема ялварып.
Калма, улым, соңарып!

**Әнкәй өне**

Кичектердем кайчакларда
Күрешү сәгатьләрен.
Аклану эзләдем санап
Дөнья мәшәкатьләрен.

Көттергән чаклар күп булды,
Зарыктырган минутлар.
Хәзер менә үкендереп
Яна бәгырьдә утлар.

Каберташка язган сүзне
Укып хәтта җил елый.
Җил еламый, үзәкләрне
Өзеп-өзеп җан дулый.

Баш иергә каберенә
Килсәмме җомга көнне?
Пышылдый әнкәй өне:
И көттем, улым, сине,
И көттем, улым, сине!

**Елатмагыз!**

Кадерләгез эти-әниләрне,

Кадерләгез әниләрне,
Үзкәйләре исән чагында,
Үзкәйләре исән чагында.
Өзмәгез лә үзәк-бәгырьләрен,
Өзмәгез лә үзәк-бәгырьләрен,
Арабызда йөргән чагында,
Арабызда йөргән чагында!

Елатмагыз әти-әниләрне,
Елатмагыз әтиләрне,
Хәтеркәйләрен лә калдырып,
Хәтеркәйләрен лә калдырып.
Җирләп куйгач, эшләр узгач йөрү
(Җаныгызга урын тапмый)
Хәер биреп, корбан чалдырып,
Хәер биреп, корбан чалдырып.

Олылагыз әти-әниләрне,
Үрнәкләрен, киңәшләрен
Күңел түрләренә сыйдырып,
Күңел түрләренә сыйдырып.
Гөнаһларны юып булмый,
Юып булмый.
Булмый кайтарып та,
Мәрмәр таштан һәйкәл койдырып,
Мәрмәр таштан һәйкәл койдырып!

**Иманы нык булса**

*(Фазучарак итеп)*

Помни, жена, что в житейском море
Должна быть семья – как надежный остров.
*Фазу Алиева*

Тормыш – диңгез,
Шул диңгездә
Гаилә бер нәни утрау кебек.
Әйләндереп алган чүпле күбек –
Актарылып кайный дулкыннары,
Күтеп тора котсыз упкыннары,
Сытмак булып кыса диңгез яры...

Мәгәр синең гаилә утравың

Көрәп, түгеп торса чүп-чарын,
Мәхәббәткә төрсә ир-ярын –
Котсыз дулкыннардан кайгы таммас,
Дәһшәт упкыннары йота алмас,
Ямьсез шаукымнар да тынмый калмас,
Үзәге нык – утта янмас!
Иманы нык – сине суга салмас!

**Кызу канлы булган безнең нәсел**

Кызу канлы булган безнең нәсел,
Җанын саклыйм диеп тормаган.
Бабам мәрхүм, сабыйларны яклап,
Кансыз вәхшиләрне кыйнаган.
Кызулыгы белән ничә тапкыр
Чак-чак кына башын җуймаган.

Кызу канлы булган безнең нәсел,
Яратмаган ялган, хәрәмне.
Килгән чакта аждаһа күк дошман,
Калдырмыйм дип җирне, адәмне,
Күкрәгенә сыймас ярсу белән,
Сакларга дип җирне, галәмне,
Киткән әткәй чыгып изге яуга.
Җанын аяп тору кая ул!
Үз гомерен илтеп утка салган,
Юлдашныкын тартып алган ул!
Шулай кирәк булган, бары шулай,
Үз гомерен аяу кая ул?!

Кызу канлы булган безнең нәсел –
Кызу канлы, кызык кешеләр.
Туган иле өчен яна-яна,
Утка керде, суга төштеләр.
Илләр имин булган чакта алар –
Шундый сабыр, тыныч кешеләр!

**Җиңү көне**

Була икән Кешелекнең
Анадан тума көне!
Җиңү көне –
Бу дөньяның

Яңадан туган көне.

Майның тугызынчы көне –
Гасырның изге мәле.
Шул мәле безне үлемнән
Тартып алды, бирмәде!

Бу тынлыкның бер мизгеле,
Бер секунды эчендә
Күпме ирнең йөрәк каны,
Беләк, егәр көче дә.

Чәчәк атып өлгермәгән
Җаннары... куырылып,
Күпме авыр йөк тартканнар
Сабыйлар, суырылып.

Ат булып җигелгән толлар
Арбаларга, чанага.
Каен тәртә шартлап сынган,
Туры килми чамага.

Түзде толлар,
Түзде уллар,
Түзделәр карт-корылар.
Бәгырьләргә кату чыкты,
Җилкәләргә – орылар...

Өч ел үтте,
Дүрт ел үтте,
Сукты көтелгән сәгать.
Күралмаслар кебек иде
Кабат сөю-сәгадәт.

Күрделәр,
Сөелделәр!..
Толлар гына, нәүмиз калып,
Кан-яшькә төелделәр...

Кадерле безгә тыныч көн,
Кадерле һәр минуты.
Үз тәнендә генә йөрсен
Һәркемнең йөрәк суты!!!

**Әниләр сүзе**

Тупасланды, әйе, безнең куллар,
Сез сугышта йөргән чакларны.
Җир тырмашып сабан-сука тарттык,
Алыштырдык хәтта атларны.

Әмма түздек бөтен авырлыкка,
Сез кайтуны көттек җан атып.
Түздек, түздек,
Тагын бер кат түздек,
Иреннәрне тешләп, канатып.

Бөкерәйгән билләр тураерлар,
Эчкә баткан күзгә нур иңәр.
Без beләбез, җиңел бирелмәгән
Беркемгә дә олы җиңүләр.

Тупасланган иде безнең куллар,
Сез сугышта йөргән чакларда.
Җир тырмашып кара җирне сөрдек,
Калмас өчен җирдә ятларга!

**Күңел күзе**

«Әнкәй» дигән сүзне ишетер өчен,
Сөяр өчен безнең балаларны,
Юл газабын үтеп киләсең гел,
Якын итеп ерак араларны.

Авырлыклар килсә, кыен килсә –
Бер бисмилла гүя «әнкәй» сүзе.
Шатлыкларны күрсен,
Газапларны
Күрми торсын иде әнкәй күзе.

Болай да бит барлык кайгыларны
Күчтәнәчләр итеп син аласың.
Аерылганда, моңсу таңнар булып,
Нурлы көннәр булып югаласың.

Сине уйлау – олы юаныч ул,
Әнисезләр ничек түзәләрдер.
Безнең сезгә сыенганны күреп,

Бәгырьләрен кат-кат теләләрдер.

Кичә килгән идең, бүген киттең... –
Кулларыңны суздың түзем генә.
Йөрәгеңдә сыкрау-әрнүләрне
Күрде бары күңел күзем генә.

**Дөнья булгач...**

Дөнья фани.
Бәхилләшә алмый
Китеп барыр, бәлки, әнкәм дә.
Туган йорты белән саубуллашып
Очып китәр, бәлки, бәбкәм дә.

Дөнья булгач,
Төрле хәлләр була,
Китәр, бәлки, сөйгән ярым да,
Әмма хыялдагы саф мәхәббәт
Тиеш минем белән калырга.

**Ялгыз нигез**

Туган йортның моңсу тынлыклары,
Ызаннарның әрсез кырлыклары
Күзебезгә яшьләр тутыра.
Әле генә гөрләп, гөжләп торган,
Тирә-юне гөлләр белән тулган
Туган нигез ялгыз утыра.

Бер кочакта, сез һаман да бергә
Әткәй кулы салган тигез ниргә,
Әнкәй кулы юган тәрәзә.
Сезнең төсне сагынып кайттык, әнкәй,
Балачакка кире кайттык, әткәй,
Хатирәләр ага әз-әзләп.

Көн дә йөргән сезнең бакча юлы,
Һәммә җирдә ныклы хуҗа кулы,
Сез җан өргән гөлләр, куаклар.
Бихисап күп сез утырткан агач,
Бер һәйкәл кук үзегез дөнья куйгач –
Юньле гомерен шулай йомгаклар!..

**Картлык**
*(Мөнәҗәт)*

Балам да юк, анам да юк, юк ирем дә,
Күзләремне теким, Аллам, әйтче кемгә?
Ыңгыр-шыңгыр йорт-курамны әйләнәм дә
Сыенамын ай-йолдызсыз кара төнгә.

Бар иде бит бәбкәем дә, әнкәем дә,
Ирем белән бергә туган чиркәем дә.
Юктыр хәзер су бирерлек бер кешем дә,
Артка китә, алга бармый бер эшем дә.

Парсыз калган, ярсыз калган аккош кебек,
Канатсыз кош баласыдай торам чүгеп.
Җир җимертеп эшләүләрнең әҗереме,
Яшәүләрем бүген көндә михнәт чигеп?

**Соңгы чиктә**

И, и генә,
И, сез генә,
И, без генә, туганнар!
Кан-яшь түгеп
Гомер сөрә
Туганнарын җуйганнар.

И, и генә,
И, сез генә,
И, без генә, җаныйлар,
Кадерлесен җуйган җаннар
Бирчәйгәч тә каныйлар.

И, и генә,
И, сез генә,
И, без генә, якташлар.
Соңгы чиктә
Туган җиргә
Кайтып ята күп башлар.

**Авыл тормышы**

Авыл халкы, имеш, мулдан яши,
Бәрәңгесен игә, мал тота.
Тик аның да күпме «тик»ләре бар,
Һава шарты кайчак «кул тота».

Эссе каба суган басуында –
Баш түбәсен керә бораулап.
Тиз тотарга!
Боз болыты килә,
Җәһәт җыю кирәк, җинаулап.

Алы да юк, ялы да юк аның,
Көн-төн эштә,
Хәтта йокламый.
Авыл кешесенең кадерләрен
Кемнәр белер?
Кайчан?
Әй, наный!..

**Саклый авыл**

Кара яз –
Карлы көзгәчә
Иген игә авыл халкы,
Кунып басуында ята,
Ял итәргә юктай хакы...

Акыл, зиһенкәен җыеп
Уйлаганы – фәкать иген.
Ипекәйгә табынганга
Белә яхшы-яман чиген.

Шушы авыл саклап килә
Кан хәтерен, биеклекне.
Тамырлардан җәйрәп аккан
Татардагы бөеклекне!

Саклап килә ничә гасыр:
Өметләрне, хыялларны,
Кыйблабызны югалтмаслык
Иман, ныклык догаларын.

Илгә миһербанын сибеп,

Яшәешне дәвам итеп,
Милләтемнең асыл йөзен
Киләчәккә, алга илтеп.

Кара яздан карлы көзгә
Баш күтәрми тарап кырын,
Ымсынмыйча алтыннарга,
Суза һаман яшәү җырын!

**Синдә һәрбер көн яңа**

Яшен булып балкыйммы,
Сагыш булып саркыйммы?
Туган ягым күгендә
Йолдыз булып калкыйммы?

Мәхәббәт эчкән җаным,
Тәнемә күчкән таңым,
Күздә – нур булып кабын,
Телдә – моң булып кагын!

Сиңа кирәк булганга,
Бәхетле мин дөньяда.
Синдә генә, авылым,
Һәр төн, һәрбер көн яңа.

Җырла туган ягыма
Багышланган җырымны.
Сөйлә, алтынга төреп,
Сурәтләнгән кырымны.

Яңгыр булып кайтырмын
Син сусаган көннәрдә.
Чәчәк булып шытармын
Сабый салган эзләрдә.

Синдә генә, авылым,
Һәр төн, һәрбер көн яңа.
Сиңа кирәк булганга,
Бәхетле мин дөньяда!

**Зур шатлыгы**

Авылыбызның сылу сабыйлары.

Салпы якка салам кыстырып
Йөгерттеләр апа-агайлары,
Җибәрерләр иде кыздырып:
Йәгез әле, йәгез, кем беренче?
Йәгез әле, йәгез, кем җитез?
Йөгерәбез, йөгенәбез,
Чөеләбез, сөенәбез...
Менә шулай!
...Туган-үскән газиз җиребезнең
Зур шатлыгы,
Зур байлыгы идек мәгәр без!

**Бәби мунчасы**

Йолалары милләтемнең
Күчә килә кечегә.
Ак әбиләр игътибары
Яңа туган кешегә.

Бәби мунчасы ягалар
Баладан котылгачтын,
Кырык кыл өзелгән газап
Күпмедер онтылгачтын.

Буыннарны сылап, сөеп,
Сыйпап оешканнарны,
Мунча кертәләр әбиләр
Җан тудырган җаннарны.

Мунча кертәләр әбиләр,
Укыйлар теләк-дога.
Шуңадырмы авыллардан
Рәхимле җаннар чыга.

**Карга боткасы**

Дәгъвалашып язгы ташу киткәч,
Язгы кояш җылы нурын сипкәч,
Узу белән апрель уртасы,
Пешә иде карга боткасы.
Җыеп безне – ыбыр-чыбырны,
Авылның иң өлкән карчыгы
Китәр иде...

Безне көтеп тора
Кыңгыр түбәтәйле таучыгы.

Табыннар мул хәзер –
Икмәк кенә
Түгел икән яшәү тоткасы.
Тик онытылмый түбәтәйле шул тау,
Шунда пешкән карга боткасы.

Ботка пешкәч, җыелышып,
Түбәтәй тау
Итәгенә килеп утыргач,
Күңелләрне кояш нуры белән,
Яшәү яме белән тутыргач,
Елмаер ла иде Нурлый әби,
Сыйпап яңа шыткан үләнне, –
Әйтер иде:
«Дошманыңа хәтта
Күрсәтмәсен безнең күргәнне!»

Ул чагында бала булганбыз шул,
Кызык булган безгә галәмәт...

Нурлый әби әйткән нурлы сүзләр –
Әманәт лә булган, әманәт.

Әманәтләр әйтер өчен диеп
Пешергәндер, бәлки, ул аны.
Икмәк кискән саен хәтерлимен
Онытылып барган йоланы.

...Тормышлар мул хәзер,
Табыннар мул.
Ә нәрсә соң яшәү тоткасы?
Каян гына искә төштең әле,
Онытылган карга боткасы?!

**Кышка соклану**

Мамык кебек карга басып
Атлыйм ап-ак дөньядан.
Күпереп тула баскан эзем,
Күпереп тула яңадан.

Барам да барам.
Аклыктан
Сихерләнгәнмен бугай.
Ул гүзәлдер бу агачлар,
Ул гүзәлдер бу тугай.

Тирә-юньгә сокланудан
Шашып китмәсәм кана...
Хисләремнең ялкынынnan
Битләрем дөрләп яна.

Салкын аклык күңелләрне
Шулай алдый алганын
Аңладым да салмакладым
Үтәр юлның калганын...

**Хәерле иртә!**

Хәерле иртә, туган җирем,
Хәерле иртә, торган җирем!
Илем-көнем, балаларым,
Авылларым, калаларым.

Хәерле көн, хәерле көн,
Килеп җитте көткән сәгать,
Изгелекләр кылыр өчен
Чыгып торсын төрле сәбәп.

Елгаларым көнгә ага,
Көнгә ага, көн дә ага.
Үзәннәргә бу таңнарым
Ак каймактай томан яга.

Сөзәк тауның итәгендә
Чәчәкләргә көн кагыла.
И сылу ла каен кызы,
Ак тәненә күз чагыла.

Яфракларның серләшүе
Моңнар сала әйткән сүзгә.
Табигатьнең үзе булып
Эндәшәмен бүген сезгә:
Хәерле иртә, туган җирем,
Илем-көнем, балаларым!

Уяныгыз,
Ямыйсы бар
Бу дөньяның яраларын!

**И кешеләр, нишлисез?**

Мин шомырт агачы булам,
Ап-ак чәчәкләр атам,
Тәмле хуш ис таратам,
Балаларны яратам,
Олыларны яратам.

Ямь бирәм, җимеш бирәм,
Сыйлыймын сезне ел да.
Тик, яз җитсә, ерткычлык –
Ботагым сезнең кулда...

И балалар, кешеләр,
Беләә торып нишлисез?
Аш биргәнгә – таш атып,
Яман эшләр эшлисез.

Яз аласыз сындырып,
Күз җыясыз сындырып,
Җимешле агачларга
Булырмы бер тынгылык?..

**Кем дә булса кадерсезли калса**

Шактый ерак иде өебездән
Йомшак сулы Галләм чишмәсе[*].
Чишмә бурасына балчык ишсәң:
«Ишмәгезне бар, – дип, – ишәсе», –
Ачуланыр иде авыл халкы,
Чәй суының кадерен белмәгәч.
Безнең өчен бар да бертөрле су –
Яшь шомырттай авыз бөрмәгәч.

Ә әнкәйләр суның тәмен белгән,
Ямен тойган чишмә буеның.
Чишмәсе дә сайлаган ич аның

[*] Зөбәер авылында Галләм абый ачкан чишмә.

Борылып аккан елга куенын...

«Су су инде», – дия идек кайчак,
Ераксынып Галләм чишмәсен.
...Хәзер берсе кадерсезли калса,
Ишәрмен күк үзем ишмәсен.

**Кем утырткан – шул сыйлансын**

Туган ягым – түр ягым,
Тирә-юньдә бер ягым!
Бәлзәмдәй мәрхәмәт эчеп,
Яшәреп йөргән чагым.

Туган ягым – Ыклы як,
Туган нигез чиста, ак!
Һичнидән өстен булалмый
Нигезеңә тигән хак.

Ыккае көмеш сулы,
Суында байлык тулы.
Иң уңган, моңлы егет
Булыр Мөслимнең улы.

Утлары кабынамы,
Җилләре кагыламы,
Сагынып саргаямы күңел,
Саргаеп сагынамы? –

Бәхеткә, назга кинәнсен
Нурлы йөзле парлары.
Ишелмәсен ярлары,
Саргаймасын таллары!

Сулары айкалса да
Баскан җир чайкалмасын,
Кем утыртса – шул сыйлансын,
Яратсын үз алмасын!

**Симәгем**

Сим-Сим аңа ишек ачкан,
Сим-Сим аңа бишек аскан.

Мөхәммәтнең олы кызы
Менә шунда күзен ачкан...

Тылсым көче белән хастан:
Сим-Сим үзе ишек ачкан,
Симәк авылы бишек аскан...
Туган ягым – Мөслим ягы,
Ә дәүләтем – Татарстан!

Язмышыма серләр качкан:
Симәк авылы бишек аскан,
Шагыйрь булыр мин мөслимәң
Шунда туып, күзен ачкан,
Язмышыма серләр качкан.

Менә шунда тәпи баскан
Мөхәммәтнең олы кызы.
Ул дөньяга килгән өйдә
Ут элдергән каен тузы,
Җылы биргән имән кузы.

Биеткәндер имән кузы
Самавырда чишмә суын.
Шуңадырмы, сөбханалла
(Шөкер Ходаем-Аллага!),
Үз көчендә егәр-буын!

Симәгемнең җиләклеге,
Урманнары, әрәмәсе
Туендырган, сыендырган,
Ык елгасы коендырган,
Гомер юлымда – һәммәсе.

Мәрхәмәтле туган җирем!
Игелекле атам кыры!
Рәхмәтеңнән ташлама син,
Сагыш сүзе саклама син,
Илһам алсын шагыйрь җыры,
Чәчәк атсын шигырь кыры.

Әткәемнең туган җире –
Минем төбәк, минем илем!
Кайчан кайтып егылсам да,
Үтешлиме сугылсам да,
Сыяр кебек сиңа серем.

Кендек каным тамган җирем,
Симәгем, син – туган илем!

**Хыялымда кайтып килдем**

Озын-озак көн булды бу –
Иртәдән төнгә кадәр.
Хыялда җәяүләп кайттым
Иделдән Сөнгә кадәр.

Сөн буйларына кайттым да
«Утырып уйлар уйладым».
Үзәкне өзгән моңымны
Җырга салдым, җырладым.

Кушылды куш каеннарым
Сагышлы хисләремә.
Күзләремә яшь төелде,
Төштең дә исләремә...

Озын-озак көн булды бу –
Иртәдән төнгә кадәр.
Хыялымда кайтып килдем
Иделдән Сөнгә кадәр.

**Ватаным!**

Кайда да бер кояш, диләр,
Ышанмагыз, авылдашлар:
Безнең авыл өстендәге
Кояш якты бар кояштан.
*Ф. Шәфигуллин*

**1**
Сагындым елгасыз-сусыз,
Урмансыз ягыбызны.
Мин киткәч туган балалар,
Сагындым барыгызны.

Мин кайткач төшкән киленнәр,
Мин юкта киткән кызлар.
Әби булган замандашлар,
Оныкбулган – йолдызлар.

Кайда да бер кояш, диләр.
Җәмәгать, алай түгел!
Туган җирнең кояшкаен
Һәр көнне тели күңел.

Тук булсак та искә төшә
Каймагы, әйрәннәре.
Калдылар артта тезелеп
Чәчәкле бәйрәмнәре.

Сагындым туган җиремне,
Фәкать шунда ал таңым.
Зөбәер! –
Йөрәк түремдә
Иң кадерле Ватаным!

**2**
Зөбәер – туган җиркәем,
Олы юл уртасында.
Сынатмый егете-кызы
Ындырда, сукасында.

Шаккатмалы урманы юк,
Сикәлтәле юллары.
Тик авылдаш ир-атларның
Көрәк кадәр куллары.

Киленнәре Зөбәернең
Йөгерә-атлый йөри.
Кыз сорап килсә күршеләр,
Мактанып ала юри.

Баҗанага төшеп йөзә
Кояшы да, Ае да.
Кашка тау итәген чемли
Колыны да, тае да.

Булса булсын туган ягың
Кайгыңны таратырлык.
Урмансыз-сусыз килеш тә
Өзелеп яратырлык.

Сихәтле сәгате синдә
Гомер дигән көнемнең.

Зөбәер – үскән авылым –
Бер бизәге илемнең.

**3**

Чишмәле безнең авыл,
Каршыда Кашка тавы.
Уңда-сулда кырлары,
Кырда тургай җырлары.

Буасы бар балыклы,
Яшь наратлар калыкты,
Кечкенә авылым илгә
Бирә күпме байлыкны.

Яз көнендә буасына
Кайта кыр үрдәкләре,
Пар аккошлар – табигатьнең
Иң гүзәл бизәкләре.

Болынында гөл-чәчәкләр,
Сибепләр салган кебек...
Башкасын сөйләп тә тормыйм,
Килеп китегез күреп!

**4**

Зөбәер!
Данлы авыл син!
Зөбәер – җанлы авыл!
Күп михнәт, шатлык кичергән
Һәм күргән дошман явын.

Геройлар биргән авыл син,
Шәхесләр биргән авыл!
Җиңалмаган сине дәһшәт,
Ега алмаган давыл.

Зөбәер – нурлы авыл син,
Зөбәер – җырлы авыл.
Кая китеп яшәсәк тә,
Синдәдер йөрәк-бавыр!

**Балачак мизгелләре**

Зөбәернең* басулары,
Саф алтын кебек иде.
Усының* җир җиләклеге
Ал ялкын кебек иде.

Чәчер* буйлары дисеңме,
Күлләре, Нарат урман –
Бөтен тирә авылларның
Бәйрәме шунда узган.

Илтимернең* юалары,
Бөрлегән-баланнары,
Бер урамлы Түке аулы –
Бөтнекле яланнары.

«Таң кояшы – яшь кояш, – дип, –
Иң эшли торган вакыт», –
Уята иде әнкәйләр,
Хәл алмас борын ятып...

Чалгы чыңы, урак җыры,
Ул тояк тавышлары!
Күз алдын яктыртып уза
Күбәләк кавышканы...

Һай син безнең балачакның
Баллы-майлы көннәре!
Кемне генә сагындырмый
Туып үскән җирләре?!
----------------
* Зөбәер, Усы, Чәчер, Илтимер – авыл исемнәре.

**Әрәмә**

Бала чакта аз чаптыкмы
Зөбәер кырларыннан?
Эссе көндә су эчкән чак
Тәгәрмәч юлларыннан
Истә әле, һаман истә
Чыклы чирәм, чокырлар.
Җимешенә җибәрмәскә
Тарткалашса чытырман,

Шуып астан керә идек –
Безме аннан буш кайткан?
Әмәлен тапсаң, әрәмә
Бар байлыгын
Чиләгеңә бушата...

**Нурчишмәм**

Карап торам, хәйран калам,
Суларыңа тәңкә салам,
Тәңкәле су – сучишмәм.
Көмеш суда чагыла нур,
Көмеш суда агыла җыр –
Җырчишмәм син, җырчишмәм.

Салкын суын кулга алам,
Тып-тып тамчың телгә тама –
Балчишмәм син, балчишмәм.
Тәннәргә сихәтең сеңә,
Җаннарга җылың йөгерә –
Җанчишмәм син, җанчишмәм.

Җирнең җәйге кочагында
Кызның моңсу курчагыдай
Чүгәлим, тик җир ишмәм.
Моңлансам да синең кебек,
Горур калам, дәртең күреп,
Сүз тишсәм дә, сер чишмәм.

Көч-гайрәтең, күрче, нинди,
Миндә дә ут, ялкын көйри –
Туган чишмәм, җирчишмәм.
Тибеп, бәреп чыгасың ич,
Тынычлангач тонасың ич –
Сафчишмәм син, сафчишмәм.

Уйлап торам, хәйран калам,
Суларыңа тәңкә салам,
Тәңкәле су – сучишмәм.
Көмеш суда агыла җыр,
Көмеш суда чагыла нур –
Нурчишмәм син, нурчишмәм!

**Умырзая**

– Син ландыштай хуш исле дә түгел,
Миләүшәләр кебек гүзәл дә,
Умырзая, җырланасың?
Тибрәнәсең нигә телләрдә?

– Хуш исле һәм чибәр булмасам да,
Гомерем минем узмый заяга:
Боз өстендә чәчәк атам бит мин, –
Яз калдырып китәм дөньяга.

Үсентемнең яшәү кодрәтеннән
Җир тәнендә эри туң катлам.
Сихәт тә мин сырхау йөрәкләргә,
Табигатьтә – гүзәл бер аклан!

**Яхшыем – якты авылым***
*(Җыр)*

Туган ягым – якты өлешем,
Өлешемә тигән көмешем.
Синдә бары, синдә бәхетем,
Бәхетемә тигән тәхетем.

Кушымта:
Яхшыем, яхшы авылым,
Изге җаннар төбәге.
Уларыңның, кызларыңның
Син һәрвакыт терәге.
Чиләк-чиләк карлыганың,
Бөрлегәнең, җиләгең.
Чәй кайнаганчы җыярсың,
Булсын гына теләгең.
Терәлеп тора урманың –
Чиясе бар, юасы.
Яхшыем, яхшы авылым,
Җиләк-җимеш оясы.
Кайгым булса, сиңа кайтамын,
Кырларыңда чалкан ятамын.
Шатлыкта да сиңа сыенам,
Рәхим-шәфкатеңә коенам.

Кушымта.

Таратадыр хәсрәт хисемне
Атап әйтү синең исемне:
Яхшый авылым – якты өлешем,
Өлешемә тигән көмешем!

Кушымта.

*1997*

________
* Илһам Хисмәтуллин көе.

**Туган илнең түре Нәдердә***
*(Җыр)*

Үсмер чакның күңел дәфтәрендә
Шаяру да, шуклык, җәбер дә.
Беркайда юк мондый матур авыл,
Туган илнең түре – Нәдердә.
Колач җәеп каршы ала,
Колач җәеп каршы ала
Корбанай әрәмәсе.
Шомырт исләренә чумган,
Шомырт исләренә чумган
Очлы Тау әйләнәсе.
Өлкәннәргә һәрчак хөрмәт монда,
Ата-ана сүзе – кадердә.
Таң суында тәпиләрен юып,
Бала-чага үсә Нәдердә.
Шәкүр каракны яшергән,
Шәкүр каракны яшергән
Бикәнәй урманнары.
Сабантуйда бил бирмәгән,
Бер эштә дә бил бирмәгән
Нәдернең уңганнары!
Вакытлыча утлар сүнсәләр дә,
Ятим нигез юктыр Нәдердә.
Туган якка кайтып башны ию,
Әманәт тә кебек, нәзер дә.
Колач җәеп каршы ала,
Колач җәеп каршы ала
Корбанай әрәмәсе.
Ап-ак чәчәкләргә чумган,
Ап-ак чәчәкләргә чумган
Очлы Тау әйләнәсе.

*1998*

---

* Илгизәр Исламов көе.

**Гүзәл Казаным**

Алтын бишегем,
Гомер ишеген
Ачтым мин синдә, гүзәл Казаным!
Яшьлек елларым,
Барыр юлларым
Сиңа тоташа, данлы Казаным!

Синдә батырлар,
Синдә матурлар,
Синдә көчлеләр туа, Казаным!
Моңлы сазларың,
Көзең, язларың
Илһамландыра, гүзәл Казаным!

Шагыйрьләр иле,
Галимнәр иле,
Шанлылар иле – гүзәл Казаным!
Миллионнар иле,
Милләтләр иле,
Татарлар иле – данлы Казанным!

**Тарихи калам***
*(Җыр)*

Җырда гына түгел, тормышта да
Рифмалана «Казан» «заман»га.
*Х. Туфан*

Башкалам минем, таш калам Казан,
Дәшеп китерден үзеңә, Казан.
Серле зур калам, тарихи калам,
Гомер итәргә мин синдә калам.

Башкалам минем, таш калам Казан,
Рухи мәркәзем, гомер елъязмам.
Синнән моң алып, илһам-нур алып
Ямьләнә кебек бүгенге заман.

Башкалам минем, таш калам Казан,
Мең яшең әнә капкаңны кага.
Күпме милләтләр, дус-тату яшәп,
Синдә бәхетен, тәхетен таба.

Мәгърур башкалам, шәһри Казаным,
Үсмер елларым, яшьлек юлларым.
Насыйп булсачы каршы алырга
Гомер азагын синдә, Казаным!
--------------
* Сәйдә Вәлиди көе.

**Казан – туган җиребез**

Безнең шәһәр – Казан шәһәре,
Безнең шәһәр – бик гүзәл, ямьле,
Безнең шәһәр – борынгы шәһәр,
Безнең шәһәр – тарихлы, гамьле.

Казан, Казан – туган җиребез,
Татарстан – туган илебез!
Җир-суларның син иң якыны,
Шәһәрләрнең син иң матуры!

Безнең шәһәр Идел ярында,
Казансуы ага янында.
Мең яшь тулды,
Олгайган саен
Матурлана бара тагын да.

Казан, Казан – туган җиребез,
Татарстан – туган илебез!
Җир-суларның син иң якыны,
Шәһәрләрнең син иң матуры!

**Без – татар балалары!**

Без – Кол Шәриф шәкертләре,
Идегәй бөркетләре,
Күчембикә токымнары,
Нурсолтан шытымнары,
Сөембикә орлыклары,

Кол Гали оныклары,
Батырша яраннары без
Һәм Тукай оланнары –
Халкымның күз каралары,
Әрнүле яралары,
Без – татар балалары шул,
Без – татар балалары!

**Универсиада**

Төрле җирләрдән, бик күп илләрдән
Агыла ташкын, яшьләр ташкыны.
Борынгы шәһәр Казан күгендә
Кабынды ялкын – спорт ялкыны.

Кушымта:
Универсиада, универсиада,
Универсиада – син безнең ода!
Шатлыклар китер җиңүләр белән,
Универсиада, без синең белән!

Төрле милләтләр, төрле телләрдә
Сәламен бирә, әйтә рәхмәтен.
Спорт шундый көч, фәкать ярышта
Ача үзенең серен, хикмәтен.

Кушымта.
Колачлы, эшле халкым, дәүләтем –
Татарстаным, хөр мәмләкәтем!
Иминлек белән, игелек белән
Өләш халкыңа ямь-бәрәкәтең!

Кушымта.

**Тәрәзәмне ачып куйдым***

Үтәли күрсәтә көнне
Тәрәзә пыяласы.
Спорт бәйрәме үткәрә
Бүген татар дөньясы.

Тәрәзә төбем кояшлы,
Чәчәк ата ал кына.

Сокланып китсен килгәннәр
Татарстан халкына.

Ике тәрәз уртасында
Күкеле сәгать суга.
Татарстан кунакчыл ил,
Халкы оста аш-суга.

Катлы-катлы тәрәзәмнең
Уртасында бар бушлык.
Арага җилләр үткәрмик,
Тантана итсен дуслык!

Минем тәрәзәм тәрәзә
Карап тора кояшка.
Тормышыбыз тирә-юньдә
Өстенерәк бер башка.

Ак та була, күк тә була
Тәрәзә рамнары.
Татар җирен читләп үтсен
Сәясәт бураннары.

Карасу элпә япканнар
Зәңгәрсу тәрәзәгә.
Без бит Рәсәй үзәгендә
Яшәмибез зрәгә.

Тәрәзәмне ачып куйдым,
Балкысын кояш нуры.
Физик көч кайтсын татарга,
Киңәйсен спорт кыры!

Парлы тәрәзә уйдырдым
Өй-нигезем – түрбашка.
Татарстаным торырлык
Күз өстендәге кашка!

Алланып аткан алсу таң
Тәрзәмә карый туры.
Чистарсын каны татарның,
Яңарсын милли җыры!
-------------
* Халык көенә җырлана.

**Уйда – ташлар**
*(Баллада)*

Санкт-Петербургның нәни геройларына багышлап Ковалёво поселогы янында «Тормыш чәчәге» исемле һәйкәл куелган. Ак каеннар утыртылган дуслык аллеясы һәйкәлне блокаданың бөтен авырлыгын кичергән Таня Савичева көндәлеге белән тоташтыра.

Аптырашта ташлар:
Гади сүзләр
Таш тәннәргә сеңгән, нур булып.
Гади сүзләр,
Гади эшләр кебек,
Тарихларга керә ургылып.
Гади сүзләр
Тарих белән бергә
Сыкрана бүген, уйлана.
Гүя ташлар,
Иминлекне саклап,
Иртә таңда тетрәп уяна:
Нигә әле, нигә тәнебезгә
Кеше сурәтләре уймыйлар?
Йә булмаса,
Өтеп ала торган
Утлы сүзләр язып куймыйлар?
Нигә әле гади бер сабыйның
Гади сүзен безгә язганнар?
Без ташларны, көндәлекләр итеп,
Тарих сукмагына салганнар.
Кем ул Таня?
Таня Савичева?
Дәверләрне үтеп атларлык?
Нәрсә язган соң ул
Көндәлеккә,
Һәммә кеше отып ятларлык?..

* * *
«...Ленинград*.
1942 ел.
Январь... март, апрель, май ае –
Савичевлар үлде...
Таня берүзе калды...»
...Гади сүзләр, гади эшләр кебек,
Таш тәннәргә сеңгән, уелган.
Ә күпме җан,

Күпме мирас, хезмәт
Киләчәген күрми җуелган...

* * *

Таня балам,
Терел хыялымда,
Китик әле Питер буйлатып!
Киләчәген кемдер бага булыр,
Чегәннәрдән карта уйнатып.

Ә безнең юл бакмый-нитми туры,
Күрәзәче нигә пакь җанга?
Сабыйлыгың белән үлемсез син,
Садәлегең белән гел яңа.
Башың җиткән әнә, теркәгәнсең
Кемнең кайчан вафат булуын.
Күз алдына китерәм дә уйлыйм
Язган саен күңелең тулуын...

---------------------

* Ленинград – хәзерге Санкт-Петербург шәһәре.

* * *

Петербург – фонтан каласына
Сокланмыйча кемнәр чыдасын?
Гүзәллеккә нигез салган чакта
Укылмаган әллә догасы?..

Укылмаган...
Бисмилласыз эшне
Кабул итә шайтан, шатланып.
Догасыз эш – хәерсез эш. Имеш,
Буыныңа китә – вакланып...

* * *

Аптырашта дөнья –
Каты токым хәтта
Тетрәнә бүген, уйлана,
Салкынлыгы белән сыкранып,
Таш булып таш таңда уяна.

Гади сүзләр –
Гади бер баланың
Фаҗигасы, ачы язмышы.
Ә чынында сабый сурәтендә

Сөйли ташлар
Тарих ялгышын!..

**Пицунда наратлары**

Балалыктамы әле сез,
Пицунда наратлары?
Тормышыгыз агышының
Әллә үсмер чаклары?

Картлык елларына, бәлки,
Кергәндер кайберегез.
Егетләрдәй төз буегыз,
Яшәртә сезне диңгез.

Шаулап үсеп утырасыз,
Диңгез буйлары тулып.
Сезнең янга киләбез бит
Без дә, яшәрмәк булып.

**Тәвәккәлләр**

Тәвәккәлгә бәхет юлдаш, диләр,
Тәвәккәлне чынлап мактарлык.
Тәвәккәлләр хәтта ялгышса да,
Кыюлыгы өчен акларлык.

Тәвәккәлләр, әйе, таш ярадыр,
Баш ярылыр диеп тормыйча.
Утка пешеп,
Суга төшеп яшәр,
Тукталмас та, бәлки, сынмыйча.

**Әби патша күпере**

1766 елда Минзәлә шәһәре янындагы Минзәлә елгасы аркылы Екатерина II тимер күпер салдырган.
*Автордан*

Тимер күпер – Әби патша эше,
Челтәрләнеп тора читләре.
Бабай түгел, әби булса да ул,

Бикләмәгән милли чикләрне.

Мәчет салган татар.
Шуннан килеп
Жалу киткән Әби патшага:
– Манарасы чиркәүдән дә биек,
Долой... Налог!.. Күккә ашканга...

– Ә юк, – дигән, Әби патша әйткән, –
Мин аларга бары җир бирдем.
Ә Күкләргә бер Аллабыз хуҗа,
Күкләргә мин хуҗа түгелмен...

**Илгә кайтсын**

Бар ямемне бирәм гөлләремә,
Тир суларым түгәм җиремә.
Ак чәчәккә чумган яраннарым
Урын ала бакчам түрендә.

Бар көчемне бирәм хезмәтемә,
Куәтемне салам җырыма.
Моң-миһербан тулган шигырьләрем
Чәчәк атсын иҗат кырымда.

Кылган эшем җирне сафландырсын,
Бер тамчысы булып диңгезнең.
Тәрбиясе булып илгә кайтсын
«Әдәп-Иман» дигән зур сүзнең!

**Комганга мәдхия**

Күренекле полководец Михаил Фрунзе, Аксак Тимернең сугыш тактикасын өйрәнеп, үзенең һәр сугышчысына комган йөртергә кушкан. Юынып йөрү нәтиҗәсендә аның атлы гаскәрләре юлны күпкә артык үткән.

Медицина фәннәре докторы, профессор Зәйнәп Якупова: «Татар хатын-кызларында гинекологик авырулар сирәк очрый, комган коткара», – дип язган.

*Автордан*

Дөнья тулы сер, илаһым,
Әйтик, гади бер комган.

Эчләренә госел кояр
Көмеш сыман су тулган.

Энҗе-мәрҗән салып, кайчак
Җир астына күмгәннәр.
Ат менгән сугышчы ирнең
Иярenә элгәннәр.

Тәһарәтле җайдак юлны
Бермә-бер артык узган.
Хатын-кызның да пакьлеген
Саклап торган шул комган.

Чисталыкка чыганак ул
Вә серле көчкә ия.
Бу шигырем мөселманның
Комганына мәдхия!

**Горур идем...**

Горур идем,
Түгел үземә күрә...
Башкаемны иеп килдем сиңа, түрә.
Инәлепләр сорыйм: ярдәм әйлә,
Балакаем үлә, балам үлә...

Үзем түгел,
Сабый хакларына
Гозеремне тыңла, тыңласана, түрә!
Иренеп әйткән бер әмерең җитә,
Синең кулда бүген тылсым-сүрә.

Йөз суымны түгеп басып торам,
Ярдәмеңне боер, ялварамын, түрә.
Горур башым – аяк асларында...
Балам тернәкләнә,
Җаным үлә...

**Дусларым***
*(Җыр)*

Йөгереп килдем Идел ярларына,
Сикереп төшим диеп суларга.

Дөрләп янган ялкыннарым басса,
Җиңел булыр иде суларга.

Сулар сибеп, янган утка кереп
Басылмасын күргәч кайгымның,
Хәлем бетеп, дуслар җилкәсенә
Авыр башым белән кагылдым.

«Сабыр бул!» – дип, якын дуслар
әйткән
Йомшак сүзләр күзне ачтылар.
Дусларымны күреп янәшәмдә,
Кайгыларым ташлап качтылар.
------------
* Шамил Тимербулатов көе.

**Елмаю көче**

Эшләрем уңмаганда,
Ярдәмчем булмаганда,
Дошманнар дулаганда,
«Бүреләр» улаганда,
Гайбәт тик тормаганда,
Йөзгә кот кунмаганда,
Бәгырем сызлаганда,
Беркем кул сузмаганда –
Син елмайдың Кояшым,
Яктыртып күз карашым!..

Күтәрдем түнгән башым...

**Ак бишектә**

Туган илем –
Ак бишегем –
Таң нурына эленгән.
Минем гомер, бәһа сорап,
Тылсымчыга күренгән.

Тылсымчы карап торган да,
Имеш, коңгырт күземә:
Терки барсын, дигән, сүзен,
Шифа бардыр сүзендә.

Тауга менеп таш булмас та,
Ләкин гади зат түгел.
Чишмәсе бар – мөлдерәмә...
Чайпалып тора күңел...

Менә шулар –
Ак бишектә
Тылсымчы сөйләгән сүз.
Инде килеп, йөрәккәем,
Чайкап-чайпалуга түз!

**Бала туды**

Галибанә яктырып
Ал таң аткан чагында,
Сандугачлар җиһанга
Моң тараткан чагында,
Зилзиләләр куптарып
Үзе яткан карында,–
Җанлыдан җан яралды.

Чәчәкләр баш калкытып,
Нурга күмелгән мәлдә,
Бар табигать уянып,
Җырга төренгән мәлдә,
Бәгырьне парә-парә
Җан ачысы телде дә,–
Җанлыдан җан яралды.

Җанлыдан җан яралды,
Җиргә-күккә, тирә-юньгә
Яңа аваз таралды.

Яңа аваз таралды,
Сират күпере кичкән Ана
Бер рәхәт сулыш алды...

Бар матурдан матуррак,
Кыйммәтледән кыйммәтлерәк,
Үз җаныннан газизерәк
Бала тудырды Ана.
Бүген таңда дөньяга
Кеше тудырды Ана!

**Җыр кайта**

Күркәм йола,
Бәби кайткан йортка
Бер-бер артлы керә күрше-аршы.
Һәркем ризык белән, аш-су белән,
Китерәләр шулай бәби ашы.
Рәхмәт сезгә, мең рәхмәт сезгә,
Кардәшләрем, түрдән узыгыз.
– Ата-анасы –
Алтын канат белән
Үссен, диеп, күрше кызыгыз,–
Телисез ич әнә.
Изге теләк һәркем күңелендә.
Төкле аягың белән, әй, нәни кош!
Аваз салдың бүген өемдә...

Күркәм йола...
Бәби кайткан йортта –
Ягымлы сүз, иркә, наз, кадер.
Бәби кайткан йортта кыш өстендә
Чәчәк ата кызыл канәфер.
Бәби кайткан йортка шатлык кайта,
Сөю, сөелү кайта, нур кайта.
Бәби кайткан йортка мең мәшәкать белән
Күкрәкләргә тулып җыр кайта,
Җыр кайта!

**Табигать җимеше**
*(Җыр)*

Син минем нәнием,
Табигать җимеше.
Синдә Җир шарының
Йөрәге тибеше.

Синдә ул кояшның
Якты, саф нурлары,
Син булсаң ямьләнә,
Нурлана Җир шары.

Күлләрдәй серледер

Күзләрең карасы.
Күзеңә төбәлгән
Туган ил карашы.

Син минем нәнием,
Табигать җимеше.
Синдә Җир шарының
Йөрәге тибеше.
--------------
* Риф Гатауллин көе.

**Изге җыру**
*(Җыр)*

«Йөрәк парәм» диеп җыр башладым,
Бишегенә аның кагылгач.
Гөлләр тама икән телләреңнән,
Сабыеңа шулай табынгач ла,
Сабыеңа шулай табынгач.

Газизләрдән газиз кемнәр газиз? –
Үз баласы газиз анага.
Күкрәгенә сабый сарылганның
Йөрәккәе сыймый далага шул,
Йөрәккәе сыймый далага.

Ак биләүгә төргән нарасый җан –
Сабыйлыгы белән сылу ул!
Дөньяларны иңләп таралган җыр –
Бишек җыры – изге җыру ул, һай,
Бишек җыры изге җыру ул!
------------
* Мәсгут Имашев, Бату Мулюков көйләре.

**Онытым биргән бәхет**

Балалык бирдең, табигать,
Үсмер чагым да булды.
Җитү кыз идем,
Ә аннан...
Башым уй белән тулды.

Ана булдым.

Кызым туды... –
Әби булдым бүгеннән.
Бар йолдызлар кояш булып
Балкый кебек күгемнән.

Кодрәтең зур, и табигать,
Шәфкать чыганагың киң.
Бер оныгым биргән бәхет
Мең кояш назына тиң!

**Нурлы бала**

Кулларыңа каләм алдың,
Әй, нурлы бала.
Сурәт сыздың, шигырь яздың,
Син – нурлы бала!
Шигырьләрең җырга күчәр,
Әй, нурлы бала.
Иңнәреңә канат үсәр,
Син – нурлы бала!

Пумалаңда сары төсләр –
Кояш төсләре.
Каләмеңдә зәңгәр кичләр –
Диңгез өсләре.
Аллы-гөлле бизәк төргән
Урман-болынны.
Таң җилләре куа чыккан
Җитез колынны.

Язган шигырь, җырларыңда
Әнкәң назлары.
Сурәтләрдә туган якның
Көзе, язлары.
Иҗат дәртең сүрелмәсен,
Уйлы, уйнак бул.
Балачагың бакчасында
Җырлы йомгак бул!

Кулларыңа каләм алдың,
Әй, нурлы бала.
Сурәт сыздың, шигырь яздың,
Син – нурлы бала!

Шигырьләрең җырга күчте,
Әй, нурлы бала.
Иңнәреңә канат үсте,
Син – нурлы бала!

**Нишләп әле?**

Нишләп әле мин бәхетсез булыйм? –
Томрап торган ике кызым бар.
Туганнарым килә,
Өстәлемдә
Чәй-шикәрем, ипи-тозым бар.

Нишләп әле мин бәхетсез булыйм? –
Әткәм-әнкәм исән чагында.
Дөньяның бер кадерлесе ич мин,
Кайткан чакта туган ягыма.

Нишләп әле мин бәхетсез булыйм? –
Моңлана һәм уйлый белгәндә.
Өлешемә тигән көмешемне
Аем итеп күккә элгәндә?!

**Һаман син кирәк!**

Мин үзем дә күптән әни инде,
Ләкин, әнкәй, сине сагынам.
Сәбәпсез дә сәбәп уйлап табып,
Синең яннарыңа ашыгам.

Мин үзем дә күптән әни инде:
Мәшәкатьләр, борчу, сырхаулар.
Яннарыңа кайтып килсәм генә,
Тәмле була ашлар, йоклаулар.

Мин үзем дә күптән әни инде,
Ләкин, әнкәй, һаман син кирәк.
Авырма әле, әнкәй-әнкәччәем,
Бергә типсен безнең бу йөрәк!

**Әнкәемә тиң түгел**

Әнкәем көлгән чагында,
Йолдызлар ява күктән.
Шул йолдызлы минутларны
Чыгарып булмый истән.

Әнкәемнең күңел күзе
Күрә һәрбер сагышны.
Әнкәемнең йөрәк кылы
Ишетә җан тавышын.

Эчке дөньясы сафлыгы,
Иманлы, керсез күңел –
Минем өчен башка беркем
Әнкәемә тиң түгел!

**Сискәнү**

Сүтелеп төшкән ике толымым.
Хастаханә – яткан урыным.
Шакыдылар:
– Түрдән узыгыз!
Ак биләүдә, апа, кызыгыз.

– Тулып кына пешкән бу алмам,
Үземә бир, газиз бер Аллам,
Бөтен чирен,– диеп,– баламның! –
Өзелүен күрдем анамның.

– Чәчкәйләрең төсле биләвем,
Башкаемның бетми гүләве,
Аяк астындагы бәладән
Хастаханә менә янәдән, –
Дип әнкәмә хәлем сөйләдем,
Күз яшьләре белән түләде.

Син сыеңда әле, сыеңда,
Кайгы килде әмма быел да...
Ничә бала – борчу шулкадәр.
Җил сызгыра,
Чү, дип, ни хәбәр?
Сискәнәдер ана йөрәге,
Ваемсыздыр, ай-һай, сирәге...

**Хәтфә юл**

Иңнәремнән сыйпап сөйгән кул –
Газиз әнкәм, газиз әткәм ул!
Иңнәрем буш – сихәт-җылысыз
Сагындыра иркә, җылы сүз...

Иңнәремнән сыйпап сөйгән кул –
Үткәннәрем, нурлы хәтфә юл.
Тәгәрәшеп үскән биш бала,
Тар сукмаклар иде, киң дала.

Иңнәремнән сыйпап сөйгән кул –
Сагыш-хатирәләр ай-һай мул.
Күпме сагынсам да, мин – сезсез...
Әткәй, әнкәйләрсез – күңелсез.

**Үз сөягең**
*(Танышым фаҗигасе)*

Аяк атлавымнан танып алган
Әнкәемнең мин бер сөйгәне.
Үз сөягең кайтты, тагын кайтты.
Әнкәй-бәгърем, ә син өйдәме?

...Ишек шакыйм, әнкәй, ник дәшмисең?..
Юк, дәшмәссең инде гомергә.
Авылдашлар, туган-тумачалар
Өлгергәннәр сине күмәргә.

Өлгергәннәр...
Ә мин өлгермәдем
Соңгы сулышыңда күрергә...
Әйтә идең: «Боз акканда үлсәм,
Тилмерерсез кайтып керергә...»

Кайтып җиткәч, аргы ярда калдым,
Язгы ташу бүлде – күпер юк.
Мең чакрымны бер сәгатьтә үттем,
Йөз адымны үтәр әмәл юк.

Алдан белеп, күреп әйткәнсең син,
Тирән серләр бәйли ананы...
Йөрәгемдә әрнү... –

Кар суы да
Юып төзаталмас ярамны!

**Чечняга – ут эченә**

Мин – Чечнядан исән кайткан
Солдат егет,
Хезмәт иттем өч ел буе,
Кан-тир түгеп.

**1**
Безнең яшьлеккә хезмәтнең
Хәвефле чагы тиде:
Кайчагында исән калу
Үзе могҗиза иде.

Тәҗрибә юк, юк аксакал,
Кемнәрдер каннан курка.
Табарга, өзәргә кирәк,
Без тотмасак, ул йота...

Югалттык күп яшьтәшләрне,
Югалттык чын дусларны.
Киләчәктә дәүләтләрнең
Булмасын кан дошманы!

**2**
Кан елап мине озаттың
Чечняга – ут эченә.
Елама, исән кайтам мин,
Дидем күңел өченгә.

Иң авыр минутларымда
Син искә төшә идең.
Аллага таян, улкаем,
Без – өчәү, дия, идең.

Рәхмәт, әни, әнкәй генәм,
Җандай хатларың өчен!
Синең изге теләкләрең
Арттыра иде көчем.

Исән-имин алып кайтты
Хәерле догаларың.

Кабул булды сорый белеп,
Өзелеп сораганың!

**Сугыш – кабер...**

Кылганнарны мәңгелек уй җилфердәтә...
Ята егет ят җирләрдә, ят төбәктә.
«Улым! Улым!» – газизенә ана дәшә.

Бер уч туфрак – ата йорты нигезеннән,
Бер уч чәчәк – әнкәсенең ал гөленнән,
Меңәр чакрым ара үтеп китерелгән...

Киңлекләрне кинәнгәнче күрәлмәгән,
Кинәнгәнче кара җирне сөрәлмәгән,
Артык иртә хушлашкан ул тормыш белән.

Һәлак булган бәхет өчен туган бала.
Сугыш – үлем, сугыш – кабер, сугыш – яра...
И кешеләр, кабер казыйк сугышка да!

**Гөлдән яралганнарга**

Ни кичерә, ниләр уйлый
Бүгенге бала җаны?
Идел аръягыннан килдек
Сиңа, Мамай курганы.

Алты яшьлек нарасыем –
Кыз балам сорау бирә:
– Әнием, – ди, – Мамай бабай
Бу таудан нәрсә күргән?

Йөгереп китә баскычлардан,
Таш диварга кагыла.
Кызыксына барсы белән,
Һаман сорау агыла:

– Бу абыйның йөрәк турын
Кем каерып йолкып алган?
Чапкан шәпкә Акбүз атның,
Нигә яллары янган?

Ник бу абый автоматын

Тешләре белән кыскан?
Ни өчен ул утта янган,
Кызыл байракны кочкан?

Үзе сорый, үзе тыңлый,
Күзләреннән яшь тама.
Гөл булып шытар яшегез,
Чөнки сез үзегез, кызым,
Гөлдән яралган бала.

Сез елыйсыз, мин шатланам,
Димәк, тоя беләсез.
Ташка уелган байракның
Ал балкышын күрәсез!

**Иркәләгез ир баланы**
*(Мөнәҗәт)*

Тауның башын болыт кисәр,
Ирнең башын мокыт кисәр.
*Мәкаль*

Ир баланы иркәләгез,
Иркәләгез сез, аналар!
Кадерле булып үссеннәр
Теләп тапкан ул балалар.

Сабый чагында сөегез
Ир баланы сез, аналар!
Явыз хатын кулына керсә,
Хасил булыр зур яралар.

Явыз хатын таптап үтәр
Өрлек кебек балагызны.
Каралтыр ак абруен
Затлы әби-бабагызның.

Явыз хатын үзе туймас,
Күзе туймас, шөкер итмәс.
Явыз белән бәйләнгәннең
Күзләрендә яше кипмәс.

Саклагыз сез балагызны,
Кыек юлдан атлатмагыз!

Күрәләтә зәхмәтледән
Сихер, бозым ашатмагыз!

Иркәләгез сез, аналар,
Ир баланы яшь вакытта.
Тормыш җиле ега калса,
Үкенмәс булып актыктан.

**Оялма!**

Калай түбәле йорт зур бакчада,
Кичен сагынып шунда килəм мин.
Әйтерсең лә тимер койма аша
Солтанаттай сының күрәм мин.

Йөгереп чыгарсың да чәчәкләрнең
Җыеп нәфис, хушбуй ислесен,
Сузарсың күк миңа бүләк итеп
Күзләреңдәй зәңгәр төслесен.

Мин алырмын.
Мин бит шуңа килдем,
Зәңгәр чәчәкләрне кочарга.
Өстәлемә куеп, сулар салып,
Истәлегең итеп тотарга.

Ирек бирмәм сиңа онытырга,
Ерак калды диеп уйлама.
Кара чәчләремне чаршау итеп
Үбеп калам, тик син оялма!..

**Хат көтәм**

Мин хат көттем
Күзе төсле зәңгәр күлмәк кигән,
Ерак калган
Кара егеттән...

Килмәде,
Күрәсең,
Йөрәкнең янганын
Сизмәде,
Көн саен хат язып

Ертканны күрмәде,
Юк, күрмәде...

Белмәде,
Магниттай үзенең
Тартканын
Белмәде,
Мин хат көттем...

Хат көтәм,
Күңелем һаман да бизмәде.
Сәбәпләр күп була дөньяда...
Әй, кызый,
Өметең өзмә әле!

**Ләззәт хисләрендә сыйланып**

Хатлар язам сиңа, минем хатны
Әкрен генә укып ал әле.
Уңай урын табып, назга талып,
Уең белән ялгыз кал әле.

Колагыңа сөю пышылдармын,
Күз алдында торыр карашым.
Минем өчен син әүлия кебек,
Күрмим, сизмим һичбер кара эшең.

Хатлар язам сиңа, хатлар язам,
Яшь-җилкенчәк кебек кыланып.
Салмак кына укы әле хатны,
Ләззәт хисләрендә сыйланып!

**Дөньяда тиңе булмаган**

Мәхәббәт камалышында
Калып сөелсәң иде.
«Син генәм!» диеп сулаган
Ярга тиенсәң иде!

Мәхәббәт камалышында
Калып кабынсаң иде.
Дөньяда тиңе булмаган
Ярга сарылсаң иде.

Камап алган мәхәббәттә
Калып кагынсаң иде.
Йолдызларга, Айга очып,
Җирдә танылсаң иде!

**Коендыр нурларыңа**

Елмаер идем көн булып,
Якты нур булып тусам.
Сайрар идем бер кош булып,
Бәллүр талларга кунсам.

Түр тәрәзәңнән сирпелеп
Керер идем өеңә.
Биер идем көннәр буе
Йөрәккәең көенә.

Моңнарыма төрер идем
Бөтен тирә-юнеңне.
Коендырчы нурларыңа
Син дә минем көнемне!

**Үзе сөя, үзе кача**

– Хәерле көн сиңа, Мөслим кызы,
– Хәерле көн, Бикбау егете!
Чү, туктап тор,
Ат юлыннан барма,
Буяла бит арба дегете.

(Ул туктады,
Ап-ак чалбарының
Балакларын куйды сызганып.
Җил күтәреп киткән җыр артыннан
Атладылар алга, кузгалып.)

– Хәерле юл Бикбау егетенә!
– Хәерле юл Мөслим кызына!
Мин ут ягам бүген, Мөслим кызы,
Йөрәгеңне сарган бозыңа!

Эретәмен

Һәм дә сөю тәмен
Сеңдерәмен кырыс холкыңа.
– Юк, кирәкми! Якыная күрмә!..
(Үзе сөя, үзе йолкына.)

– Хәерле кич сиңа, Мөслим кызы!
– Хәерле кич, Бикбау егете!
...Намусларны берүк тапламасын
Җәйге төннең кара «дегете»!

**Утырдым атыңа**

Телибез парлашып йөрергә...
Утырдым атыңа, куала!
Сокланып, сөенеп әйтсеннәр:
Тиенгән бәхеткә бу бала.

Утырдым атыңа, туктатма,
Җитик бер сахра урынга.
Юкәләр шау чәчәк,
Чәчәге бал гына,
«Ис кергән» безнең дә борынга.

Мин җитү,
Син күптән егетсең,
Данымны чыгарма, каралтма!
Саклыйк без сөюне пакь килеш,
Сакларлык булмасаң яратма!

**Ассоле идек...**

Өянкеләр пышылдашыр иде,
Тамчы булып тамса болытлар.
Чоланнарда көя җыеп ята
Безне төреп йөрткән толыплар.

Ә алар бит күпме җылы бирде
Калган чакта кара буранда.
Исәннәрдә истәлекләр күп ул,
Барысын уйлап, барлап торам да.

Басуларда кораб йөртүченең
Без Ассоле идек авылда.

Буй үстерер, сылу булыр өчен
Басып тордык күпме явымда...

Офыкларга зәңгәр җилкән элеп,
Язмыш нигә ерак җибәрдең?
Тапкан идек юкса туган җирдә
Күңелкәе белән чибәрне.

Сихерләнеп, җир читенә чаптык,
Алтын кырлар калды аһ орып.
Өянкеләр ярсып шауладылар,
Бәреп яуды яңгыр, котырып...

Йөрәкләрдә бер-бер кизү мәллә,
Сагыш сыгылып чыга җырлардан.
...Бүгенемдә бары уйлар белән
Йөгералам басу-кырлардан.

**Яңгыр җиле**

Дөньясында нигә гамем юк та
Ризыкның нигә тәме юк?
Әйтерсең лә бар да торгынлыкта.
Торгынлыкның, беләм, яме юк.

Сүзләремнең җылылыгы качкан,
Җан битараф бүген барсына.
Яңгыр җиле сизгән күңел генә
Алгысына, көтә, ярсына.

Яңгыр җиле!..
Җилләп йөрсен иде,
Дер селкетсен иде дөньясын!
Коеп-коеп яңгыр яусын иде,
Бөтен җирне итеп манма су.

Кояш чыксын иде, һаваларда
Төсле күпер салып һәркемгә.
Гөлем чәчәк атсын, һәм кешеләр
Соклансыннар иде шул гөлгә!

Дымлы җиле, бәрәкәте белән
Гөл-күңелгә кагылып элгәре,
Китсен дә ул,

Сахраларны урап,
Кире кайтсын яңгыр җилләре!

**Күрсеннәр**

Миңа каян юл тоттың?
Каян сиңа юлыктым?
Кузгаттың күңелемне,
Яктырттың бүгенемне.

Син минем көткәнемдер,
Син өмет иткәнемдер.
Язган барлык җырларыма
Мөкиббән киткәнемдер.

Санаулы көннәр иде,
Сансыз күп серләр иде.
Янып көлләргә әйләнсәм,
И дошман көләр инде.

Яныйм әле, көлсеннәр,
Көлим, көлә, дисеннәр.
Яна белгән, көлә белгән
Кыз баланы күрсеннәр!

**Кемнәре юк бу дөньяның?..**

Бар икән бәхетле җаннар,
Рәхәтенә тиенгән,
Тәнендәге һәр күзәнәк
Мәхәббәттән киенгән.

Ләззәтләргә чыдый алмый
Бар микән үлүчеләр?
Акылдан ничек шашмаган
Сине тәү белүчеләр?

Кемнәре юк бу дөньяның,
Без генә белмәгәч тә,
Эрер өчен кочагына
Атылып кермәгәч тә.

Насыйбым түгел, шулай да

Мин сине беләм икән.
Төшләремдә күрәм дә бер,
Өнемдә көләм икән.

Төшләр дә ярап куя шул
Бәхете чамалыга.
Күпсенмәгез шул бәхетне
Күңеле яралыга...

**Таптым гына***
*(Җыр)*

Җир тетрәтер көч бар кебек синең җанда,
Күк күкрәтер көч бар кебек синең җанда.
Кояш булып балкыр идем синең таңда,
Булсаң янда, минем янда һәрбер таңда!

Булсаң янда, минем янда һәрбер таңда,
Синңа табынып башлар идем иртәләрне.
Гомерем буе эзләп-эзләп таптым гына,
Ал юлымнан газапларны, киртәләрне.

Таптым гына, күзләреңә бактым гына,
Инде килеп шатланыйм да көлим дисәм...
...Миһербансыз язмыш белән килешә-килешә,
Бәгыремне үзем турыйм, үзем кисәм...

Көттем сине: җаным көтте, тәнем көтте,
Читлегеннән чыгар булып йөрәк типте.
Чишәсе сер тагы калды йомгагында,
Санаулы көн «ә» дигәнче үтте-китте...

Барлыгыңны, бу дөньяда яшәвеңне
Ник белгерттең икән миңа, ник белгерттең?
Чарасызлап, бәйгедәге йөрәгеңнән
Ник сөйдерттең икән мине, ник сөйдерттең?

Җир тетрәтер көч бар кебек синең җанда,
Күк күкрәтер көч бар кебек синең җанда.
«Аягыңа уралам да җибәрмим», – дип,
Мин йөрим ул, томан булып, синең таңда...

---------------

* Мәсгудә Шәмсетдинова көе.

**Елмайган ireннән үпсеннәр***
*(Җыр)*

Күтәреп күңелем пәрдәсен
Җил түгел, син кердең, сөюем.
Бу – минем, мәңгегә булсын дип,
Чын итеп, зур итеп сөюем.

Сөешеп яшәгән парларның
Көннәре кайгысыз үтсеннәр,
Күзләре яктылык сипсеннәр,
Елмайган иреннән үпсеннәр.

Елмайган иреннән үпсеннәр,
Юлларга түшәлсен гөлбизәк.
Тизерәк кайт, кайт минем сөюем,
Калдым ла озатып, кул изәп.

Елмайган иреннән үпсеннәр,
Ихластан әйтелсен ярату.
Иң олы гөнаһ ул кемнеңдер,
Ялганлап, йөрәген канату.

Елмайган иреннән үпсеннәр,
Илһамы күзләргә күчсеннәр.
Мәхәббәт күтәрә, үстерә,
Парлылар сөелеп үссеннәр.

Сөешеп яшәгән парларның
Көннәре кайгысыз үтсеннәр.
Күзләре яктылык сипсеннәр,
Елмайган иреннән үпсеннәр!

-------------

* Чулпан Зиннәтуллина көе.

**Сөю күле**

Телдән түгел, күзләремнән
Түгелә, моң түгелә.
Уем, буем, бар булганым
Чумды сөю күленә.

Кердем, чумдым,

Яндым, сулдым,
Дөрләми калмам инде.
Ни хәл итим, бу күлләрдән
Коры чыгалмам инде.

**Офык**

Мин җирдә бары кунак...
Җитәрмен дип йөгерәмен,
Офык, син нигә ерак?

Дәүләтем – тынчу торак.
Ымсындыра зәңгәр җилең,
Офык, син нигә ерак?

Йөрәгем тора тырнап...
Колачымны җәеп чабам,
Кил, офык, үзең, зурлап!

**Юл йөрүнең ләззәте**

Җилкәнемне җыя алмыйм,
Син тынмасаң тынма, җил.
Бәгыремне телмәсәнә,
Сулышымны бума, җил!

Җилкәнемне ботарлама,
Ярыкларга тулма, җил.
Туган төбәккә илт мине,
Туган җирдән кума, җил!

Чикли алмасам үземне
Юл йөрү ләззәтеннән,
Аерма мине, җилкәем,
Бу яшәү сәнгатеннән!

**Син – өмет иткәнемдер**

Миңа каян юл тоттың,
Сиңа каян юлыктым?
Кузгаттың күңелемне,
Яктырттың бүгенемне.

Син – минем үткәнемдер,

Син – өмет иткәнемдер,
Языласы җырларымны
Зарыгып көткәнемдер.

Яктырттың бүгенемне,
Кузгаттың күңелемне,
Җырдан алып, җырга салдың
Алдагы һәр көнемне.

Син – минем үткәнемдер,
Син – өмет иткәнемдер,
Җырланачак җырларымны
Өзелеп көткәнемдер.

**Балкысын моңсу йөзләр**

Мин җырлыймын,
Җырларымда
Чагылсын кояш нуры,
Чагылсын садә хисләрем,
Чайкалсын иген кыры.

Мин җырлыймын,
Җырларымда
Дулкынлансын диңгезләр,
Дулкынлансын бар күңелләр,
Балкысын моңсу йөзләр.

Мин җырлыймын,
Җырларымда
Шыбырдап яңгыр яусын.
Шыбырдап ләйсән коелсын,
Шатлык яшьләре тамсын.

Мин җырлыймын,
Җырларымда
Барлык халәт чагылсын,
Барлык халык дус яшәсен,
Таң тургае кагынсын!

**Вакыт – табиб**

Вакыт ул дәвалый

Һәм бүлә
Дусны дус,
Дошманны дошманга.
Аерып бирә ул буш сүзне
Һәм сүзнең тиңнәрен Иманга.

Вакыт ул, чынлап та, табиб күк,
Вәгъдәсез качалмый һич алда.
Сулышы кысыла, фаш була
Ялган да, хыянәт, хәрам да...

Вакыт ул, чынлап та, табиб күк.

**Җаның кемдә?**

Калды Кояш,
Калды таңнар,
Иртәләр...
Гамәли уй:
Арабызда киртәләр.
Өмет итмим,
Фараз кылам, тулаем...
Сагыш тулган карашыңа, тургаем,
Табып алып, кайчан мине иркәләр?

Кайда чоңгыл,
Кайда кыя,
Кайда тау?..
Ни сурәттә кайтсаң да син – юл урау.
Җанның тәнне ташлап чыгып киткәне,
Кемгә күчеп, ничек гомер иткәне –
Сорау әле,
Һаман да шул бер сорау...

**Кызларыбыз чыксын эзләргә**

Без хыянәт итмик якты язга,
Яз бит безгә юллар күрсәтте.
Шул юлларда күпме шатлык таптык,
Гөрләвекләр белән шаулап актык,
Җылы язга илттек хиссәтне.

Без җәйләргә тел тигермик әле,

Җәй җылытты алып куенына.
Нурга манды безнең карашларны,
Бүләк итте сердәш-адашларны,
Җитәр итеп гомер буена.

Ә күзләрне инде әйткән дә юк,
Нигә дисәң, күзләр көч бирде.
Тагын бер җәй, тагын бер яз, дуслар,
Бер күз әле тагын көтегез, дип,
Сыналуны безнең хуп күрде.

Кышка менә хәтта бурычлы без,
Кайнарланып салкын көннәрдә,
Урамнардан шаулап гөрләп үттек,
Без туй иттек, дуслар, без туй иттек,
Без кавыштык төштә, өннәрдә.

Без хыянәт итмик якты язга,
Тел тигермик сабыр көзләргә.
«Әнкәбезнең кайда яшьлеге?” – дип,
Кызларыбыз чыксын эзләргә:
Кышка, язга, җәйгә, көзләргә –
Баса-баса безнең эзләргә.

**Эчкән суым – таулар бәлзәме**

Баш очымда – кояш,
Битемдә – нур,
Күз алдымда – гөлләр, калалар.
Тирә-юньдә төсле шарчык кебек
Йөгерешә нәни балалар.

Аяк астым – газиз Туган җирем,
Эчкән суым – таулар бәлзәме.
Кавемеңнең кадерлесе булып
Яшәүләре үзе – җан тәме!

**Насыйп булсын***
*(Җыр)*

Насыйп булсын очрашулар тагын безгә –
Уздык күңел түрегезгә.
Күңелегезнең түре иркен, якты икән,

Чын яз икән күңелегездә.

Насыйп булсын ул язларны бергә күрү,
Бәйрәмнәрдә бергә йөрү.
Сөенечтән бергәләшеп уйнау-көлү,
Күңелләрне җырга төрү.

Насыйп булсын нигъмәт тулы табыннарда
Тагын шулай җыйналырга.
Яхшылыктан, якынлыктан, җырдан-моңнан
Җирдә мәңге сыйланырга!

-------------

* Риф Гатауллин, Рәшит Гобәйдуллин, Рөстәм Сәрвәров көйләре.

**Җилкә белән җир күтәрә**
**Илен яраткан бала.**

**Галиҗәнап әнкәй**

Дөньяны мәхәббәт коткарыр.
*Тереза-ана*

*Әнкәем Закирә Сабировага һәм ирләрен Бөек Ватан сугышына озаткан барлык аналарга*

**1**

Алиһә дә, ханбикә дә түгел,
Син – гап-гади татар килене.
Гомер иткән йорт-җиреңә әллә
Күңелеңнән нурлар иңдеме?

...Бала булып яшәгәнсең башта
Тапкан, баккан газиз әнкәңә.
Сабый булып барып сарылгансың
Ирек яулап кайткан әткәңә.

Зифа булып үсеп җиткәнсең дә,
Килен булып, килеп иңгәнсең.
Ярсу җанлы, дәртле, мәхәббәтле
Иргә хатын була белгәнсең.

Таңнан торып казан аскансың син,
Иген чәчеп, урак ургансың.
Әмма җирнең һәрчак уртасында
Син булгансың һәм нык торгансың.

...Итәк тулы уллар, кызлар әнә –
Ничә җанга ана син хәзер.
Син алиһә безнең дөньябызда,
Тезләнергә әзер, бир әмер!

Син – патшасы безнең яшәешнең,
Күпме йөрәк сиңа тоташа.
Синең сөю көчле иткән илне,
Алып чыккан янган ут аша.

Син – гап-гади татар килене бер,
Син – гап-гади татар хатыны.
Син – иң бөек яшәү чыганагы,
Галиҗәнап әнкәй, алтыным!..

**2**
Бу күзләрең – күңел көзгеләрең,
Мин аларны хәзер гел эзләрмен,
Гел эзләрмен инде, әнкәем.
Таба алмам ятып еласам да,
Җир читенә китеп юлласам да,
Син бакыйга күчтең, әнкәем.

Ул күзләрең – күңел көзгеләрең,
Сөенеп кенә әйткән сүзләрең,
Искә төшеп, җанны кузгата.
Әйтелмичә калган иркә сүзем,
Күз алдында торган сабыр йөзең
Кузгата да җанны, сызлата.

**3**
Йөзлек белән туганмын мин,
Туганда ук.
Җир йөзеннән куганда су,
Куганда ут,

Саклап калган шул йөзлегем,
Иткән ярдәм.
Йөземне ак саклар өчен
Япкан пәрдәм!

Йөзлек белән туганмын мин,
Туганда ук.
Башымда – уй, җанымда – җыр,
Йөрәктә – ут.

Ярты юлда туктап калмам
Бер эштә дә.
Рәхмәт яусын әнкәемә,
Йөземне ак иткән кешем –
Фәрештәмә!

**Әткәемнең яшьлек эзе**

*Фин һәм Бөек Ватан сугышларының башыннан ахырына кадәр катнашып исән кайткан әтием Мөхәммәтулла Шәрифуллинга*

**1**
Җил тузгыта ап-ак чәчен әткәемнең,

Моң сызлата ап-ак күңелен әткәемнең.
Үткән юлы, яткан кыры, йөргән җире,
Туфрагына сеңеп калган йөрәк җыры.

Сеңеп калган дуслар җыры белән бергә
Каны тамган Рәсәй дигән изге җиргә;
Таш стена булып баскан: ниргә-ниргә,
Ил уллары белән ул да иңне иңгә.

Иңне иңгә куйган өчен егылмаган,
Рухлары да бергә булган, сыгылмаган.
Иманын ул саклап калган зур утлардан,
Изге антын бер мәлгә дә онытмаган.

Онытмаган!
Ничә еллар үткән инде...
Бу урыннар – әткәемнең йөргән җире,
Яшьлек эзен эзләп гүя килде бире...
Чал чәчләрен тузгыта чал дала җиле.

**2**

Әткәем узган юллардан
Йөрим, йөрим уйланып.
Кан-яшь тамган җирдә үскән
Кылгандай дулкынланып.

Бу күзләрем ник елмая? –
Елыймын бит эчемнән.
Көйрәп китмәсме даласы
Дөрләгән уй-хисемнән?

Җил әз генә хәбәр бирсә,
Тере җандай кылганнар
Ташланалар уңга-сулга:
«Исәнме, – дип, – туганнар?»

Ары чабып, бире килеп
Әйтә кебек кылганнар:
«Белегез тыныч тормышның
Кадерләрен, оланнар!»

Әткәм сугышкан җирләргә
Килдем, йөрим уйланып.
Кан-тир тамган җирдә үскән

Кылгандай дулкынланып.

**3**

Үзем күрдем,
Үз күзләрем белән –
Ничек шадраланган җир йөзе;
Кагылмагыз миңа,
Дигән сыман,
Әткәм йөри, йөри берүзе.

Үзем күрдем,
Үз күзләрем белән
Окопларны, бомба чокырын.
Үзәгенә кадәр
Янганмы җир?
Әби чәче үсә котырып.

Әткәм йөри
Шадра биеклектә,
Нидер җуйган кебек эзләнеп.
Фронт сызыклары
Үткән урын –
Шәһитләргә дәшә тезләнеп...

Әткәм йөри,
Әткәм – биеклектә,
Тимгел-тимгел монда җир йөзе.
Шаклар катып,
Өнсез торган чакта
Ныклык бирде аның бер сүзе:

– Булды хәлләр.
Дошман безнең илдә
Сынамаган корал калмады.
Чикләребез янды,
Йортларыбыз...
Иманыбыз ләкин,
Иманыбыз,
Иманыбыз безнең
Янмады!

**Әбием күңеле**

*Якын әбием Бәгъделбанат Шәрифуллинага һәм ерак әбием Шәмсениса Сабироваларга*

**1**
Җир җиләге төшкән ак күлмәгең
Бала итәк белән тегелгән.
Зәңгәр читле батист яулыгыңа
Болын бизәкләре түгелгән.

Йодрык кадәр гәүдәң, әбекәем,
Учка куеп, өскә чөярлек.
Синнән туган уллар өрлек кадәр,
Түбәләре күккә тиярлек.

Бәйләм-бәйләм покрау чәчәкләре
Һәммәбезгә аерым җыелган.
Безгә диеп җиләк-баланыннан,
Миләшеннән кагың коелган.

Оя-оя казлар, үрдәк-кошлар
Оныкларга атап куелган.
«Төсем итеп, сагынып бәйләрсез бер,
Инде калмам, – диеп, – быелдан».

Кайткан саен йә бер яулык бирдең,
Йә алъяпкыч – үзең чиккәнне.
Көтә идең җәйләр саен безне,
Язлар саен бәбкә типкәнне.

Бары – бергә, югы уртак булган,
Әбекәем, синең милкеңдә.
Сеңдергәнсең олы хөрмәт хисе
Ипекәйгә – яшәү күркенә.

«Валчыгын да җиргә төшермәгез,
Гөнаһысын кая куярсыз? –
Күңелләрдә һаман шул сүз йөри: –
Бисмилланы әйтсәң туярсыз».

Ипкә дәшкән чагың бик күп булды,
Йөз чөерден хәмер кебектән.
Тәмәкене күз алдында тарту
Әшәкелек иде электән.

Ап-ак төскә киендерде сине

Кадер киче,
Туйлар,
Гаетләр.
Ак намазлык өсләренә чүккән
Ак җаныңны кемнәр гаепләр?..

Очты-очты ап-ак карлар белән
Ап-ак җаннар очты, күз җиткәч.
Башларыңны ташка орсаң да син,
Кайтмый алар, кайтмый, бер киткәч.

Соңгы юлга чыга тыныч кына
Әүлиядай җанлы әбиләр.
Тәүбә, тәүбә!
Исән була күрсен –
Әбекәйләр булыр әниләр!

**2**
Син сөйләгән әкиятләрдә
Чәчәкләр җирдә иде.
Балык сурәтләрдә түгел,
Елгада, күлдә иде.

Син сөйләгән әкиятләрдә
Диңгезләр зәңгәр иде.
Юл буйлары бәбкә үлән,
Егетләр мәргән иде.

Син сөйләгән әкиятләрдә
Гөлләр хуш исле иде.
Хәтта киек җанварлар да
Мәрхәмәт хисле иде.

Син сөйләгән әкиятләрдә
Изгелек савап иде.
Тарактан үскән урманнар
Савапка җавап иде.

...Кирәксенмибез шифасын,
Яңгырын, чиста карын.
Кайсы әкият сыендырыр
Без яшәгән Җир шарын?

**3**
Үзгә бер йолдыз ул,

Хыялый кубыз ул –
әбием күңеле.
Сер чыкмас йозак ул,
Акыллы тозак ул –
әбием күңеле.
Шифалы угыз ул,
Һаман да яшь кыз ул –
әбием күңеле.
Йөгерек юллар ул,
Дәһшәтле еллар ул –
әбием күңеле.
Тулы бер авыл ул,
Шигъри давыл ул –
әбием күңеле.
Нәселнең яме ул,
Изгесе, гаме ул –
әбием күңеле.
Күз яшьле тарих ул,
Иң мәһшүр табиб ул –
әбием күңеле.
Мәкамле намаз ул,
Моң тулы азан ул –
әбием күңеле.
Мөкатдәс инсан ул,
Төкәнмәс җиһан ул –
әбием күңеле.
Соклангыч бәхет ул,
Нур тулы тәхет ул –
әбием күңеле.
Әкияти сандык ул,
Халык күк сабыр ул –
әбием күңеле!

**Нурсолтан**
*(Җыр)*

Өч ханның – Казан ханнары Хәлил белән Ибраһимның, Кырым ханы Миңлегәрәйнең хатыны;
Казан ханнары Мөхәммәтәмин белән Габделлатыйфның әнисе Нурсолтанга

Идегәй батыр нәселеннән
Килә аның тамырлары.
Каһарман шәҗәрәсенең

Нурсолтан – бер тармагы.

Кушымта:
Нурсолтан – затлы, зыялы.
Нурсолтан – нур солтаны.
Олуг нәсел дәвамчысы,
Төрки-татарлар даны!

Өч ханның зирәк бикәсе,
Ике ханның әнисе.
Хаҗия, оста дипломат,
Исеменә тиң җисмисе*.

Кушымта.
Сөембикә сеңлесеннән
Нәкъ йөз яшькә өлкән ул.
Шөһрәтле дә үткән юлы,
Хәсрәте дә булган мул.

Кушымта.

----------------------------
* Җисемгә (бу очракта: исемгә) мөнәсәбәтле зурлык.

**Сөембикә**
*(Баллада)*

*Казанның соңгы ханы Сөембикәгә*

Йә үзен, йә яманатын сатып,
Җәдәлләшеп хатын-кызы белән,
Түрәләрен сүгеп йә табанын үбеп,
Вакланды ла безнең ирләр гелән...

Акылдан без, шөкер, язмадык...
Тик тарихны дөрес язмадык...
Алган дошман безнең каланы,
Үзебезгә яккан яланы.

Хәбәр салып куйган Мәскәүгә:
Кулга төште Казан каласы!..
Һәйкәл кагып куйган Казанга:
Җиңелде, дип, татар агасы...

Тарих – дәрья,
Еллар – дулкыннар,
Агалар да җанга кагалар.
Үткәннәрнең утлы еллары
Исегездә калсын, балалар!

Баш очында ага ак болыт –
Болыт өсләрендә ак бикә.
Күз яшьләре гүя шарлавык,
Яңгыр булып явып ул үтә.

Җил сызгыра, бәрелеп-сугыла:
Сө-ем-би-кә-ә!.. Би-кә – кайтаваз.
Табигать тә сизә, сызлана,
Эчләрендә сыза моңлы саз:

Әсир китә Ана, Ханбикә
Яшь баласы белән Иделдән.
Йә кем шундый мәһәр көтала
Газиз күреп йөргән иленнән?!

* * *

Явыз патша гашыйк булган, имеш,
Сурәтемне минем күрүгә.
Мәхәббәтен кире каккан өчен
Әмер биргән корал-чирүгә.

Сугыш белән яулап алам, дигән,
Мөселманның Сөембикәсен.
Тик белмәгән канга сусау хиснең
Нәфрәткә бары күчәсен.

Мәхәббәтне корал җиңә алмый,
Көчкә карап тумый саф тойгы.
Явыз затлар хәтта сөя белми,
Явыз затлар белми хак уйны.

Чибәрлегем булды бер фаҗига,
Илгә-көнгә афәт чакырды.
Сөя белми сөйгән дуамаллар
Мәхәббәтне канга батырды.

Корбаны мин кырыс сәясәтнең
Мәкерле һәм баткак юлында.
Гади хатын, ана булыр идем

Сөя белгән чын ир кулында!

* * *

Сөембикә патшабикә
Булып торган чагында,
Дөньяның бар гүзәллеге
Булган Казан ягында.

Сөембикә йөреп үтсә
Тирә-юньгә күз салып.
Елга-сулар акмый торган,
Ярларына укталып.

Сөембикә бер эндәшсә,
Тавышына моң салып,
Сайрар кошлар тынып калган
Сайравыннан тукталып.

Сөембикә-ханбикәнең
Акылына сокланып,
Аллаһыдан саулык сорап,
Сәждә кылган бар халык!

Сөембикә-ханбикәбез! –
Халкымның йөз аклыгы,
Милләтемнең горурлыгы,
Иманымның сафлыгы!..

Тик берзаман ханбикәсез
Калган безнең калабыз.
Бу сулкылдау меңәр елга
Җитәр ачы ярабыз.

* * *

Сөембикә манарасы –
Казанның күрке, җаны.
Акыллы ханбикәбезнең
Еракка киткән даны.

Кайнар күз яшьләре юган
Манара кирпечләрен.
Бикәнең сөю хисеннән
Балкып калган эчләре.

Сөембикә моңы килә

Чал тарих төпкеленнән.
Ихтирам хисе яңара
Яз нуры сипкеленнән.

* * *

Ханбикәсен хурлап, имгәтеп,
Тозак ясап золым-газаптан.
Гайбәт йөрткән хәтта хан йорты
Һәм яшь түккән, имеш, азактан.

Ил Анасын саклый алмаган
Нинди дәүләт, нинди милләт бу?
Хатын-кызны яклый алмаган
Нинди хикмәт, нинди михнәт бу?

Бөек исем – Ана исеме,
Исбатлауга мохтаҗ түгел тик.
Шуны ярып әйтер өчен дә
Күпме киртә тора, күпме бик.

Татар акылы йөри төштән соң,
Сынамыйча халык әйтмәгән.
Шагыйрьләре шигырь, җыр язган,
Кыйсса язган, сүзе бетмәгән.

Яңгыр үтеп кояш чыккач та,
Яфраклардан коела тамчылар.
Тарихта да шәхес югалту
Фаҗигасе соңнан ачыла.

Тәрбияле нәсел-нәсәпнең
Якты нуры булган толбикә.
Горурлыгын горур күтәреп,
Мәскәүләргә тараф юл китә.

* * *

Мәскәү дигән башкалада – таш калада –
Юк беркеме Сөембикә – тол хатынның.
Тасвирларга мин кичергән ут-ялкынны
Сүзе җитмәс бер шагыйрьнең, бер акынның!..

Мәсхәрәнең аръягында – күргәннәрем,
Улкаемны тартып алып көлгәннәре.
Ирексезләп,
Урыс ясап ябь-яшь ханнан –

Йөрәгемне суырып гүя газиз җаннан.
Ыргыттылар бурзайларга өзгәләргә,
Шуны күргән бу Анага куш түзәргә!!!

...Канлы яшьләр коела көн-төн күзләремнән,
Нур да, нор да качты йөзләремнән.

Дөньяның бер шәфкатьсезен ир иттеләр,
Шул ир белән Казаныма яу киттеләр.

Шаһгали дип йөртеләдер ул зур корсак,
Хатын битле, кыска торык, озын колак.
Ук үкчәле, тук бүксәле, ил ямьсезе,
Ир затлары арасында иң тәмсезе,
Иң тозсызы, иң котсызы, кара йөзле,
Шакмак буйлы, явыз күзле, кәкре тезле,
Сөйкемсезнең сөйкемсезе, иң шыксызы –
Шул мәльгуннең куенында морза кызы.

Мондый ирдә яшәгәнче, җаның көеп,
Мең мәртәбә артыграк үлем, диеп,
Канлы яшьләр агызамын күзләремнән;
И Казаным! – телләремдә, сүзләремдә.

И Казаным! и Казаным!! и Казаным!!!
Калды синдә кадер-хөрмәт күргән чагым,
Калды көлгән, бикә булып йөргән чагым.
Калды синдә иркәемнең каберкәе,
Бармы икән инде аның кадеркәе?

Калды минем башны саткан «пәһлеваннар»,
Гәүдә олы, мәхлук бәндә кечтек җаннар.
Калды анда Хан мәчете – зур манара,
Исемемне бирәчәксез сез аңарга!

Сагынырсыз, үкенерсез, уйланырсыз,
Бәет язып, җыр чыгарып моңланырсыз.
Колмак батып, таш йөзсә дә су өстендә,
Язмышкаем булмас инде үз иркемдә...

**«Тимер» булып туа**

*Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиевкә*

**1***

Гыйлем эстәү юлларында
Юк һичкемгә ташлама.
Илбашының юл башы да
Әлифбадан башлана!

**2**
Буыннардан килә, Төрки каганаттан
Җан егәре бөек татарның!
«Тимер» булып туа балалары,
Җигелеп тартыр,
Савыктырыр һәм
Танытыр өчен Ватанын!
-----------------
* «Нәниләргә әлифба» китабына язылган култамга.

**Без – Тукайлы халык!**
*Халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукайга*

Иске Казан,
Синең урамыңда
«Донкихотлар» туе бар иде.
Тукай кебек халык улларына
Ул чакларда урын тар иде.
*Х. Мөҗәй*

Мәңгелектән килеп, мәңгелектә калдың,
Син җырларда калдың, аңнарда.
Тугры булып тарихларга кердең,
Байрак булып яндың таңнарда.

Әткәм теле булып иркәләдең,
Әнкәм теле булып назладың.
Үткәннәрдән киләчәккә китеп,
Җир әйләнә моңлы сазларың.
Чын безнеңчә итеп, милли итеп,
Йөрәкләргә үтеп, бәгырьгә.
«Зиләйлүк»ләр килә, «Тәфтиләү»ләр,
«Әллүки»ләр кайта хәтергә.

Гамәлләре, гамь-гарьләре кайта,
Рухы торып баса шул чорның.
Үлеләрне хәтта терелтерлек
Көчен тоясызмы сез җырның?

Якты исем килә дастаннардан,
Милли моңнар килә үткәннән.
Без тумыштан «Туган тел»гә гашыйк,
Туган җиргә гашыйк күптәннән.

Чишмәләрен эзләп, Кушлавычка,
Өчилегә бардык, Кырлайга.
Арабызда берәү бармы икән
Табынмаган бөек Тукайга?

Канап-канап, яраларын ялап,
Ил өстенә шифа яудырды.
Чирек гасыр гомер яшәп җирдә,
Мең ел сүнмәс ялкын калдырды!

Бәйрәм ясап күңел түрләрендә,
Пар атлары чаба заманның.
Тукайлары туганчыга кадәр
Нуры булды микән Казанның?

Нуры булды микән авылларның,
Якты җыры җиткән кызларның?
(...Очкыныннан Тукай туар кебек
Күзләрендә янган кузларның!)

Язы барның җирдә җыры булыр,
Язлар бирде Сине бу җиргә.
Зур җаннарга гына насыйптыр шул
Гасырларга үтеп керергә.

Җыры барның җирдә даны булыр,
Бәйрәмнәре булыр мәңгегә.
Без бәхетле, без шагыйрьле халык,
Без Тукайлы халык мәңгегә!

**Бибимәмдүдә**

*Габдулла Тукайның әнисе Бибимәмдүдәгә*

Кабереңә киләм изге Ана,
Күземнән – кан, җаннан яшь тама.
Чарасызлык кыскан ул заманда
Кем гаепли Сине, сүз яга?

Бәетләрең бер кырыйда торсын,

Сезнең язмыш мәгълүм чагында.
Җир упмаса, горурлану хисе
Һич туктамас халкың җанында.

Сигез оҗмах насыйп булсын Сиңа,
Насыйп булсын барлык хөрмәтләү.
Гөнаһ булыр шигырь яза торып,
Табына торып, дәхи сүз әйтмәү.

Кешелеккә син Тукайны бирдең,
Җир башында чишмә булдырдың.
Нинди теләк теләп йөрдең икән,
Нинди дога укып тудырдың?

Син дөньяга илаһи зат бирдең,
Кеше бирдең, Бибимәмдүдә.
Син дөньяга бөек Шәхес бирдең,
Шагыйрь бирдең, рәхмәт, Мәмдүдә!

**Каюм коесы**
*Мәгърифәтче, күпкырлы талант иясе Каюм Насыйрига*

Гасырларны кичеп исән калган,
Исән калган Каюм коесы.
Күпме чишмә юлын югалтканда,
Адашканда иң мул сулысы,
Насыйрилар нәсел агачының
Бер тылсымы булып,
Ядкяре,
Нуры булып изге гамәлләрнең,
Бер әдәбе булып,
Әхлагы –
Исән калган кое.
Һәм бүген дә
Тибеп тора көчле чишмәсе.
Ничә килеп,
Күпме мәртәбәләр
Сындырганнар булыр
Сиртмәсен...

Кискән саен үсеп чыккан кебек,
Тылсым көче белән кабаттан,
Изгелеккә тугры якташлары
Сиртмә-чыгырларын яңарткан.

Яңарткан да сипләп,
Ипләп кенә
Су алырга йөргән коедан.
Терек суы,
Гүя гыйлем суы
Агып чыга Шырдан буеннан.

Су бирегез,
Кирәк бер йотым су,
Кайчагында җитә бер тамчы.
И Табигать,
Каюм коесында
Шул бер тамчы саф су булсамчы!..

**Онытылмассың**
*Герой-шагыйрь Муса Җәлилгә*

Хуш, Минзәлә, синдә кунак булдым
Бик аз гына, үтеп барышлый...
*М. Җәлил*

Белмим, Муса, кунак булдың микән,
Вакыты бит туры килмәгән.
Сугыш кырларыннан Туган илең
Сине чакырып кулын изәгән.
Алып киткән канлы ут эченә
Курку белмәс батыр йөрәгең.
Дошманнарны илдән себереп түгү,
Изеп ташлау булган теләгең.
Алман илләрендә дуслар тапкан,
Юл күрсәткән үлмәс җырларың.
Минзәләдә кайнар эзең саклый
Биек бина, йөргән юлларың.
Тезгә җиткән урам пычраклары
Кәефеңне, бәлки, бозгандыр.
Бик ихтимал, әле кызлары да
Читтән генә карап узгандыр.
Һай, юк, Муса, үпкәләмә тагы,
Уйнап кына мисал китердем.
«Бер лейтенант күрсә, акылыннан шашкан
Барышняны» искә төшердем.
Ә син хәзер кайтып килсәң иде,
Белсәң иде безнең шатлыкны.

Күрсәң иде ничек үзгәргәнен
Үзең укып киткән таш йортның.
Якты истәлегең үсә генә,
Училище* белән бәйләнеп.
Онытылмассың, герой-шагыйрь Муса,
Кайтмасаң да үзең әйләнеп.
*1962*

---

* Минзәлә педучилищесы бинасына (хәзер педагогия көллияте) Бөек Ватан сугышы елларында Курск өлкәсенең Марьино хәрби-политик училищесы килеп урнаша. 1942 елда анда Муса Җәлил дә укый.

**Фикердәше, хистәше**

*Язучы Фатих Әмирханга*

Язган Тукай. Яза хәзер безнең каләм,
Фикердәше Әмирханга биреп сәлам.

Тамырлары кемнәр, диеп, сорау бирсәң,
Кызыксынып нәсел бакчасына керсәң –

Милләтемнең дан-шөһрәткә лаек заты –
Булыр берсе Тукай әйткән Шиһаб атлы.

Акчурасы, Бигиевы, Түнтәрие,
Үзе генә ни тора бит Исхакые!

Шушы затларга тоташа бер иптәше,
Фатих Әмирхан исемле чын хистәше.

Тирән милли фәлсәфәсе Әмирханның
Әсир иткән, көчле иткән шагыйрь җанны.

Рухташым, остазым, дип бәя биргән,
Шатлыкта да, кайгыда да аңа килгән.

Фатих, Тукай – милләтемнең хис остасы,
Әйдәүчесе, озын сүзнең шул кыскасы.

Берсе өчен икенчесе булган әләм,
Күп сөйләргә хәбәрем аз – шулдыр бәлам...

**Музейда**
*Шагыйрь Фатих Кәримгә*

*Ф. Кәримнең үзе Бөек Ватан сугышында һәлак булганнан соң (1945, 19 февраль) гаиләсенә җибәрелгән, хәзер Казан Үзәк музеенда саклаучы шинеленә карап уйлану*

Әйтә алмасам да тәгаен,
Сөйкемледер үзең, мөгаен.
Матур исемең хатта юл саен,
Пионерка сеңлем, Гөлчәчәк!

Пионерка сеңлем, Гөлчәчәк,
Якты булыр синең киләчәк,
Күңел сизә, серен сүтәчәк –
Барыйк әле, әйдә, музейга.

Анда шинель,
Шагыйрь шинеле.
(Һәлак булган үзе, билгеле.)
Җибәрелгән илгә, өенә
(Хәтта шуңа күңел сөенә)
Кирза итек, куен дәфтәре –
Сугыш мәхшәренең ядкяре.

Дәфтәрендә
Шигырь берничә,
Йөрәгендә калган меңничә,
Калган ак кәгазьгә төшмичә,
Поэмалар – миллион юллысы,
Дошманга ут, нәфрәт тулысы,
Ташып торган кайнар хислесе,
Аңкып торган дары ислесе,
Ярты юлда калган өзелеп,

Тал бөресе кебек тезелеп,
Шытып чыгам диеп торганда –
Туктап калган йөрәк,
Шуңарга
Язылмыйча калган мең җыры...

Барыйк әле, әйдә, музейга,
Белү кирәк көен шуларның,
Язылмыйча калган җырларның,
Чиртелмичә калган кылларның.

Сиңа язган хат бу, Гөлчәчәк,
Гасыр бусагасын кичәчәк,
Иң моңлы, иң назлы гөл булып,
Нәни йөрәкләргә күчәчәк,
Без инаныйк моңа, Гөлчәчәк!

...Соңгы ядкяр – сугыш кырыннан,
Пуля тишкән ничә урыннан...
Яу кырында калган шагыйрьнең
Хисе булып кайткан шинель бу!
*1966*

**Фаил җыры**
*Ирем, язучы Фаил Шәфигуллинга*

**1**
Бездәйләрнең мәхәббәте, Фаил,
Бездәйләрнең мәхәббәте, бәгърем,
Таһир-Зөһрә,
Таһир-Зөһрә,
Таһир-Зөһрәләргә авраздаш.
Беребез калып, беребез югалганга,
Беребез калып, беребез югалганга,
Йөрәкләрдән коела канлы яшь!

Бездәйләрнең мәхәббәте, Фаил,
Бездәйләрнең мәхәббәте, бәгърем,
Галиябану,
Галиябану,
Галиябанулардан көч алган.
Шундый сөю, шундый ярату тик,
Шундый Сөю, шундый ярату тик,
Халык җырларына күчәлгән.

Бездәйләрнең мәхәббәте, Фаил,
Бездәйләрнең мәхәббәте, бәгърем,
Ләйлә-Мәҗнүн,
Ләйлә-Мәҗнүн,
Ләйлә-Мәҗнүн дигән кыйссадан.
Фаҗигале язмыш-кичерешләр,
Фаҗигале язмыш-кичерешләр,

Бер үк калып, бер үк кысадан!

Бездәйләрнең мәхәббәте, Фаил,
Бездәйләрнең мәхәббәте, бәгърем,
Таһир-Зөһрә,
Таһир-Зөһрә,
Таһир-Зөһрәләргә авааздаш.
Беребез калып, беребез югалганга,
Беребез калып, беребез югалганга,
Йөрәкләрдән коела канлы яшь!

**2**
Синең белән оя кордык,
Бер-бер артлы кызлар туды –
Моңлы булдык, җырлы булдык.

Синең белән оя кордык,
Җил тимәсен җимешләргә –
Уяу тордык, уйда тордык.

Синең белән оя кордык,
Хәсрәт килсә, шатлык килсә –
Күкрәкләргә башны куйдык.

Синең белән оя кордык,
Оябызга мая куйдык!..

**3**
Ак уйларың күчеп балага,
Тургайларың, килеп һавага,
Сорый гүя: «Нихәл, Раушания?..»

Күңел китек, тора томанлап,
Хисләреңне укыйм гөманлап:
«Уем сездә, кызым Резеда...»

Зәңгәр күктә сыман эзләрең,
Күзләремне алмый күзләдем,
Югалтмасам иде үзләрен...

Өзелеп-өзелеп сине сагындык,
Очып китмәк булып кагындык,
Мәңгелеккә сөйдек, табындык.

Еллар имин, үсә балалар,
Җөйләнер дә алган яралар,
Ерагая бара аралар!..

**4**

Бүгенемә калган икән
Әчесе сагышларның.
Колагымда шавы тора
Син сөйгән арышларның.

Тургайларың кайтты үксеп
Яшьлегең тугаена.
Аргамакларың җилдерә
Искән җил уңаена.

Очты китте хыялларым,
Очтылар чиксезлеккә.
Кубарылып сызлый күңел,
Юрама көчсезлеккә.
Бер йолдызларга кагылып,
Бер җиргә егылдылар.
Нахак телләр күзгә карап,
Җаныңа орындылар.

...Үткәннәргә хәер-дога,
Киләчәккә мең савап.
Без сөйгәнчә сөя белеп
Яшәсен берсе кабат...

Гашыйк диңгезче егетнең
Дулкында оранннары.
Килсен иде дә кайгылар
Дулатып урамнарны,
Үтеп китсен иде алар
Гүяки язда дулаган
Сыерчык бураннары.
...Тик үтеп китсен иде дә!..

**5**

Дилбегәсен чорнап кулларыңа
Биеп торган толпар атыңның,
Әле яңа юлга чыккан идең,
Әманәтен алып халкыңның.

Күкрәк тулы җегәр-дәрман белән
Олы юлга килеп кергәндә,
Синең юмор – җыен талантсызның
Кәҗә маен чыгарып көлгәндә,
Иҗатыңа таслап салган чакта
Диңгезләрне, чирәм җирләрне,
Иркәләп һәм назлап сөйгән чакта
Ап-ак җанлы Фирүзәләрне...

Кемнәр намусында калды каның?..
Кемнәр вөҗданында вафатың?..
Туктаталмый беркем,
Чаба әнә
Син калдырып киткән сүз-атың...

Җилдерер дә җиде диңгез аша
Кайтыр тагын туган ягына –
Билен бирмәс ярсу толпарлар да
Синең кебекләргә табына!

**6**
*(Фаил Шәфигуллинны искә алу кичәсендә уку өчен язылган шигырь)*

Бу саваплы, изге кичә иде,
Сирәк була моның ишеләр.
Зурлап килгән өчен чын иҗатны
Рәхмәт сезгә, яхшы кешеләр!

Рәхмәт сезгә, ил агасы булган,
Ил хуҗасы булган зур затлар.
Бәһагезне Фаил иҗатына
Тарих саклар, халык, ил саклар.

Ә без менә – сезнең күз алдында,
Аңа бәйләнешле өч бөртек.
Туктатмаска, тугармаска диеп,
Иҗатыннан акбүз ат җиктек.

Әтием, дип горурлана белгән,
Өзелеп торган гүзәл кызлары –
Ялкын булып алар йөрәгендә
Күтәрелер Фаил җырлары!

Сүндермәбез аның учагын без,
Сүнеп калыр өчен тумадык!
Үзебезнекеннән һәрчак алга куеп,
Аның җырын башта җырладык!

**Фирүзә**

*Кызым Фирүзәгә*

**1**

Яшел чирәм чыкты хәтфә кебек
Йомшак кына, синең битеңдәй;
Алмагачлар ап-ак чәчәк атты,
Ап-ак чәчәк – ана сөтедәй.

Иренеңдәге ана сөте кебек,
Чия куаклары ап-аклар...
Ташкын булып яшәү килгән чакта
Коелгандай язда яфраклар,
Кырау тиеп кенә куырылдың
Күз алдымда, җылы куенымда,
Беренче туй хәстәренә керми,
Кунак җыйдым соңгы туеңа...

Хәтфә төсле йомшак чирәм калды
Көтеп синең тәпи эзеңне.
Бу дөньяның назлы җиле калды,
Сыйпый алмый алсу йөзеңне.

Иренеңдә калды күкрәк сөтем –
Йотылмаган соңгы тәгамең.
Кайларга соң җаның ашты, балам?
Кайдан килер назлы аһәңең?!

Аһәң булып үзе килер сыман,
Син, әнисе, аңа кул изә.
Алмагачның ак чәчәге төсле
Ап-ак идең, кызым Фирүзә!

**2**

Яңа кабер туфрагына
Тамчылары коела.
Яшенле түгел бу яңгыр,
Яшьле булып тоела.

Җилләр җиргә ятып елый,
Җилләр дә җирсиләрдер.
Җаны яралы анага
Кушылып үксиләрдер.

Табигать шуңа кайгылы –
Югалткан бер баласын.
Аңа да газиз булгандыр
Яңа туган нарасый.

Җитәр, җилләр, җирсемәгез,
Син дә, болыт, түкмә яшь.
Чык, кояш, юат ананы,
Чык, хәсрәтен уртаклаш.

«Нишлисең? Тукта!» – дип, хәзер
Язмышларга дәшимме?
...Керфекләремне көйдерә –
Яшемме бу, яшенме?

**Эзләдек, исем эзләдек...**

*Кызым Раушаниягә*

Тудырдым...
Исем эзләдек
Йолдызлар арасыннан.
Күзләре җете булсын дип
Зәңгәр күк карашыннан,
Раушания дип эндәштек
Баш балам – багалмама.
Әй, күгем!
Минем баламны
Биеккә дәш, алдама!

**Суга барам**
*Кызым Резедага*

Иртүк торып суга барам,
Чайкала чиләкләрем.
Комлы юлда шыгырт-шыгырт
Сөйләшә чүәкләрем.

Әнкәемә су кайтарам,
Чишмә сулары – чәйгә.
Тәпи йөреп китәр инде
Нәни кызым да җәйгә.

Кызым үсеп буйга җитәр,
Чишмә юлыннан китәр.
Тәүфыйгы артсын иде лә
Буе-сыныннан битәр.

Уйга чумып суга барам,
Чайкала чиләкләрем.
Кабул булсын су алганда
Теләгән теләкләрем!

**Вакыт җиткән**

*Кызларым Раушания белән Резедага*

Вакыт җиткән,
Яучылары белән
Юлга чыккан инде юртаклар.
Кызларымны туйлап биргән чакта,
Шатлыгымны кемнәр уртаклар?

Егет куенына кергән мәлдә
Алтын алма кебек кыз балам.
Мин тартынып кемгә сыенырмын,
Кемгә серем сыяр, йа Аллам?

«Ир шәүләсе – гарше күләгәсе» –
Саклап торыр яман күзләрдән.
Сөелеп кенә яшәсәгез иде,
Өстен булып юк-бар сүзләрдән.

Без күрмәгән бәхет сезгә булсын,
Балда, майда йөзсен кулыгыз.
Бер-берегезгә дөнья бәяседәй
Олы бәя биреп торыгыз!

**Гаделлек өлгесе**

*Абыем Риф Шәрифуллинга*

**1**

Гадәти иде елларың,
Көннәрең иртә-кичле.
Кояштай якты күңелең,
Таңнардай тыйнак, хисле.

Айдай ялгыз булдың ләкин,
Йолдыздай ерак тордың.
Ялгыз булуларың белән
Хәвефле ният кордың.

Гаделлек өлгесе идең,
Намуслы иде эшең.
Әмма әдәпсез явызга
Үтә алмады «тешең».

«Бергә яшәгез, туганнар,
Берлектә – бар бәрәкәт!» –
Диеп, безгә хат язгансың, –
Ай авыр бу җәрәхәт!..

Саклый алмадык шул сине,
Аңлый алмадык бугай.
Синдәй туганны кабаттан
Биралмый инде Ходай!..

**2**

Яраланды җаным,
Кайгыларда калдым,
Ак күлмәкле кышка кергәндә.
Тамды яшем, акты,
Чигәмдә чаң какты,
Абыем, сине иртә күмгәнгә.

Җан сыкрый, сызлый,
Йөрәк яна, тырный,
Башны кая илтеп саласы?
Дөнья шундый серле,
Кешеләре керле,
Фаҗигале адәм баласы.

Әче михнәт, әче,
Кемнең җитә көче,

Язмышларны узып яшәргә?
Хәбәр биреп алдан,
Саклан, диеп, саздан,
Яхшы атлар юк шул кешнәргә...

**3**
Кайгы яуды яңгыр булып,
Түбәмнән китми болыт.
Чыкты да шулчак гарасат,
Китте болытны куып.

Карыймын, җил канатында
Абыемның өрәге.
Гомер буе нәселебезнең
Булдың бит син терәге!
*2003*

**Диңгезче малае**

*Кайнагам Шәүкәт, аның улы Роман Шәфигуллиннарга*

Менә диңгез.
Малай басып тора
Моңсуланып биек ярында.
Китте кораб.
Әтисе дә китте,
Бик озакка икән тагын да.

«И дулкыннар, – ди ул, авыр сулап, –
Мин ятимме, әллә ятим сез?
Озын җәйләр тагын шулай итеп
Үтә икән инде әтисез.

Күпме сулар ага,
Күпме рәсем ясый
Нәни куллар диңгез турында.
Йөргән юлын ясап юана күк
Балалары, ата югында...

Күз нурлары бата дулкыннарга,
Китә уе ерак ярларга.
Диңгезне ул ясап дәфтәренә,
Тели кебек серен аңларга.

Әфлисундай түм-түгәрәк кояш,

Суга ап-ак тасма сузылган.
Әле сизми нәкъ шул мәхәббәтнең
Дәшәчәген ата юлыннан.

Ачулана сыман диңгезне ул,
Әтисен бик озак йөрткәнгә.
«Барма! – ди дә,
Муенына сарылып: –
Мине дә ал, – дия, – киткәндә!»

**Сажидә апа**
*Шагыйрә Саҗидә Сөләймановага*

Ай-ли, Сажидә,
Керләр чайкый сай җирдә...
*Халык җыры*

Суга карап уйларыма чумам,
Дәрья буйларына киләм дә.
Сажидә апа,
Ай-һай, керләреңне
Чайкадың син бигрәк тирәндә.

Бөтерелеп ага дәрья суы,
Кайнашалар көмеш күбекләр.
Басма өсләрендә – ак сөлгеләр,
Ак сөлгеләр
Кершән кебекләр.

Алсу түрләмәләр әйтерсең лә
Таң нурына манып алынган.
Һәркайсына сеңгән балан исе,
Алан исе сеңгән җаныңнан.

Сажидә апа, ап-ак керләреңне
Чайкагансың икән тирәндә.
Ак сурәтең калды күңелләрдә,
Пакь эзләрең калды чирәмдә!..

**Затлы әдибә**
*Ләбибә Ихсановага*

**1**

Ләбибә апа!
Синең кочагыңда
Ышык табып була явымнан,
Синең кебек сабыр яшәгәндә
Исән чыгып була давылдан!

Ләбибә апа,
Үрнәк, өлге дә Син,
Апа да Син, хәтта Әни дә!
Каләм ияләре гаиләсендә
Сокландыргыч затлы Әдибә!

Иң мөлаем,
Иң дә зыялысы,
Тәрбияле, олы җанлысы!
Шуңа күрә йөрәгеңнән тама
Әсәрләрнең тулы канлысы!

Күркәм гомер белән бүләкләнгән
Әдәп, әхлак, намус үрнәге!
Ходай тагын гомер бирсен Сиңа,
Укучыңның, каләм дусларыңның
Бу иң изге, ихлас теләге!

**2**
Балалар сафлыгы Сездә,
Изгеләр җылылыгы.
Эшсөярләр тырышлыгы,
Егетләр кыюлыгы!
Бохарада түгел, Сездә
Намлы шәфкать орлыгы!

**3**
Гомер шундый кыска,
Сиксән түгел нокта,
Җитәклә Син йөзне,
Туксаныңнан чык та!
*1993–2003*

**Күрәсе килә**
*Гөлшат Зәйнашевага*

Гөлшат апа,
Гел шат апа,

Күрәсе килә Сине,
Назлы, сихәтле сүзләргә
Төрәсе килә Сине.

Йомшак, ягымлы тавышың
Сагындырды бит инде.
Юри юксындырдым диеп,
Йөгереп килеп җит инде.

«Гайфи»ләрне өйләндерик,
«Меник Уралтауларга».
«Сандугач»ың сихәт бирсен
Җаны исән-сауларга.

Гөлшат апа,
Гел шат апа,
Юллыйм сәлам хатларым:
«Ак бураннар ярып чапсын
Җыр төягән чаптарың!»
*2005*

**Рухи тәһарәт**

*Шагыйрә Әминә Бикчәнтәевага*

Кайчагында көл дә калмый
Оп-озын гомерләрдән.
Рухи тәһарәт аламын
Сез язган шигырьләрдән.

**Бирегез мәйдан!**
*Шагыйрә Нурия Измайловага*

Туып кына киләм –
Шатланыгыз күреп.
*Н. Измайлова*

Җыр сорап типкән йөрәккә
Җилләр генә өрмәсен.
Хис кадерен белмәүчеләр
Килмәсен дә йөрмәсен.

Туып кына килгән чагы,
Һавада сөю өне.

Гашыйк күңелнең колачлап
Сафлык ташыган көне.

Мыскалланмаган ефәктәй
Асыл зат була икән.
Чат сөюдән генә йөрәк
Торса да тора икән.

...Җыр сорап типкән йөрәк бар –
Ягез, мәйдан бирегез!
Күктән төшмәгән бу бәхет –
Кадерләрен белегез!

Кычкырып җырласын.
Ә сез
Җырдан такыя үрегез!

**Рәхмәт!**
*Язучы, сәясәтче Фәүзия Бәйрәмовага*

Рәхмәт,
Түздең, чигенмәдең,
Егет, йөрәкле кыз бәнең,
Кайсыбызны борчый икән,
Ничекләр, дип, синең хәлең?

Рәхмәт,
Түздең, чигенмәдең,
Дөнья гиздең, иренмәдең.
Гомер бакый шулай булды,
Эш эшләгән күренмәде.

Рәхмәт,
Түздең, чигенмәдең,
Ука белән чигелмәдең.
Исемнәр һәм дан-дәрәҗә
Бездә гадел бирелмәде.

Рәхмәт,
Түздең, чигенмисең,
Байлык диеп тилермисең.
Күпме таптап-кыссалар да,
Гадел сүздә бирелмисең!

Рәхмәт!!!

**Ир хакы**
*Язучы Фәнис һәм хатыны Нурсөя Яруллиннарга*

Гомер бакый онытылмаслык
Изге җанлы хатыннар,
Көрт ярып киткән еракка –
Калып торган алтыннар.

Калган алтынга биргесез
Күнеккән, торган куыш.
Җан сөйгәне кайда булса,
Шунда дәвамлы тормыш.

Ирләр хакын хаклар өчен,
Ир җанын аклар өчен,
Себергә киткән хатыннар,
Ирләрен саклар өчен.

Себергә киткән хатыннар,
Җаннарын аямыйча.
Яши бүген Нурсөяләр
Замана маягыча.

Җир читенә китәргә дә
Әзер, кирәк, дисәләр.
Сокланырлар иде хәтта
Декабристлар, күрсәләр.

Татар хатынына хас ул:
Киң күңел, керсез йөрәк!
Мәхәббәтен, тугрылыгын
Бәяли белү кирәк!

Яшәү олылыгы – бакый,
Яшәү – бер гомер өчен.
Бүген декабрист хатыны –
Нурсөя, минем өчен!..

**Тукай күгендә**
*Язучы, галим-мөгаллим Мөхәммәт Мәһдиевкә*

Тауга карап, таулар булам, димә,
Соклана бел әмма тауларга!

Яраланган елның бер үксезе,
Сыенгандыр җаны сауларга.

Шигырь түгел,
Кыйсса язу тиеш
Багышлап һәм башлап бүгеннән.
Нинди генә йолдыз калыкмады
Түбәң өстендәге күгеңнән.

Тарих чокырының төпкеленнән
Табып чыгармадың кемнәрне?
Фәкать синең акыл бәян итте
Мәңге сер булачак серләрне.

ТОРНАЛАРЫҢ ТӨШКӘН УЛ ҖИРЛӘРГӘ
КЫРЫК БЕРДӘН КИЛГӘН МАЛАЙЛАР,
ФРОНТОВИКЛАР: Рушад, Хәкимҗаннар,
ИСӘНМЕ, дип КӘШФИ АГАЙЛАР?!

Пәйгамбәрлек йөген тартучыга
Ходай үзе әмер бирдеме?
КЕШЕ КИТӘ, ҖЫРЫ КАЛА, егет,
БӘХИЛЛӘШҮ кирәк, дидеме?

Бәхилләшү, әйе, авыр булды,
Ачылып калды АЧЫ ТӘҖРИБӘ.
УТ ЧӘЧӘГЕң ушны үткерләсә,
КАЗ КАНАТЫ җанга моң сибә.

Кәсмәс үзәнеңә язлар кайтыр,
Гөберчәктә гөрләр Сабантуй.
Тальян тартып, ничә Гата җырлар,
Сине сагынып өзелер ничә уй?

Үзәкләргә үтеп үкендерер,
Табындырыр зиһен-акылың –
Милләтемнең олуг Мөхәммәте,
Татарымның горур акыны!

Ихлас белән биргән гыйлемеңне
Саклый сабый күңел түрендә...
Гөберчәктә чыккан Ай-Кояшның
Нуры балкый Тукай күгендә!

**Сурәтеңне ясыйм да...**
*Язучы Нурихан Фәттахка*

**1**
Зәңгәр күк фонына бастырып,
Кояшны элеп бер почмакка,
Мәңгелек сурәтең ясыйм дип,
Ут яктым, нур сорап учактан.

Зәңгәр күк – чисталык билгесе,
Гаделлек, гадилек символы.
Син Кеше исемен йөрттең дә
Калдың шул җисемгә тугыры.

Ә Кояш иң изге, гали көч,
Кодрәте киң дә киң, ай-һай киң.
Син минем хыялым түрендә:
Шул Кояш, Зәңгәр Күк, Нурга тиң.

Ясыймын сыныңны чын итеп,
Ә аннан текәләм, таң калып.
Һай, мин дә балкысам –
Кемнеңдер
Уенда, сурәтем ясалып...

**2**
Хушлашабыз бүген синең белән,
Садрислам улы Нурихан.
Арабыздан киттең, җанны өтеп,
Күзне төбәп торган сизгер җан!

Дөрес кеше идең,
Алып кеше,
Гаделлек һәм Намус өлгесе.
Купшы сүзләр үлгәч күп әйтелә,
Ә бу сүз чын – хаклык өлгесе!

Синең үлчәм белән үлчи идек
Биеклекне, упкын, киңлекне.
Әсәрләрең өлге бирә иде,
Киңәшләрең – таймас җирлекне.

Вакланабыз ласа, арабызда
Юк Исәнбәт, юктыр Әмирхан...
Син шуларның тамыр җебе идең,

Корыч сынлы, көчле әдип-хан!

Син бит безне Кол Галидән алып
Тукайларга ялгап яшәттең.
Таң калдырып төрки дөньябызны,
Фән юлында яшен яшьнәттең.

Мең гасырның җыйдың шәҗәрәсен,
Бирде Ходай нинди түземне?
Сызгырттың да укны...
Агыздың да,
Төпләрендә йөреп, Иделне...

...Хушлашабыз бүген синең белән,
Бәхиллегең калдыр безләргә!
Уклар түгел,
Сукыр чебен бүген
Яшь чыгарып керә күзләргә...

...Февраль ае.
Чатнап торган суык!
Тик болыт юк. Юк җил әсәре –
Бу бит Синең холык, дөрес Кеше,
Аллаһының Сиңа мәһәре!

Коры суык – чын кыш билгесе ул,
Боз да, кар да бәрми йөзеңә.
Көчле рухлы сынмас Нуриханның
Сурәте бу – Җир-йорт телендә!
*2004*

**Дөлфәт**
*Шагыйрь Зөлфәткә*

«Дөл-дөл» тамырыннан синең
Исемең, газиз дустым!
Дөлфәтне биргән туфракны –
Мөслимне җанга кыстым!

Ял төпләре янып чыккан,
Шигырь аты – ак күбек!..
...Татарның шагыйрь дөньясын
Таң калдырды бу егет:

ТОМЫРЫЛЫП* шигырьләрен
Укыды Хәлимнәре**.
КӨРӘШЧЕЛӘР ЗАТЫ итеп,
Хуп күрде галимнәре.

БЕТХОВЕНЧА СОНАТАлар
Яңгырады сәхнәдә.
АЮЛАРГА – ПЫЧАК БЕЛӘН!..
Тикме?..
Ирләр – «ятьмәдә».

Күпме ярсу көч, талант һәм
Тирән гыйлем, сәгадәт!
Ихласлыгына шагыйрьнең
Кыласы бар гыйбадәт!
-----------------
*Шигырьләренең исемнәре яки аерым юллары.
** Артист Хәлим Җәләй.

**Шагыйрь үлеме**
*Шагыйрь Михаил Лермонтовка*
Ачы булгач күңелем,
Шигырем ачы чыга.
*Г. Тукай*

**1**
**Машук ***
Утлар яна Машук түбәсендә,
Әллә каян сузган кул сыман.
Дуэль урынына китергән юл –
Түземлекләр сорый юлчыдан.

Газаплану белән гаҗәпләнү,
Сыкрау белән бергә соклану –
Тамырлардан ага актарылып,
Килгән көннән бирле уйлану.

Мәһабәт тә, сылу да син, Машук,
Тик бер сукмак йөри әйләнеп...
Тарих шулай. Теркәләсең аңа,
Җәбер яки данга бәйләнеп.

Күпне күргән башың, агач-ташың
Ниләр сөйләр иде, тел белсә?

Кеше жаны ни хәзинә җыя,
Күпме газап җыя, юл йөрсә...

Кара каеш сыман,
Билләреңнән
Кара сукмак үтә әйләнеп.
Мәңгелеккә телгә кердең, Машук,
Шагыйрь исеменә бәйләнеп.

———

** М. Ю. Лермонтовның дуэльдә үтерелгән урыны.*

**2**

**Синең үлем**

Биштау* иле, кыя-ташлар иле,
Анда нәфрәт, анда мәхәббәт.
Мәңге ак һәм мәңге бөек дөнья,
Синең илең, синең мәмләкәт.

Синең дөнья – зур шигъри дөнья,
Анда хәтта таулар бәләкәй.
Ә җаныңда тархан гына түгел,
«Юылмаган» бөтен Рәсәй.

Яшен булып яшьнәдең дә,
Кодрәт белән аннан күкрәдең.
Тарханнарга гына сыярлыкмы
Шигъри өермәле күкрәгең?

Халык кирәгенә туган идең,
Бәхетенә – жаның яралган.
Ү-тер-де-ләр!..
Җан ачысы белән
Таудан тауга хәбәр таралган.

Үтерделәр.
Биштау чәчәкләрен
«Татарчонок»** каны чылатты.

---------------------------

** Пятигорск шәһәре.*
*** М. Ю. Лермонтовка бирелгән кушамат.*

Синең үлем бүгенгесе белән
Киләчәкне хәтта елатты...

Җырдан тукып тарткан ак җилкәнең
Йөзә әнә, юктыр туктыйсы.
Җирне чүпләп туган зәхмәтләрне
Тамырыннан килә утыйсы.

Тоталар да шагыйрь үтерәләр,
Күзгә карап яки сизмәстән.
Күрәкарауларның барысын бергә
Егасы иде, буй, бил бирмәстән!..

...Физик үлем оятмыни җирдә,
Рухи үлем чалып екмасын.
Кургаш түгел, тугры сүз куелган
Пистолетның тарттың чакмасын!..

...Үтерделәр.
Биштау чәчәкләрен
«Татарчонок» каны чылатты.
Синең үлем бүгенгесе белән
Киләчәкне, шагыйрь, елатты!..

**Безнең авыл бөркете**

*Авылдашым, Советлар Союзы Герое Николай Орловка (Гатаулла Минаев)*

Белегез сез һәммәгез дә
Җир шары оланнары,
Арада күп татарларның
Бөркеттәй булганнары.

Безнең авыл улын халык
Бөркет диеп атаган.
Юкса аның да нәселе
Гап-гади бер татардан.

Туып үскән Зөбәердә*,
Актаныш төбәгендә.
Туган илгә зур мәхәббәт
Яшәгән йөрәгендә!

Бөркет карашлы булган ул,
Акыллы, зирәк, җитез.
Сугыш кырында андыйны
Дошманга җиңү читен.

---
* Зөбәер – Татарстандагы авыл исеме.

**Бәхет сәгате сукты**

*Якташым Фикус Закировка*

Затлы бер китап чыгару
Теләге булган шагыйрь,
Йөреп-йөреп очын тапмый,
Өметен җуйган шагыйрь
Очрады бер якташына –
Фикус Хәсән улына,
Гүя Хозыр чыгып басты
Шагыйрәбез юлына.
Киңәшә, сөйләшә торгач,
Бәхет сәгате сукты, –
«Сөюеннән чибәрерәк»
Китап дөньяга чыкты!

**Әфсенлисең**

*Галимә Резеда Ганиевага*

Хисси касә – Шәрык илләреннән,
Сәгадәтле Сөю күлләреннән,
Гомәр Хәйям, Фирдәүсиле дөнья –
Гарәп, фарсы, төрки телләреннән.

Думавилар, Исхакыйлар белән
Әле үлеп, әле терелгәндә,
Әнкәйләрең белән намазлыкта
Җаның-тәнең акка төренгәндә –

Өлге итте Сезне күңелебез,
И мөкатдәс галим, мөгаллимә!
Чыда бүген барлык мактауларга,
Туктатыгыз, тукталыгыз, димә!

Чәчне йолкып оран салыр чакта,
«Гөрзиле»ләр көткән чакта чатта,
Галәм белән Җирне бағланышка кертеп
«Әфсенлисең», Шагыйрь җанлы итеп!

Шигъри сүзнең тәмен, кыскалыгын,

Акыл белән сөйләү осталыгын,
Фәнни телнең могҗизалы көчен,
Рәхмәт,
Безгә күрсәткәнең өчен!

**Мөгаллимә-галимә**
*Галимә Флёра Сафиуллинага*

Мөгаллимә, Сез – галимә,
Сез – минем укытучым.
Белемле кеше булсын, дип
Кайгырып ут йотучым.

Һәр шәкерт, һәр талибәгә
Мәгърифәт, нур бирүче.
Туган телне өйрәтим, дип
Йөгерүче, йөрүче.

(Ут йотучым, укытучым,
Мөгаллимә-галимә,
Мактау сүзе әйталмадым
Моңарчы бер кәлимә.)

Сез укыткан егет-кызлар
Бүген шагыйрь, шагыйрә –
Гыйлемне Сездән алсын дип,
Кызын «татфак»ка бирә.

Сез – иң мәртәбәле Кеше,
Сез – иң чын Укытучы.
Шәкертем кеше булсын, дип,
Утлы күмер йотучы!

**Беренче мөгаллимем**
*Гаиләбездәге биш баланың дүртесенә бер-бер артлы башлангыч белем биргән Гөлсем Салиховага*

Күзләреңдә – очкын, ялкын,
Йөрәкләргә учак яктың,
Беренче мөгаллимәм.
Күңел тәрәзләрен кактың,
Саф чишмәләр булып актың,
Беренче мөгаллимәм.

Син галим дә, син җырчы да,
Син рәссам, тылсымчы да,
Беренче мөгаллимәм.
Сәяхәтче, син сынчы да,
Син үзең үк укучы да,
Беренче мөгаллимәм.

Белем дигән дәрья кичтек,
Бергә үстек, бергә күчтек,
Беренче мөгаллимәм.
Якты көннең кояшы син,
Гомерләрнең юл башы син,
Беренче мөгаллимәм.

Балачакның күзе бит син,
Сабыйлыкның үзе бит син,
Беренче мөгаллимәм.
Гадиләрнең гадие син,
Мәктәптәге әнием син,
Беренче мөгаллимәм!

**Вальс бии җилләр**
*Композитор Салих Сәйдәшевкә*

Кызым, мин бит Сәйдәшне күреп беләм!..
*Әткәй истәлегеннән*

Сәйдәш, Сәйдәш,
Һәрбер күзәнәгең
Моңнан гына, ахры, яралган,
Күк гөмбәзе кебек күзләреңә
Тере очкынчыклар таралган.

Тылсым көче һәрбер сулышыңда:
Син талпынсаң – яшен җемелди,
Вальс бии, җилләр бөтерелеп,
Син ишетми калган моң йөди...

...Сокланмыйча кемнәр түзә алсын,
Баш имичә синең талантка?
Бөекләрне күреп калу да бит
Бетмәс шатлык бирә күп затка!..

**Моңның йөрәге – синдә**
*Композитор Сара Садыйковага*

**1**
Туган җиргә табынгансың,
Давыл булып кабынгансың,
Кар-бураннар ябынгансың
Көйләреңдә, Сара апа!

Күңелләрдән саркыгансың,
Ефәк нурлар талкыгансың,
Йолдыз булып балкыгансың
Көйләреңдә, Сара апа!

Гөл, чәчәк булып шыткансың,
Утлы күмерләр йоткансың,
Туфан-су булып купкансың
Көйләреңдә, Сара апа!

Шул моңнарың – кышта, көздә,
Шул моңнарың – йөздә, күздә,
Яши илдә, яши бездә,
Моңның йөрәге Синдә!

**2**
Һич китмәссең кебек иде арабыздан,
Искә төшсәң, сагыш сарка ярабыздан.
Көйләреңнән илһам алып, сихәт алып
Яши күпләр
Синнән – моңчы апабыздан!

Яшибез. Тик...
Сагынабыз, Моңсарабыз,
Апастагы Тутайга* да гел барабыз,
Хыялларга кайтарып бер терелтәбез.
Мизгел үтә –
Тагын синсез без китәбез...
--------------
* Сара Садыйкованың бабасы Әхмәдиша туган авыл. Хәзер анда С. Садыйкованың музее бар.

Һич китмәссең кебек иде арабыздан,
Искә төшсәң, сагыш сарка ярабыздан.
Бүген дә бит илһам алып, сихәт алып

Яшибез без
Синнән – моңчы апабыздан!

**Халкымның газизләре**

*Композитор Сара Садыйковага һәм аның ире югары белемгә ия беренче татар режиссёры, талантлы актёр, Мәскәү татар театрына нигез салучы Газиз Айдарскийга, кызлары, балет биючесе Әлфия Айдарскаяга*

Яшел Үзән якларыннан
Чыккан пар былбыл алар:
Газиз Айдарский һәм дә
Сара Садыйковалар.

Газиз Айдарский – мәшһүр,
Талантлы, ихлас актёр,
Югары белемгә ия
Ул беренче режиссёр.

Халык йөрәген яулаган
Кадерле, сөеклесе,
Милләтен җыр-моңга төргән
Сарадыр икенчесе.

Авыр елларда табышып,
Берсен берсе яраткан.
Әмма ләкин тормышлары
Ләйлә-Мәҗнүн, Таһир-Зөһрә
Язмышларын яңарткан.

«Газизем!» дип өзгәләнеп
Хатлар язган Сарасы.
«Саруш, сине сагынам!» дип
Җавап алган аннан соң.

Каршылык, нахак газаплар
Сызлаткан үзәкләрен.
Фәкать олы яратышу
Яшәткән йөрәкләрен.

Халкымның газиз җаннары,
Кадерле, сөеклесе –
Берсе аның Айдарский,
Сарадыр икенчесе!

Татарымның менә шушы
Ике бөек затыннан
Дәвам булып яши бер кыз –
Үзе шәхес, асылда!

Үзе дә талант иясе,
Үзе дә сәнгать колы.
Үзе дә олы җанлы ул,
Балет аккошы моңы!

Әтисе һәм әнисенең
Музейларын төзешү,
Китапларын нәшер итү –
Бар булмышы, бар эше.

Хезмәтләрен сәйлән итеп
Җыеп, бөртекләп туплап,
Һәр нотасын яңгырата,
Күз карасыдай саклап.

...Без өлгермәгән гамәлләр
Яшь буыннарга кала.
Поэма, роман темасы
Әлфия, Газиз, Сара.
*2010*

**Тыңлагыз!**
*Сүз остасы Айрат Арслановка*
Тугансыңдыр Син, бүз бала,
Шагыйрьләр бәхетенә.
Кемне генә утыртмадың
Тукайлар тәхетенә!

Агыла Сүз...
Тыңлар өченгә дип,
Сүзсөярләр бире җыелган.
Ә Арслан мәгърур –
Һәрбер күзәнәге
Бөек Шигырь белән туенган!

Тынлык әнә үзе өнсез калган,
Аның тавышына бүленеп.
Әҗәл кагылганнар, түзә алмый,
Чыгар сыман бүген терелеп.

Иманлысын,
гамьле,
гайрәтлесен
Өләшә ул,
Илтә халыкка.

Йотасың Сүз,
Йә кабынып китеп,
Әсәренеп,
Телсез калып та.

Әйтә белеп әйтелгән Сүз – назлы,
Бит очыңнан үбеп аладыр.
Ялкынлысы үзәгеңне өзә,
Каны саркып торган ярадыр.

Ә кайчакта?..
Чиртә маңгаена –
Аяк астың
Убылмаса шунда бик ярый...
Әнә шулай, агын акка куеп,
Сизгер Арсланнар Сүз сайлый.

Арсланнар кирәк булган икән,
Йөгәнләргә шигырь атларын.
Тукайгача хәтта күтәрергә
Талантларның алтын хакларын!

...Тагын кемнәр туып,
Гади сүздән
Нәкыш чигеп, сурәт төшерер?
Галиҗәнап Шигырь!
Мең бизәкле
Кыйммәтеңне кемнәр төшенер?

Агын – акка,
Күген күккә куеп,
Фатихасын биреп дәвамга,
Шагыйренә түгел,
Шигыренә карап
Агыла Сүз
Гамьле гавамда!

**Рәссам**
*Рәссам Алсу Тимергалинага*

Моңланып җәй чигә*.
Кулларың көз чигә
Кәгазьгә, ефәккә, диварга.
Кузгатып күз явын,
Сеңдереп буявын,
Тотындың җырлы юл сызарга.

Кулларың яз коя,
Кайчакта кыш сыя
Рамлы кечкенә киндергә.
Айлы төн – ал таңлы,
Таңнарда тиң парлы –
Могҗиза илендә сез бергә.

Кулларың урманнар,
Елга, тау, кылганнар
Ясыйлар күңелгә, күзләргә.
Көч алып урманнан,
Ямь табып кылганнан,
Нур куна сүрелгән йөзләргә!
-------------------
* «Чигенә» мәгънәсендә.

**Тансык тәгам кебек**

*Җырчы Гөлсем Сөләймановага*

Күпме җаннар кабат күзен ачкан,
Синең моңнарыңда коенып.
Ач елларда хәтта исән калган
Затлы җырлар белән «туенып».

Колхозларга кергән, күмәкләшкән –
Җырың ярдәм иткән күпләргә.
Сугыш кырларында гаярь уллар
Тыңдәш сизгән үзен Күкләргә...

«Салкын чишмә»ләрең ай-һай моңлы,
«Кәккүк»ләрең, «Сәгать чылбыры»...
Тансык тәгам кебек синең җырлар,
Халкыбызның моңлы былбылы!

**Милләтемнең зифа каены**
*Җырчы Зифа Басыйровага*

**1**
– Бәхете дә, тәхете дә булмас,
Бигрәк моңлы кызың, Фәрхинур*», –
Дия торган була Мөслим халкы.
Киләчәген төргән сихри нур...

Тәхеткәе олы сәхнә булды,
Бәхетен дә тапты шул юлда:
Туган халкын,
Үзенең татар халкын
Изерәтте моңлы дулкында.

Ятимлектә үсеп кеше булды
Басыйр кызы, җырчы Миңзифа.
Бригада төзеп юлга чыкты:
Мәскәү, Киев, Тула, Ош, Уфа...

Мөслименә атап җыр чыгарды,
Ыгы белән күңелен сугарды.
Йөрәк хисен «Шөгер», «Минзәлә»гә,
«Арча», «Сарман»ына тугарды.

«Хуш авылым» – визит карточкасы –
Йөрәк каны сеңгән җыруы.
Олы бәхет туган якларында
Зифа кебек затлар булуы!

---

***** *Зифа Басыйрованың әнисе.*

**2**
Исеменә җисемкәе тәңгәл,
Ихлас хезмәт итте халкына.
...Эчтән янган, көйрәп-көйрәп янган,
Әмма ләм-мим үзе хакында.

Без ахырдан белдек, соңлап белдек
Фаҗигасен, авыр тормышын.
Авыл халкы, Ыкта чагылгандай,
Әйткән икән алдан язмышын.

Күз алдында зифа каен кебек
Сәхнәләрдә басып торуы.
Кешеләрнең күпме җәрәхәтен
Дәвалады аның җыруы.

Дәвалады, дәрман, куәт бирде,
Яшәү көче бирде меңнәргә.
Ә үзенә нинди сабырлыклар
Кирәк булды икән түзәргә?..

Милләтемнең зифа ак каены,
Мөслимемнең зифа Ык талы!
Сагыш сарган моңлы йолдызларның
Иң яктысы безнең яктагы!

**Җырчы килә**
*Җырчы Хәйдәр Бигичевка*

Җырчы килә дөнья буйлап,
Җанда чаң кага-кага.
Аланнар эзләп бара ул,
Йолдызлар яга-яга.

Җырчы килә дөнья буйлап,
Тынлыкка колак сала,
Керә урманнар иркенә,
Гөлләрдән илһам ала.

Өр-яңадан туа дөнья,
Өр-яңа көн ярала.
Алиһәләр табынырлык
Илаһи хис тарала.

Җырчы килә дөнья буйлап,
Бар җиһан хәйран кала.
Моң кала көнгә сибелеп...
Мең рәхмәт, гамьле бала!

**Арабызга син килгәннән бирле**
*Җырчы Салават Фәтхетдиновка*

Арабызга син килгәннән бирле,
Сихри моңнар төреп алды Җирне.

Җырың белән иркәләдең безне,
Җырың белән әйттең йомры сүзне.

Кыз-кәмәше, сәхнәләргә узып,
Сорый, бир, дип, култамгасы сызып.
Автоярышларда очсаң кызып,
Җыр тузаны кала юлда тузып...

Күңелләргә җырлы күпер сузып,
Әбиләрнең тәһарәтен бозып,
Көлдерәсең күзгә яшь килгәнче,
Тамашачы, басып: «Бис!» – дигәнче.

Җырың белән иркәлисең безне,
Әйттерәсең йомры, кирәк сүзне.
Арабызга син килгәннән бирле
Сихри моңнар гизеп йөри Җирне!

**Мин – артист**

*Җырчы Альбина Шаһиморатовага*

Мин – артист,
Сәхнә – эш урыным,
Сезләргә, кардәшем, агыла бу җырым.
Сүзләрнең тәэсире, моңнарның шифасы
Дәвалап чиертсен йөрәкнең һәр кылын.

Мин – артист,
Сәхнә – эш мәйданым,
Айкала, чайкала, түгелә бар җаным.
Кайчакта хисләрем сыймыйча йөрәккә,
Сил булып тарала, туктала күк каным.

Мин – артист,
Сәхнә – эш биләмәм,
Мин сезгә иртә дә, кичен дә килалам.
Сәнгатьне ярату, мәхәббәт, җыр аша
Көч җитмәс эшләрне, ахыры, җиңалам.

Мин – артист,
Сәхнә – эш бәйрәмем,
Ачарга тиешмен әсәрнең бар ямен.
Егәрем җитсәйде бар дөнья халкына
Күтәреп илтергә

Тукайлы татарның зур гамен!

**Йөзек кашы**

*Җырчы Гөлзадәгә*

Милләтемнең йөзек кашы бит син,
Җыр-шигырьле күңелең ай-һай бик киң.
Бәхет басар иде татарымны,
Һәр баласы булса сиңарга тиң!

Сәхнәләргә тезелеп чыгып басса
«Сөембикә варислары»ң Синең,
Таудай хезмәт, талантыңны күреп,
Иманлысы шатланадыр җирнең!

Тарих тузаннарын сөртә-сөртә
Табып алган җырлар – «каһарман»*нар,
Ирештеләр яңа буыннарга,
Сөенеп туя алмый моңлы җаннар.

Шул җырларың кемгә тел өйрәтте,
Шул җырларың кемдә ут көйрәтте.
Шул җырларың безне күзле итте,
Синең җырлар җиргә сөю сипте.

Милләтемнең йөзек кашы бит син,
Нәкъ җырларың кебек – каһарман!
Җырла әле, иңлә дөньябызны,
Буыннарга биреп көч-дәрман!

___

**Җырчының М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында үткәргән «Каһарман җырлар» исемле концерты күздә тотыла.*

**Талантлыбыз**

*Авылдашым, җырчы Илгизәр Исламовка*

Зөбәердән* чыгып китеп,
Илләр гизден, Илгизәр.
Тавышыңны фин дуслар да
Ишеттеләр, Илгизәр.

Иракка барып җырладың,
Барып кайттың Германга.

Мин, мәсәлән, бик шатланам,
Син – якташым булганга.

Авылдашым, карендәшем,
Талантлыбыз Илгизәр.
Әйдә әле җанны айкап,
Гөрләтеп җырлап җибәр!

______________________

* Җырчының туган авылы.

**Җырла, җырла, дип әйтәсез**
*Җырчы Хәмдүнә Тимергалиевага*

Бөреләр шартлап ярыла,
Гөлт итеп утлар кабына,
Син җырлап җибәрсәң бер.
Дөньяларны оныттырып,
Йөрәкләрне умырттырып,
Утларга саласың, бел!

*Җырла, җырла*, дип әйттеләр*,
Өйрәттеләр, көйләттеләр –
Җырлап *Галигә* киттең.
*Җомга*ларны суздың кичен,
*Картуф*лардан алдың үчең,
*Торна Зариф*ка җиттең.

------------

* Хәмдүнә җырлаган җырларның кайберләре.

Гөнаһларың санадылар,
Чәйнәп-чәйнәп карадылар,
Йоталмадылар, туган.
Тотып ашарлар иде бик,
Тешләп ташларлар иде бик,
Гәүдәң олырак булган.

Холкың кәттә, уең шашкын,
Җыр-моңнарың гүя ташкын,
Татар кызы Хәмдүнә.
Тыеп торып булмый кызсаң –
Шыңгырдатып җырлар сузсаң,
Һәр тарафны моң күмә.

Адым саен йолдыз бүген,

Йолдыз басты сәхнә күген,
Күренми дә үзәге.
Ходай үзе ярдәм иткән,
Казаннарга килеп җиткән
Котлыяр*ның гүзәле!

Бөреләр шартлап ярыла,
Гөлт итеп утлар кабына,
Син җырлап җибәрсәң бер.
Дөньяларны оныттырып,
Йөрәкләрне умырттырып,
Утларга саласың, бел!
------------------------
* Җырчының туган авылы.

**Кәүсәрия**

*Биюче Кәүсәрия Сираҗетдиновага*

**1**

Кәүсәрия – гүзәл татар кызы,
Үзе житез, сылу, сөйкемле.
Кешелегең йөрәккә май кебек,
Әйткән сүзең тапкыр, үтемле.

Кәүсәрия – гүзәл татар кызы,
Тыпырдатып биеп җибәрсә,
Җансызлар да сикереп торыр кебек,
Итәгеннән искән җил бәрсә.

Кәүсәрия – гүзәл татар кызы –
Тормышның ул үзе, чып-чыны!
Сәхнәләргә биеп килеп чыкса,
Сокландыра нәфис буй-сыны.

Кәүсәрия – гүзәл татар кызы,
Сыгылмалы, сылу гәүдәсе.
Гүзәллеккә матур өлге булып
Тугандыр бу Алла бәндәсе!

Кәүсәрия – гүзәл татар кызы,
Кәүсәр күлендәме коенган?
Сәхнәләрдә биеп торган чагы
Күз алдыңнан китмәс, уеңнан...

**2**
Фаҗигале төстә вафат булдың,
Күзләр тидеме соң үзеңә?
Ике улың үсеп килә иде,
Карап кына торып күзеңә.

Кәүсәрия – гүзәл татар кызы,
Уңган идең, өлгер, ягымлы.
Ашкыныплар дөнья көтүеңнең
Үлем булдымы әллә калымы?

Сагынабыз, шундый сагынабыз,
Якын идең, гүя багалма.
Шәһитләрнең урыны җәннәттә, ди,
Шулай булсын, газиз бер Аллам!

**Кара төн яктысы**
*Табиб Иркен Галиевкә*

Бәлки, күрәчәгем җилкеткәндер,
Карамыйча көчле явымга,
Җыендым да, эш сәгатем беткәч,
Кайтырга дип чыктым авылга.

Кул күтәргәч, ялгыз кыз баланы
Кызгангандыр шофер, күрәсең.
Утыртты да тау юлыннан китте...
Ни буласын каян беләсең?

...Таеп китте кинәт тәгәрмәчләр,
Төн, яр, яңгыр – барысы буталды...
Ул сузмаган булса ярдәм кулын,
Күрер идеммени бу таңны?!

Кыл өстендә торган минем гомер,
Кыл өстендә калган бит җаным.
Күңел нурын гына түгел,
Кара төндә
Биргән икән табиб үз канын!

**Солдат әнисе монологы**
*Әфганстанда һәлак булган авылдашым Рәшит Фәрдиевнең әнисе Мәдия Фәрдиевага*

Мин монда бала тудырам,
Мин монда бала карыйм.
Ач булмасын, туңмасын дип
Пешерәм, тегәм, ямыйм.

Мин монда бала үстерәм,
Кадерләп, көйләп, өфләп.
Ә анда...
Шул газизләрне
Карчыга кебек чүпләп
Тора сугыш чукмарлары –
Утлы уклар сызгыра.
Илкәемдә юкса еллар
Имин генә, тын гына.

Бар шул әле күрше хакы
Дигән изге йолабыз –
Тик урынлы булса гына
Ул «хак»ны без йолабыз*.

...Эш узгачтын сөйләнәсез,
Чәйнәмәк булып уртны:
Вазифага керәме соң
Тар-мар итү чит йортны?

Кешеләрнең җанын кыю
Акланмас ул һичкайчан.
Тапкан балам, зинһар өчен,
Кан чөмерүдән тайчан!
------------------------
***** Монда: гафу итәбез.

**Чечняда ике балам**

*1995–1996 елларда бер-бер артлы ике улын Чечня сугышына озаткан якташым Ринә Шәйхелмәрдановага*

Ике содат әнисе мин –
Чечняда ике балам.
Җаннарым энә очында,
Сулкылдап сызлый ярам.
Минем хәлемне беркемгә
Кабатлап бирмә, Аллам!

Ике солдат әнисе мин,

Хезмәтләре Моздокта... –
Бөтен гәүдәм бозлы суда,
Йөрәгем янган утта:
Хәбәрләрен көтеп яшим
Һәр сәгать, һәр минутта.

Ике содат әнисе мин...
Күчтеләр Ханкалага.
Ничекләр белим хәлләрен? –
Исәнме бүген таңда?
Алдагы көннәрен тагын
Көтәләр икән кайда?

Ике содат әнисе мин –
Чечняда ике балам.
Җаннарым энә очында,
Сулкылдап сызлый ярам.
Минем хәлемне беркемгә
Кабатлап бирмә, Аллам!

**Фатиха**

*Якташым Вазиха Әхмәровага*

Йомры тауның бөдрә чирәмендә
Йөгерепләр үскән кыз бала,
Ерак китеп Апач* җиркәеннән,
Язмыш сукмагына юл саба.

Авырлыклар килә Вазихага...
Тик ул өстен сыктау хисеннән.
Тәвәккәллек, дөрес исәп йөртү
Алып кайта Себер эченнән.

Туган җанлы туганнары белән
Бер тирәдә берегеп яшәргә!
Теләк кабул. Шуңа тамырлары
Туган якта бүген яшәрә.

...Сөйгән яры Әлфәт вафат инде.
Балалары Азат, Лилия –
Тормышының олы казанышы,
Яшәү мәгънәсенә шул ия!

Бабалары Хәсән, Хөсәеннең

Булдыклылык, зирәк гамәле
Дәвам итә шушы балаларда –
Гомер йомгагының зур яме!

Синең гөлләр, синең җимеш алар,
Хәсән кызы, дустым Вазиха!
Җитмешеңдә данга төрде сине
Кулларыңда күтәрепләр йөрткән
Газиз әнкәегез
Гөлнаҗия биргән фатиха!

________

* Татарстанда авыл исеме.

**Иман нуры**
*Җиңгәчәебез Рузалия Гарифуллинага*

**1**

Игътибарны җәлеп итәр
Ямь бар синдә,
Туганнарны кайгыртучан
Мән бар синдә.

Йөрәккәең үзе көчле,
Үзе дәртле,
Күңелкәең бар кешегә
Мәрхәмәтле.

Рәхмәт сиңа ир якларын
Якын иткәч,
Әйткән сүзең йөрәкләргә
Барып җиткәч.

Ихлас белән динебезгә
Хезмәт иткәч,
Бик күңелле, безгә Иман
Нуры сипкәч!

**2**
Ильяс, Илдар, Илсур, Илнур –
Үзе бер матур тезмә.
Бишенчегә дә исемне
«Ил» тамырыннан эзлә!

**Ике гүзәл балабыз**
*Динә белән Илнурга*

Быел унберенче елның
Уникенче мартында,
Сүз алабыз бер-бер артлы
Кавышканнар хакында.

Бүген һәммә табындашның
Нур уйный күзләрендә.
Бүген һәммә карендәшнең
Зур теләк сүзләрендә.

Бүген без дә сүз сорыйбыз
Кыз ягы кунаклары –
Кунакларның ераклары,
Инсафлы, тыйнаклары.

Мөслим ягы Ык буенда
Динә – безнең кызыбыз.
Инде хәзер сезнең Илнур
Булыр безнең улыбыз.

Динәбез дә сезгә шулай
Кадерле булса иде.
Илнурыбызның теленнән
Бал тамып торса иде!

Динәбез, Илнурыма дип,
Тәмле ашлар пешерсен.
Уңганлыгы биананың
Гамен искә төшерсен!

Назларының тылсымыннан
Эрепләр китсен Илнур.
Скрипка кылларыннан
Агыплар торсын моң-нур.

Сандугач телләре бирсен
Бер-берегезгә дәшкәндә.
Калкан булып калыгыгыз
Итәккә ут төшкәндә.

Ике якны тигез күреп
Рәхмәтләрен алыгыз!
Гел бергә булсын эшегез,
Бергә булсын ялыгыз!

Безнең теләк – изге теләк:
Якты булсын юлыгыз!
Бәхет белән уяныгыз,
Бәхет белән торыгыз!

Сез – сәнгатькә багышланган
Ике гүзәл балабыз,
Туйларыгыз котлы булсын,
Гомерегез хутлы булсын,
Дип, теләктә калабыз!

**Сәламәт тәндә акыл да зирәк!**
*Оныкларым Сәйдәш белән Сәгыйтькә*

**1**
Эзсез югалмый тырышлык хакы,
Сәламәт тәндә – сәламәт акыл.
Сәламәт акыл – сәламәт йөрәк,
Киләчәк өчен шундыйлар кирәк!

Үҗәтлек сорый спорт мәйданы,
Күтәрми спорт хәрам, ялганны.
Ярата спорт күп көч салганны,
Ярата спорт алга барганны.

Сәламәт тәндә – акыл сәламәт,
Уңыш табалмый ялкау, кирәмәт.
Талантлар эзли спорт мәйданы,
Тырышлык белән бизә син аны!

Сәламәт тәндә акыл да зирәк,
Туган илемә шундыйлар кирәк!

**2**
Чыныгып үсик әйдәле:
Корычтай нык, төз гәүдәле,
Көр тавышлы, нык бәдәнле,
Дус-иптәшләргә ярдәмле –
Шәп шөгыль бизи адәмне!

Кушымта:
Штанга, гантел, турник,
Таза-мускуллы булыйк!
Каратэ, бокс, ушу –
Безне ныгыта шушы!

Чук түбәтәй, чиккән сөлге,
Киләчәк буынга өлге –
Татарча көрәшкә керик.
Бирмик билне, билне бирмик,
Шатлыкларны кушыйк, бүлик!

Кушымта.

Ак кимано, кара билбау,
Яланаяк һәм тик тормау,
Ихластан сәлам бирешү,
Куйган максатка ирешү,
Өлешең белән күрешү!

Кушымта.

**Килеп җиттем**

Көнләшмәгез ачы бәхетемнән,
Татлыгыздан мин бит көнләшмим!
*Л. Шагыйрьҗан*

**1**
Дәрьялардан, упкын арасыннан
Исән калып чыккан бәхетем,
Тәкатьлегә, эшле, кадерлегә
Дип куелган ошбу тәхетем.
Җиттем сиңа, мең бәлане җиңеп,
Егыла-тора атлап, үрмәләп.
Мин ханбикә бүген биләмәмдә,
Баш ияләр гөлләр, чүгәләп.

Килеп җиттем, мөлдерәмә тулы,
Түм-түгәрәк ямьле яшемә.
Җиккән атым саз, су ерып килде,
Тиргә батты һәм күз яшемә...
Качам, дидем, ташлап бу арбаны –

Җен-пәриләр, ахры, төялгән...
...Ризалаштым тагын:
Рәвешем бит
Авырлыкка инде көйләнгән...

Тарттым шулай,
Телем тешләп тарттым,
Каршыгызда булган исем-атым...

Килеп җиттем, җиттем, иншалла!
Коелыгыз, җен-пәриләр, җәһәт.
Кузгал, арбам,
Атым, на, алга!
...Чоңгылларсыз, киртә-сикәлтәсез
Тигез юлдыр, бәлки, алдымда?
...Гомер – дөмбер,
Бөек Ихласлыкка
Менәр юлда, Шагыйрь, абынма!

**2**

*(Гороскопка таянып)*
Сөзгәкләргә мөгез бирмәгән Ходай,
Мүкләк иткән...
Ә мин менә Дуңгыз –
Борын белән бүләкләнгәнмен Күктән.
Дуңгыз дигәч тә, чыны түгел, кешемен,
Кабан дуңгызы елында туганнар ишемен.
Шуңа күрә гомер буе
Борын белән башкарам бар эшемне:
Казыйм,
сөрәм,
эшкәртәм,
Ерам,
ертам,
нечкәртәм –
Коям, канатам тешемне.
Аннан инде чәчәм,
урам,
җыям –
Арыйм, алҗыйм, табигый ки,
туям...

Җир эшенең авыр хезмәт икәнлеген беләсез,
Тик шомартып куймагач
Күренә эш иләмсез.

Борын бар да сөрергә,
Себерергә юк койрык...
Күмеләм дә хезмәткә, муенымнан чумып,
Сөйләнәм инде үзалдыма: мырык-мырык,
Эштән чыктым тәмам: гарык-гарык.

Чәпчесәм дә шулай үз-үземнән тиргәлеп,
Юанамын, юрауларны сөйләнеп:
«Гомер юлының икенче яртысы
Яшәлергә тиеш көйләнеп».

Ризамын,
Нишлим?
Чөнки туып булмый һич кенә дә кабаттан.
Әнкәем дә,
Бер Аллам да
Шушы фигыль, шушы язмыш белән яраткан!

**Рәнҗү**

*Әниле ятимнәргә*

Гариза язып килмәдек
Бу якты дөньягызга.
Табу нигә кирәк иде,
Кертмәгәч оягызга?!

Сыйдырмагач күңелегез,
Торагыгыз-өегез, –
Нигә кирәк булды, йә, әйт,
Безгә җан өрүегез?

Хәтта авыз иттермәгәч
Җылы күкрәк сөтегез,
Бер мәртәбә күрсәтмәгәч,
Чыраегыз, битегез?

Ник тудырдыгыз дөньяга,
Дөм ятим итәр өчен?
Урманнарга, вокзалларга
Ыргытып китәр өчен?

Уйларыгыз – азып-тузып,
Ләззәтләнеп йөрмәктә.

Шәп хуҗаның эте өйдә,–
Этләре дә хөрмәттә.

Хайваннар да балаларын
Яламыйча ташламый;
Баласы күз яше белән
Туган җирен ашламый.

Кем килеп уллыкка алыр,
Кем алып кызы итәр?
«Әни» сүзен, һай, безнең дә
Әйтәсе килә бик тә.

Без әллә ямьсез кызлармы...
Чәчләребезне үргәч?
Йөрәгебездән кан тама,
Әнилеләрне күргәч.

Ерткычлардан мәрхәмәтсез –
Баласыннан баш тарткан.
Шөкер, әле җиде ят бар
Кадер хисен яңарткан.
-----------
* Җәмилә, Зиннур Мөхәммәтдинов, Мәсгут Исхаков көйләре.

**Үксезләр үтенече**
*Әтиләргә*

Тарта кебек кемдер колактан,
Ояламын шундый гөнаһтан.
Син калдырган хурлык ут кебек,
Арттан калмый йөргән эт кебек.

Атның ялын ябып башыма
Еладым да, әти, еладым.
Мин – ир бала, миңа ат кирәк,
Ә ул атны кемнән сорармын?

Мин – ир бала, миңа ат кирәк,
Әти кирәк, терәк, иш кирәк.
Шуны тели һәр көн күңелем,
Шуны тели һәр көн яшь йөрәк.

Дөнья булгач, булмый хатасыз.

Шунсы начар: үсәм атасыз.
Шәрә йөрмим, бөтен өс-башым,
Тик аш түгел ашаган ашым.

Әти, диеп, ничек сагыныйм,
Әти назын тоеп үсмәгәч?
Көчле рух һәм гадел фикерләү
Синең үрнәгеңнән күчмәгәч.

Син калдырган хурлык ут кебек,
Арттан калмый йөргән эт кебек.
Кабына да ялмый йөрәкне,
Әйләнә дә тарта итәкне!

Рәнҗеш микән, сагыш агамы
Тамчы булып яшьле күзләрдән...
Үз әтиең үксез итмәсен,
Гыйбрәт алсын безнең сүзләрдән!

Тарта кебек кемдер колактан,
Ояламын шундый гөнаһтан...
...Үз әтием!
Үксез итмә син!
Өйдән киттең,
Бездән китмә син!

**Күрше хакы**
*Күршеләремә*

Күршеләрем, күршеләрем,
Якты йөзле кешеләрем,
Һәммәсе үз ишеләрем,
Һәммәсе үз кешеләрем.

Күрше хакы – Тәңре хакы,
Хаклыйк без күрше хакын!
Күршелекнең олы хакын
Мактап җырласын акын.

Күршеләрем кешелекле,
Якты йөзле, күренекле,
Тәмле телле, игелекле,
Һәр барчасы зур белдекле.

Күрше-күлән, оланнарым,
Якыннарым, туганнарым,
Йомыш тотмый торганнарым,
Уртак гамәл кылганнарым...

Күрше хакы – Тәңре хакы,
Хаклыйк без күрше хакын!
Күршелекнең олы хакын
Мактап җырласын акын.

**Аргамаклар, акчарлаклар иле**
*Казанның Идел буе районына*

Идел буе төбәккәем минем –
Казанымның кузлы учагы,
Кайнап торган эшсөярләр иле,
Дәрьяга тиң Идел кочагы.

Идел буе төбәккәем минем,
Дан-шөһрәтле Татар бистәсе.
Тун, күн белән дөнья базарында
Сокланырлык сәүдә итәсең.

Идел буе төбәккәем минем,
Аргамаклар, тулпар араны.
Адым саен тирән тарих монда,
Аер ләкин актан караны.

Идел буе төбәккәем минем,
Мәшһүр театрың, мәчетләр,
Музей кебек зират мәйданнарың –
Ишек-капкалары ачыклар...

Идел буе төбәккәем минем,
Хәзинәле Кабан – серле күл.
Мәрхәмәтле татар байларының
Эше-ашы монда – шуны бел!

Идел буе төбәккәем минем –
Казанымның кузлы учагы,
Аргамаклар, акчарлаклар иле,
Дәрьяга тиң Идел кочагы!

**Китапханәчеләргә**

Ханә, ханә, китапханә –
Анда Илшат, Фәйрүзә.
Китап сорап,
Киңәш сорап
Килә Энҗе, Әнүзә.

Бу ханәдә эшли бары
Олы җанлы кешеләр.
Китапларга күңел назын
Өсти белгән кешеләр.

Галим, галимә хезмәтен,
Әдип, әдибәләрне
Олуглый алучыларны,
Зурлый белүчеләрне
Үзенеке итә бу йорт –
Ханә-китапханәләр.
Фидакярлекне онытмас,
Гасыр дәхи сәнәләр.

**Рәхмәт сезгә!**
*Татар теле мөгаллименә*

Яратканга туган телне,
Ана телен яратканга,
Гыйлем эстәү чын татарча
Булсын диеп җан атканда,
Кемнәр генә сүзләмәде,
«Кыйнамады» кемнәр генә?
Туган тел дип сөйләнделәр,
Калды ләкин сүздә генә.

Татар теле – туган телең –
Бәхетсез тел булып йөрде.
Калдык-постык сәгатьләргә
Иң пүчтәк фән булып керде.

«Тара-бара», имеш, аны
Укыта ала һәрбер тинтәк...
Шул кадерсез мөнәсәбәт
Сеңдерелде җайлап, ипләп.

Саташты күп йомры башлар,
Голәмәсе, дин хадиме*.
Көрәштең син берьялгызың,
Татар теле мөгаллиме!

Сөю, әрнү газабыннан
Тамырларың шытым бирде,
Шәкертләрең бил турайтып
Басты бүген,
Күзең күрде.

Әнә шулай,
Сабыр холык,
Тыйнак акыл белән димме,
Саклап телне, сакла безне,
Татар теле мөгаллиме!
------------
* Дин хадиме – дингә хезмәт итүчеләр.

**Биюче кызга**

**1**
Әкияттәнме әллә син, бала?
Аяк баскан саен моң кала.
Күңелләрдә, җанда, күзләрдә –
Соклану һәм табыну сүзләрдә,
Әкияттәнме әллә син, бала?

Хәрәкәтең бирсен бәрәкәт,
Җилдән җитез йөреш-хәрәкәт.
Биегән кеше чынлап бай булсын,
Хыялында йөгерек тай булсын,
Хәрәкәтең бирсен бәрәкәт.

Онытылмасын гадәт-горефләр,
Күбәү булсын синең кебекләр.
Күз тимәсен сылу гәүдәңә,
Бие әйдә, көчең җәлләмә,
Онытылмасын гадәт-горефләр.

**2**
Чулпыларын чылтыратып
Кем бии? Әнә кара,

Аягүрә баскан килеш
Әйтерсең йөзеп бара.

Тыпырдатып биер өчен
Имән идән димәгән.
Ничек шулай назлы иткән –
Бер җире юк килмәгән.

Табигать яраткан аны
Дөньясында бер итеп:
Карап туймас нәфис итеп,
Тоташ наз һәм сер итеп!

**Һәрчак әзер**
*Кайбер җитәкче иптәшләргә*

Ирең белән бозылышсаң,
Күзләрең серен әйтсә,
Йөзеңә чыкса борчылу,
Чынлап кәефең китсә –

Елмаеп каршы ала ул,
Ах, ләззәтләнеп тыңлый,
Тик... шатлыктан «күңеле тула»,
Эченнән, сизәм, җырлый.

...Өйдә хәлең әйбәт булса,
Күзләргә кояш тулса,
Хуҗа хәле – болганчык су,
Ярый да кичкә тонса?..

...Аңлы хуҗа аңлы инде,
Йөрәккәе бик сизгер.
Аяк атлавыңнан аңлый,
«Ярдәмгә» һәрчак әзер!..

**Үз исемең белән тудың**
*«Азат хатын» журналының кабат «Сөембикә» исеменә кайтуы уңаеннан*

Үз исемең белән тудың,
Миһербан бирсен Ходай.
Иң күркәм чагыңа килеп

Җиткән көннәрең бугай.

Сөембикә гакыллары
Туплансын үзкәеңдә.
Сөембикә сылулыгы
Чагылсын йөзкәеңдә.

Ханбикәдәй зыялы бул,
Зыянлы булма ләкин.
Акыл бирер киңәшче бул,
Назыңнан итмә ятим.

Эчке бер нур балкып торсын,
Дәрт-дәрман ташып торсын!
Егет-җилән бер кырыйда
Башларын кашып торсын!

Яңарып тор, җанланып тор,
Сердәшче бул!
Бул серле!
Горурлык бир хатын-кызга,
Мәкерле булма, керле!

Исемкәең җисемеңә
Ят булмасын, мач булсын!
Һәр сәхифәңдә укучы
Нур иленә хаҗ кылсын!
*1992*

**Ярдәм ит!**
*«Безнең гәҗит» газетасына фатиха рәвешендә*

Замананың тәрбиягә
Сусаган, мохтаҗ чагы.
«Нигә кирәк булды икән
Бу гәҗит?» – димә тагы.

Безнеке булсын әле ул,
Тәрбия кылсын әле!
«Безнең гәҗит» белән бергә
Өйгә нур тулсын әле!

Язылыйк та, язышыйк та,
Битараф яшәмик гел.

Таркалмыйк та, вакланмыйк та,
Дөнья – иркен, дөнья – гөл.

Бергә яшик, бердәм яшик,
Уйлашыйк, киңәш итик.
Кайгыртыйк милләт тормышын,
Иманлы, мәнле итик!

Кот качты күпме тарафтан –
Казамы, әллә кәмит?..
Кыйблабызны табышырга
Ярдәм ит, «Безнең гәҗит»!
*2002*

**Читтә яшәүче якташларга**

Илдән читтә күрдем сине,
Күзләреңдә кайнар яшең:
«Туган якка кайтыр идем,
Үтте инде, – дисең, – яшем.

Ай кыен ла чит җирләрдә
Килмешәк кук көн күрүләр.
Атаң-бабаң турысында
Төрле яман сүз йөрүләр.

Ышандырыр өчен генә
Татарларның кемлегенә,
Баш күтәрми эшли-эшли,
Бөтен гомер үтте менә.

Үтте менә яшь чакларым,
Нык чакларым калды артта.
Инде тәмам өшәннәгәч,
Ник кирәк мин туган якка?..

Шулай уйлыйм, туганкаем,
Кайтасым бик килә дә бит.
Бар көчемне читкә биргәч,
Ил өченгә хәзер мин чит...»

...Телдә сүзе, күздә яше
Якташымның.
Ни хәл итим?

Ул кан елап калган җирдән
Ничек шатлык төяп китим?

Соң түгел, кайт җир өстеннән!
Җир астыннан табылмас юл.
Читтә солтан булганчы соң,
Үз илеңдә бер олтан бул!

**Абхаз халкына**

Абхазия 1910 елда Россия составына керә. 1921 елда автобусия статусы ала. Әмма халык бүген дә үз җирендә тынычлап яши алмый.

Офыкларда – таулар,
Офыкларда – яулар,
Офыкларда – Кавказ урманы.
Кочакларда – диңгез,
Йә, кемнәргә тиң без?
Өстебездә Кояш юрганы...

Кояш һаман шул ук,
Диңгез һаман шул ук.
Ә замана? Заман икенче:
Матурларны саткан,
Батырларны аткан...
Йөгән кемдә, юлда шул көчле...

Түзгән адәм башы –
Шаһит суы, ташы
Мәсхәрәнең төрле сортына.
Гөл кыйммәткә төшкән,
Күз яшендә үскән,
Нәсел күчкән диңгез артына.

Таулар үз җирендә,
Диңгез үз иңендә,
Урынында Кавказ урманы.
Ә халкына нигә
Гомер буе кинә?
Ник коела гүзәл ил каны?..

**Чуар йөрәклегә**

Мин сине язлардан эзләдем,
Чәчәкле җәйләрдә күзләдем.
Тапмадым ак буран эченнән,

Күз керде... Ахыры, кичегәм.

Язлардай балкытып дөньямны,
Күрендең кабаттан күземә.
Үпкәләп гомерне үткәрмик,
Кул бирдем, уз күңел түремә!

...Ул икән бик озын юл үткән,
Язларда бихисап гөл үпкән.
Җәйләрдә тир түккән, су сипкән,
Кышларда йөрәген өшеткән.

Өшеткән, йөрәген өшеткән...
Чуардан моны күп ишеткән.
...Тәрәздән шуышкан хыянәт
Куыла мәңгегә ишектән.

**Классташ дустыма**

Үсмер чагым бүгенгедәй истә,
Аңлый идем сине күзеңнән.
Нинди генә серләр сөйләсәң дә
Сихерләнә идем сүзеңнән.

Энже кардай хисләрең ак иде,
Бик ярата идем үзеңне.
Сукмагыңнан танып ала идем,
Синең эзме, әллә түгелме?

Сырындылы сырттан очып төшкәч
Үпкәләттең...
Ахры, белмичә...
Ак юлда йөр, тик гомерең
Өшеп үтсен, дидем көлмичә.

...Юкка чыктың, капылт юкка чыктың,
Исемемне язып ак карга.
Юләр түгел диген инде безне,
Үпкәләшкәнбез бит юк-барга.

Бер-беребезне озак табалмадык,
Ә табышкач инде соң иде.
...Сабантуйда синең кызларыңа
Исәнләшеп улым кул бирде...

**Гомеремне түләп җырлар яздым,**
**Шигырь буынына сеңдереп.**

**Аш бирдем дә...**

Кешелекле бул, балам,
Кечелекле бул, балам!
Ике сүзнең берендә
Кабатлый шуны анам.

Кече күңелле булдым,
Мохтаҗларга кул суздым.
Аш бирдем дә таш алдым,
Шул ташка... башны салдым...

**Тәгәри китте**
Ап-ак йомгак булып хисем чаба
Таудан түбән түгел, төз җирдән.
Үз бәхетеңне үзең тоталмагач,
Йомгагыңны табып кем биргән?

Үз бәхетеңне үзең сакламагач,
Кемдә кемнең эше, көмеше?
...Әйдә минем арттан, тәгәрик, дип
Ымсындыра ак шар көлмеше.

Тәгәрәпләр китте гомеркәем,
Күрмәдеңме, дисәм, кем әйтер?
...Йөгерсәм дә, туктап эзләсәм дә,
Төен-төен йомгак бу хәтер!..

**Син югында...**
Син югында өем ямьле түгел,
Син югында күңел төшенке.
Син барында шатлык качмас кебек,
Кайгы какмас кебек ишекне.

Синең белән дәртле, дәрманлы мин,
Синең белән барам кояшка.
Биеклеккә, бөеклеккә менәм,
Синең белән үсәм мең башка.

Син барында, үзе йөгереп килеп,
Шакыр кебек шатлык ишекне.
Син югында эшем көйле түгел,
Син югында күңел төшенке...

**Җаным туңа**
Карашларың эзләп, кара гүрең тырныйм,
Сулышларың сагынып, кара янып елыйм.
Кабер өсләреңдә чәчәк булып сулыйм,
Үлән арасында җилләр булып дулыйм.

Тырнак төпләремә үзле балчык тула,
Күз төпкелләремә ямьсез төсләр куна.
...Көзләр җитә, гөлләр күзен йома,
Кара җиргә чүккән җаным туңа...

**Югалганнар кире кайтса...**

«Кая гына югалды, – дип, –
Курчагымны кем алды?» – дип,
Кызым дулый,
Кызым елый.

Курчагын тиз табып алдык.
Аңа карап уйга калдым...
Һәр югалган
Кире кайтса
Һәм табылса,
Ничек кенә эзләр иде әле кеше!

**Җырланмаган җырым***
Турыбыздагы сукмаклар
Тарайды, син йөрмәгәч.
Гөлем чәчәк атты, сулды,
Сулды, сине күрмәгәч.

Тәрәзәмдә көлтә-көлтә
Таң нуры уйный иде.
Син минем җырым идең бит,
Күземнең нуры идең.

Яңгырдан соң яшәргәндәй
Бөтен дөнья, табигать,
Яшәрткән идең күңелне,
Сердәш идең, ахирәт.

Ут булдың да су булдың, һай,

Мәхәббәтем күгендә.
Җырланмаган җырым булып
Калдың күңел түрендә.
------------------
* Рөстәм Яхин, Риф Гатауллин көйләре.

**Безнең күңел***
*(Җыр)*
Безнең күңел нигә моңлы икән,
Безнең күңел ничә кыллы икән?
Онытыласы иде тын калып.
Гарасатка кереп югалмыйча,
Гөнаһларга гына уралмыйча,
Бәхет йөрсә икән юл ярып.

Безнең күңел нигә моңлы икән,
Безнең күңел ничә кыллы икән?
Ду купканнар шашкын хисләрем.
Чыгымчылап чапкан ярсу тайдай,
Дулкыннарга кунган моңсу айдай
Ярсу яки моңсу кичләрем.

Безнең күңел нигә моңлы икән,
Безнең күңел ничә кыллы икән?
Кушылырга сайрар кош кирәк.
Җаннан җанга йөри моңнар күчеп,
Тик дөньясы гына әллә ничек –
Сабырлыклар бирсен...
Түз, йөрәк!..
*1982*
---------
* Илгиз Закиров, Илдус Якупов көйләре.

**Әй сулкылдый җаным**
Күңел тулы өмет,
Йөрәк тулы яра,–
Бу төкәнмәс уйлар
Кая алып бара?

Кая илтә юллар,
Күзләр кемгә бага?
Чишмә суы булып
Моң челтерәп ага...

Нинди гөнаһ булды
Җәза алыр өчен?
Бала тудырдыкмы
Ятим калыр өчен?

Кемнәр аңлар безне,
Кем юатыр килеп?
Әй сулкылдый кичләр,
Җанны ала телеп.

Яшен булып уйный
Уйлар вакыт-вакыт.
Бер туздырсын иде
Өермәсе кайтып.

Табигатьнең сәер
Җил-давылын көтеп,
Елы-елы белән
Гомер бара үтеп...

**Яшь җан бит ул**
Яз суларын, ярсуларын үтеп,
Җәйләренә кергәч сөюнең,
Чаялыгын, каялыгын белеп,
Җаен тапкач дөнья күрүнең,

Аяз көндә яшен суккан кебек,
Тыныч көндә кинәт тол калдык.
Уй-хыялны бер суларга салып,
Бер утлардан тартып без алдык.

Каерылып уңган елы иде,
Бәхетләрнең гомере булмады.
Казалы ел кебек табигатьтә,
Таш-боз яуды, җиле дулады.

...Яшь җан бит ул.
Көтә, өмет итә,
Мәңгелеккә ярны җуйсак та.
Тыныч көндә тол калуы авыр,
Язмышларга сылтап куйсак та...

**Күзләреңә чумган гына идем...***

Иренеңә кайчан кагылдым да
Иңнәреңә кайчан сарылдым?
Шашкын булдым микән мәхәббәттә,
Вулкан булдым микән – ярылдым.

Күзләреңә чумган гына идем,
Төпкелләргә туры килдемме?
Кайгыларның кара урманында
Ешкынлыкка барып кердемме?

Әле генә куеныңда идем,
Дуеныңда идем сөюнең...
Газап күрмәгәннәр белми булыр
Кайгылардан кара көюне.

Иңнәреңә кайчан сарылдым соң,
Иренеңә кайчан кагылдым?
Ялгызлыкка бирмәс өчен җанны,
Җырларыңа төрдем, кабындым.
-------
* Риф Гатауллин көе.

**Тик...**
Күзләренең карасында
Үзәк өзгеч моң ята.
Каты кагылма толларга,
Ясама ялгыш хата.

Толлар турындагы гайбәт
Тубыктан түгел, тездән.
Арала син, кеше булсаң,
Яман күз, ялган сүздән.

Үз-үзен саклый бөҗәк тә,
Җәнлек тә, кыен килсә.
Толныкы гаеп буламы,
Кагылма миңа, дисә?

Тол хатында да йөрәк бар,
Йөрәге ләкин бәйдә.
«Хәлең ничек?» – дип сорагыз,
Күңеле булсын әйдә!

Толлардагы хис-тойгылар
Чишмә булып бәрсәме?..
Тик...
Аларга явыз дөнья
Күпсенгән күп нәрсәне...

**Гомер**
Җир яңара –
Гөлләрдән гөл ярала,
Уй кагыла,
Кагыла, моң тарала.
Гөлчәчәкләр йә баса, йә чүгәли.
Әйләнәләр итәк җилем тирәли.
Тымызык көн ләйсән яңгыр бөркеде,
Үсеп чыкты ак күбәләк төркеме.
Юлга ятты шәфәкъ кыйган кыйпылчык,
Күләгәңне ал алдымнан, кояш, чык!
Күз алдыннан нурлар, уйлар аксыннар –
Йә боз булып,
Йә куз булып ятсыннар.
Бу чагылыш – яшәвемнең бер көне,
Бер көнемме? –
Гомеремнең бөртеге...
Мин йөгерәм,
Йөгерәм – көн яктыра,
Әле сулга,
Әле уңга чакыра.
Хәтерләтеп аңлы сабый чагымны,
Көлтә-көлтә нур төргән дүрт ягымны.
Төшәм төпкә,
Төпкеленә җиремнең...
Өлеш чыгар кодрәтеннән иремнең.
Ыргылмаска,
Ургылмаска юк чарам,
Төбенә төшми,
Җиренә җитми тукталмам.
Күккә менәм,
Яшен белән үртәшәм,
Үчекләшәм:
«Үчкә – үч», – дип эндәшәм,
Хисләремнән исәнгерим мин тәмам,
Очам-кочам,
Янам-эрим һәм тамам...

Бер хәсрәт – гомеремнең мең төне,
Шатлыгыммы?
Мең төнемнең бер көне...
Күз алдымнан утлы уйлар агыла,
Үткәнемә,
Үпкәнемә кагыла...

**Күз төпләрем кара көйде**

Лачын кебек биектә җаным:
Мәхәббәтнең исән-сау чагы.
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Читлегендә талпына җаным:
Мәхәббәтне югалткан чагым.
*К. Сибгатуллин*

Офыклардан шәфәкъларга
Сузылган ялкын – яра.
Кылдан нечкә шул юл буйлап
Минем язмышым бара.

Агачларда – көзге сагыш,
Юлларда – кантар-кара.
Газапларым, котылыгыз –
Йөзгә көз төсе сара.

Ялгызлыкның үзе түгел,
Шәүләсе хәтта өтә.
Күз төпләрем кара көйде,
Якты көн көтә-көтә.

**Юктыр тиңе**

Мәхәббәтнең чиге бармы?
Бармы чиге?
Безнең сөю мисалының
Бармы тиңе?

Безнең сөю ялкынланып
Янган сөю!
Йөрәкләрдә һәйкәл булып
Калган сөю,
Безнең сөю!

Мәхәббәтнең чиге бармы –

Кемнәр әйтә?
Кемнәр сөю газапларын
Җиңеләйтә?

Җиңеләйтү, оныттыру
Мөмкин эшме?
Дөрләп янган сөюләрдә
Туктар көчме?

Мәхәббәтнең чиге юктыр,
Юктыр чиге.
Безнең сөю мисалының
Уттыр тиңе!

**Гомеремне түләп***
*(Җыр)*
Шигъри дөнья безне кавыштырды,
Кавыштырды
Шигъри дөнья,
Бәллүр бишегендә тирбәтеп,
Бәллүр бишегендә тирбәтеп.
Йөрәкләрне әсир итте Сөю,
Әсир итте
Йөрәкләрне
Шул Сөюнең шигъри ширбәте,
Шул Сөюнең шигъри ширбәте.

Шигъри дөнья безне кавыштырды,
Кавыштырды
Шигъри дөнья,
Йолдызларга кадәр күтәреп,
Йолдызларга кадәр күтәреп.
Шифа көтсәм, утлы яңгыр койды,
Утлы-бозлы
Яңгыр койды,
Үзәк-бәгырьләргә үткәреп,
Үзәк-бәгырьләргә үткәреп.

Шигъри дөнья безне кавыштырды,
Кавыштырды
Шигъри дөнья,
Сөю назларында көйдереп,
Сөю назларында көйдереп.
Гомеремне түләп җырлар яздым,

Гомеремне
Түләп яздым,
Шигырь буынына сеңдереп,
Шигырь буынына сеңдереп.
----------------
* Сара Садыйкова көе.

**Ятимлек**
Мин – җырчы да йөрдем күпләр арасында,
Кайчан миңа атар диеп тартылган ук?
*Н. Арсланов*

Иремә тиде явызның
Тартылган угы.
Шул хәсрәттән бихисап күп
Кайгылар туды.

Балаларымның үзәген
Телеп алдылар.
Туганнарымның балтасын
Суга салдылар...

Уклары һаман төбәлгән,
Йөрәгем елый.
Яклаучысыз ятимлегем
Эчемне тырный.

**Пар сандугач кунсын әле**

Мин еламый, кем еласын,
Җуйдым асыл кошымны.
Берьялгызым чыгам менә
Инде ничә кышымны.

Мин саргаймый, кем саргайсын,
Хәйран баш вәйран булды.
Дошманнар күзе алдында
Йөзгә кара коелды.

Мин җырламый, кем җырласын,
Җырлыйм күңел тулганга.
Эзләдем, таптым, югалттым,
Эчем поша шуңарга.

Мин елмаймый, кем елмайсын,
Бакчы, күпме дусларым!
Пар сандугач кунсын әле,
Баш очымда – учларым...

**Бергә чакларда***
*(Җыр)*

Кошларның да пары бар,
Көннәрнең дә таңы бар.
Миһербансыз кыланмагыз,
Толларның да җаны бар.

Кушымта:
Канатлар алтын икән,
Йөрәкләр ялкын икән
Бергә чакларда.
Дөнья түгәрәк икән,
Җаннар күбәләк икән
Бергә чакларда.

Ярларны сулар кага,
Ялгызлар суга бага.
Ялгызлыктан качар идем,
Суларда ага-ага.

Кушымта.

Шикле караш, явыз караш
Йөрәкләрне теләдер.
Ялгызларның авыр хәлен
Тик татыган беләдер.

Кушымта.
-------------
* Риф Гатауллин, Дибәҗә Каюмова, Гөлмәрьям Мансурова көйләре.

**Ярты юлда**

Җыелмаган ризык калды табынымда...
Хәзер инде беребез – анда, беребез – монда.

Әйтелмәгән сүзем калды тел очымда,
Ширбәт кенә чишмә суы – кушучымда.

Өмет тулы күзем сине эзләп талды.
Калды...
Бар да ярты юлда калды, калды.

**Пар-пар булып очкан торналар**

Үз ишләрем эзлим кешелектән, –
Тол хатыннар – минем тиңнәрем.
Барчагызның кайгыларын җыйсам,
Күтәрәлер микән иңнәрем?
Кырык бердә ятим калган җаннар,
Ни хәл итеп сезгә булышыйм?
Терелтер лә идем ирегезне –
Дәва булса әгәр сулышым.
Кырык бердә,
Кырык биштә калган...
Сиксән биштә калды бәгъзебез.
Еласак та үкенеп еламыйбыз,
Ир кочагы күрде тәнебез.
Кимсенүдән сүнә нурлы күзләр,
Күпсенүне авыр күтәрү.
Көне ярый, көне кеше белән,
Кыен кичне, төнне үткәрү.
Киңәшләшер һәм серләшер сүзләр
Хәл ителә ялгыз баш белән.
Шуңа микән толлар еш ялгыша,
Җавап ала ашка таш белән.
Шуңа микән толлар бакчасына
Күсәк төшә, салкын боз ява.
Шуңа микән толлар җилкәсенә
Кеше күтәралмас йөк ава.
Шуңа микән, нахак бәла белән
Кыерсыткач, җаны таплана.
Мәкерле сүз телә бәгырьләрне,
Сүз ярасы озак саклана.
Толлар елый,
Башын бәрә-бәрә,
Үз-үзенә урын табалмый.
Яшәсәче кеше,
Бер-берсенә
Утлы инә булып кадалмый.

Эчтән сыза,
Эчтән елый алар –
Дөрес аңлашылмас кемгәдер.
Тол хатынны тол хатыннар талый –
Хурлыклары үзәк өзәдер...

Бер Аллага сыгына ялгыз кеше,
Кыен килсә төрле тарафтан.
Бөек Акыл һәрбер җан иясен
Так итмәгән,
Парлап яраткан.

Җирдә түгел,
Күктә матур була
Пар-пар булып очкан торналар.
...Толлар җаны
Хыял ирке белән
Күк катына барып торгалар...

**Минем язмыш**

Урам бизәр, тузан сулар өчен
Утыртылган юкә, каендай,
Пычрак сүздән кеше күңеле дә
Туя икән, туя, маемлый.

Җиде яктан җиде төрле аваз –
Җиде ятның ачы каргышы.
Җилли-җилли дәвер башларыннан
Йөриме әллә кеше язмышы?

Басып калдым җиде юл чатында –
Язмышымның тагын ялгышы... –
Гүя миндә тузан сулар өчен
Утыртылган агач язмышы...

**Сыный алмас идем**

Күкләр күрмәсә дә, гөлләр белә:
Йөзем якты, керсез вөҗданым.
Гайбәтләргә урын калдырсам да,
Явызлыклар җирдә кылмадым.

Дусларымның әйткән киңәшләрен
Догам итеп йөртәм җанымда.
Кемгә ошый, кемгә ошамыйдыр –
Апа да без, сеңел, ханым да...

«Хыялый ул» диеп ялгыштылар,
Эндәшмәүне артык күргәнгә.
Барсын белеп, барсын сизеп тордым –
Кытыклары килде түзгәнгә...

Хәсрәтләр килде – саргаймадым,
Авырлыклар килде – сынмадым.
Үземне дә, дусны-дошманны да,
Дөньяны да шулай сынадым.

Сынган булсам, сыный алмас идем!

**Буй җитмәслек җиргә**

Ай йөзендә моңсу шәүлә күрдем –
Мин үземме,
Әллә өермәм?
Күңелемне китеп алганның да
Кайгы-хәсрәтенә сөенмәм.

Ай йөзендә якты очкын күрдем –
Шатлыгымнан янам, сибеләм.
Яннарыңа очып барыр мәлдә
Кире чабам,
Кире йөгерәм.

Ай йөзендә алтын алка күрдем –
Алам диеп әмма үрелмәм.
Үрелепләр буем җитмәслеген,
Сүзем үтмәслеген бик беләм...

**Үтне сытар гайбәт чөмереп...**

Гөнаһлардан гел сакланып йөрдем,
Яхшысынмый йөрдем күп чакта.
Гомер үтә торды,
Үткән елларымны

Сатып алып булмый бер хакка.

Ялгыз көннәр, ялгыз төннәр үтте,
Тәкъдимнәрдән гел йөз чөереп.
Газапланып, азапланып үтте,
Үтне сытар гайбәт чөмереп.

Җитәкләшеп алга барган булдым
Сабыйлыгым белән берлектә.
Уйсыз башлар көлеп яшәделәр,
Сөелеп яшәделәр хөрлектә.

Гөнаһлардан гел сакланмак булып,
Үз бәхетемнән үзем баш тарттым.
Алтыннарга сатып алыр идем
Үткән көннәремне, бер кайтып.

Көләр идем, бер сөелер идем,
Оялмыйча җирдә беркемнән.
Юашлыгым белән гомер буе
Мин баш тарттым бугай иркемнән.

**Күпне күрде башлар**

Күпне күрде башлар:
Башка төште ташлар,
Җимерелде кашлар,
Тозсыз пеште ашлар...
...Күрде безнең башлар!

**Аптырау**

Бәхете аягына уралган.
Ничекләр итеп теләде икән әнисе?
*Әнкәй сүзләре*

Әнкәй миңа бәхет теләгән.
Хәсрәтле суд юлында
Йөрмәсен бу, димәгән,
Чөнки минем канлы язмыш
Уена да килмәгән...

Әнкәй миңа бәхет теләгән!..

**Кай арада?**

Мәхәббәткә яшел болын диеп,
Болыннарда ярсу колын диеп
уйладым.

Хыялымда шул болынны гизеп,
Хыялымда шул колынны җигеп
туйладым.

Иртәләрне таң нурына манып,
Үземнекен атлавыннан танып
яраттым.

Чәчәк утлап йөргән хисләремне,
Сабый чакта күргән төшләремне
тараттым.

Уйлар кайта, кайта урап-урап,
Яшел болыныма бурап-бурап
кар яуган.

Җегәр кергәч кенә беләкләргә,
Кай арада безнең йөрәкләргә
кан сауган?

**Зәңгәр эңгер**

Кагылмагыз кайнар хисләремә,
Кагылмагыз зәңгәр төсләремә,
Кагылмагыз минем сөюемә,
Үксүемә, янып-көюемә.

Зинһар өчен, зинһар, кагылмагыз,
Чит йөрәкләр, безгә ягылмагыз.
...Кылану да, кыстату да түгел,
Күнми булгач, күнми күндәм күңел,
Кагылмагыз!

Кагылмагыз
Изге хисләремә,
Мин табынган зәңгәр төсләремә,
Юксынуым сары сагыш булып
Чыксын әйдә, чыксын төсләремә –

Кагылмагыз!

Кагылмагыз!
Зинһар, кагылмагыз!
Чит йөрәкләр, безгә ягылмагыз!
Изге килеш, тугры килеш гомер –
Күз алдында торсын зәңгәр эңгер!!!

**Күз буып уйнады кайгылар**

Күз буып уйнады кайгылар,
Бәхетләр качтылар, «һайт!» диеп.
Югалттым, инәлеп эзләдем,
Шатлыгым, кайт, диеп, кайт, диеп.

Әй мохтаҗ бу җаным сөюгә,
Иркә сүз, кадерләү, назларга.
Китәм дә әйләнеп кайтамын
Көзләргә, кышларга, язларга.

Китсәгез, мең бәхил, эзләмим,
Керфек тә какмаган төннәрем.
Төннәрдә иркенләп үкседем,
Лычма су булганчы мендәрем.

Ә иртән?.. Балалар... Мәшәкать...
Боегу, борлыгу ярамый.
...Кайтсана, бәхетем, «һайт» диеп,
Кайт кабат, бернигә карамый!

**Томаланып үлгән гөл сыман**

...Кояшлы, җилле җәйдә,
Сиңа калсын дип, гөлләргә
Тимәдем бөтенләй дә!..
*Р. Закиров*

Үтә дә саф иде синең караш
Җәйге төннең якты кичендә.
Мин бер сабый кебек сырпаландым
Куанычым сыймый эчемә.

Синең сулыш булып сыйпап узды
Җәйге җилләр якты йөземне.
Миләүшәләр белән болын тулган,

Ала алмый тордым күземне.

Такыялар үреп кимәк булдым...
Юк, юк, өзмә! Тыйдым үземне.
Сабыйлыгым белән сизмәгәнмен
Алда торган салкын көземне.

Күз карашың кинәт кырысланды,
Тиктомалдан искән җил сыман.
Куырылдым –
Якты көнгә чыгып
Җиталмаган язгы гөл сыман...

**Җаннар сулып калды**

Куллар кулда иде,
Күзләр юлда иде,
Уйлар сыймый иде җиһанга.
Дөньяларны гиздек,
Сүздән ләйсән тездек,
Әйләнгәник икәү бер җанга.

Мин фәрештә идем,
Сиңа канат бирдем,
Күк катына очып менәргә.
Ә биеклек бозды,
Бәгырьгә ут сызды,
Хыянәтең китте тирәнгә.

Куллар кулда иде,
Күзләр юлда иде,
Уйлар сыймый иде җиһанга.
Сөю көйрәп янды,
Җаннар бушап калды,
Ут төрттеләрмени ал таңга?..

**Чәен мактап эчкән коебызның...**

Искә алу, бәлки, кирәкмидер,
Узган-үткән инде ул чаклар.
Бер-беребез өчен ямен җуйган,
Суынганнар кайнар кочаклар.

Җитәкләшеп йөгергәник икәү,
Барыр юлны алдан билгеләп.
Кара явым куып тотты безне,
Күз алдында сынды ал гөләп.

Чәчәк атар өчен бөреләнгән
Якты хисне шул көн үтерде.
...Чәен мактап эчкән коебызның
Суына син ничек түкердең?..

### Өндәү

Гөл кипте,
Сабагында кинә калды.
Былбыл!
Сиңа бер бөртек инә калды.
*Дәрдемәнд*

Җырларымда калдың зың булып,
Йөрәгемдә калдың туң булып,
Телгә алып булмый исемең,
Күңел елый, елый сулыгып.

Гөлкәйләрем кипте, күшекте,
Җилнең салкыннары өшетте.
Сокланырлык чәчкәм калмады,
Гүя явыз ялкын ялмады.

Сызлый-әрни бәгырь-йөрәгем,
Тоз сибелгән яра эзләре...
«Бирешмә әле,
Көчле булып кал!» –
Диеп өнди сабыр күзләре.

### Хыялыма уелып

Йөрим кайчак кара коелып,
Күңелкәем төшә кыелып.
Гомер үтте,
Яшәп булмады,
Калын җилкәләргә сыенып.

Йөрим кайчак кара коелып,

Бәгырьләрем чыга суелып,
Бәйрәм ясый кемдер үзенә,
Кайгыларым белән коенып.

Йөрим кайчак кара коелып,
Йөгерәм дә...
Калам тыелып.
Өмет кенә оча гарешкә,
Хыял-хисләремә уелып...

**Күк никахы**

Таптама яшьлек чәчәген,
Каралтма ак карларны.
Безне язмыш очраштырды,
Хуп күрде Күк, парлады.

Җәйле елларыбыз белән
Ак кышларга төрендек.
Дусларыбызның күзенә
Тиң яр булып күрендек.

Уңышын көз җыярбыз дип,
Язын орлыклар сиптек.
Тормыш серле. Хыял белән
Төрле якларга киттек...

Өшетмик яшьлек чәчәген,
Каралтмыйк ак карларны.
Безне язмыш очраштырды,
Күк никахы парлады!

**Тик сиңа***
*(Җыр)*

Давылларны узып,
Йолаларны бозып,
Мин сиңа, мин сиңа киләмен.
Җанымның бар назын,
Кайгымның бик азын
Тик сиңа, тик сиңа бирәмен.

Кояштан да көчле,

Моңнардан да хисле
Йөрәгем утына төрәмен.
Җанымның бар назын,
Кайгымның бик азын
Тик сиңа, мин сиңа бирәмен.

Төшеңә керәмен,
Мин сиңа киләмен,
Бәхетне бер синдә күрәмен.
Кайгымның бик азын,
Җанымның бар назын
Тик сиңа, бер сиңа бирәмен!
------------
* Фирзәр Мортазин, Ильяс Вәлишах, Лидия Әхмәтова көйләре.

**Толымыңа төренеп**

Ачылды төннең күзләре,
Ай – ут элдергән шунда.
Ярылып ята эзләре,
Нур сукмак салган комда.

Ачылды төннең күзләре,
Кабынды йолдызлары.
Атлый,
Диңгез дулкынында
Сафланган бүз* кызлары.

Ачыды төннең күзләре,
Күләгә төшкән суга.
Толымына төренеп, ул
Төнге күлмәген сыга.
——
* Бүз – үсмер.

**Оялуның аръягына чыгып**

Хыялымда иркәләдем сине,
Хыялымда төрдем татлы назга.
Үз-үземне алдый-алдый шулай,
Суырылып кердем салкын сазга.

Хыялымда мин синеке идем,

Син дә миңа сеңдең хыялымда.
Мәхәббәтнең дәрвише дә күк син,
Буй җитмәслек ерак, зыялы да...

Хыял хыял булып кала бирде,
Чынбарлыкта мин гел бүтән кеше –
Оялуның аръягына чыгып,
Эчтән дөрлим,
Тыштан сүнәм өшеп...

**Өметләрең киселсә**

Сөю татлы,
Чая яшьлегеңдә
Пар күзләрең очкын чәчсәләр.
Ялгышларың бары сабак бирсә,
Шатлыкларың алга дәшсәләр.

Алган гыйбрәт-сабакларың белән
Хыялларың җиргә төшсәләр –
Очышта да күңел сына икән,
Өметләрең капылт киссәләр...

**Дулкын-су**
Комга язып исемеңне,
Каурыйлар кадыйм, дидең.
Барам-барам да яр буйлап
Һәм кайтып карыйм, дидең.

Кайчак дулкын юган була
Исемеңне, Эльмира.
Мин сине генә яратам,
Кулларыңны бир миңа!

...Комнан түгел, күңеленнән
Юсаң соң исемемне,
Гөнаһлардан саклар идең,
Дулкын-су, җисемемне...

**Алдар булган**

Йөрәккәем,

Синең өчен яшим, дигән,
Син – бер генәм,
Син – гөл генәм,
Назлым, дигән,
Алдар булган.
Сүзләренә ялган тулган.
...Миңа килеп ирешкәнче,
Уннан «талак» алган булган.

**Астыртын хыянәт**

Сөюләрнең җиллеләре,
Җилсезләре буламы?
Бербөтен итеп ярату
Синнән генә торамы?

Әйтеп киләме мәхәббәт,
Рөхсәт сорыймы синнән?
Күз тиде, дип тә сөйлиләр,
Күзсенә икән кемнән?

Сөюләрнең гөнаһлысы,
Гөнаһсызы буламы?
Ярату, дигән ярсу хис
Синнән сорап торамы?

Яшен түгеп, яшеренеп,
Качып-посып йөрсә әгәр,
Бу – астыртын хыянәттән
Булыр сиңа бер хәбәр...

**Явыз дию**

Туган илдә һәркем туган,
Газиз, диеп
Йөргән идем, йолдызларга
Башны чөеп.

Башкаемны вәйран итте
Дәү-дәү ирләр.
Болытларны кая куа
Искән җилләр?

...Үз җиремдә изеп, сытып
Ташладылар.
Тындылар да, янә шуны
Башладылар.

Күктән биек, офыктан киң
Сөюемне
Тартып алып,
Бирделәр бер
Диюеңне...

Дию явыз, дию сансыз,
Хәтта кансыз...
Һичбер нәрсә хәл ителми
Гәрчә ансыз.

Аның өчен юк икән бит
Изге хисләр,
Күз яшьләре, гөнаһ, хәрам
Кебек эшләр.

Шөһрәт өчен сату мөмкин
Үз анасын...
Калганнарын һәр укучы
Үзе аңласын!

**Өлешемә тигәннән дә**

Миңа гына аударДЫҢ шул
Бөтен гаеп-кыекны.
Дөньяга сыймас сөюем
Күз алдында боекты.

Парлы килеш ялгыз яндым,
Парлы килеш өшедем.
Өлешемә тигәннән дә
Мәхрүм калган кешемен.

**Юхалар бар**

Юхалар бар. Сизмисең дә хәтта,
Иплэп кенә тешли, каната.

Беркатлылар: нинди ачык, диеп,
Ягымлы, дип, аны ярата.

Юха елан токымыннан булса,
Битлек әзер аның тумыштан.
Шул сыйфаты белән бар кирәкне
Күрәп ала белә тормыштан.

**Биләүләп салсаң да...**

Айның алтын билбавы.
Дус-ишләрең арасында
Читен ярың булмавы.

Су янында баланнар.
Сине сөйдем гомерлеккә,
Кирәк түгел калганнар.

Үлеп, кабат терелдем.
Мәхәббәткә сәлам бирдем,
Михнәтенә күмелдем.

Яшикче бер җилдереп.
Наздан алган «сый-хөрмәтне»
Буй-сыннарга сеңдереп.

Күл өстеннән җил өрә.
Бөдрә башым күрәләтә
Гауга иленә керә.

Уч куям тамчыларга.
Өсләремнән йөри ирем,
Туры килә чыдарга.

Коенам явымнарда.
Синең хәсрәтең, наныем,
Таш булды бавырларда.

Егылып төштем күктән.
Биләүләп салсаң да, бүре
Чыгып чабар бүректән...

**Дөрес булган**

Очраштык без кавышып, аерылганнар –
Тетрәп куйды йөрәк, чәнчеп алды.
Ялгыз еллар ятты араларга,
Тик йөрәктә сәер очкын калды.

Рәнҗешләрне күптән уңдардылар
Яз кояшы, кышның җете кары.
Дулкын ашап убылып кергән әнә
Елгабызның син тукталган яры.

Елгабызның сөзәк ярларыннан
Җитәкләшеп төшеп җәйге кичтә,
Такыялар үреп агызганыйк,
Онытылмый шул минутлар һич тә.

Такыялар ике төрле акты:
Мин үргәнен усал дулкын какты.
Син үргәнен бөтерелдерде упкын,
Өзеп-сүтеп, кабат ярга атты...

Очрашсак та әүвәл шашып сөйгән,
Җитәкләшеп йөргән ике язмыш.
...Дөрес булган безнең аерылышу,
Кавышу хата булган, булган ялгыш.

**Үксеп, үртәлеп**

Яратырга туган идем,
Яраттырып яшәргә.
Сукмагымны үзем салдым,
Ут кабыздым яшьнәргә.

Бәхеттәнме баш әйләнде,
Хисләрдәнме исердем?
Синең белән иркәләндем,
Татлы ләззәт кичердем.

Гомерле булмаган икән
Ул бәхетле минутлар,
Бәгыремне телә-телә
Яна эчемдә утлар.

Тыштан көләм, күңел елый...

Үксеп, үртәлеп елый.
Берсе берсенә ялганып,
Җанымда давыл дулый.

Аңладым югалтуларның
Бер-бер артлы килгәнен.
Хыялның, якты өметнең
Әкренләп сүнгәнен.

**Рәнҗетмиләр яраланган кошны**

Кизәнмиләр яраланган кошка –
Әдәп бар бит җирдә, канун бар.
Тоткан җирдән өзәр иде берәү –
Чү!
Туктата аны кануннар.

Кыйнамыйлар яраланган кошны,
Чат кан гына чакта йөрәге.
Дөнья малы, алтын таулар түгел,
Бер җылы сүз аның терәге.

Рәнҗетмиләр яраланган кошны,
Яше төшәр, тимә син аңа!
Яраланмас җаннар булмыйдыр ла
Һәм булмас та фани дөньяда.

**Бер җылы сүзең кирәк!**

Һич үземә урын тапмыйм,
Тыныч чагым бик сирәк.
Тик сине генә көтәм мин –
Бер җылы сүзең кирәк.

Карашым җиргә текәлгән –
Кайгылы вакыт, димәк.
Күзләрем елмайсын өчен
Бер җылы сүзең кирәк.

Уйчанланам, моңсуланам,
Сагынам булса кирәк.
Яңарып кабыныр өчен
Бер җылы сүзең кирәк!

**Әмәлен ничек табыйм?**

Адаштым да кебек,
Аңлаштым да...
«Сөям» дидең... Нигә алдаштың?
Мәхәббәтнең мәшһүр сукмагында
Бәрелә-сугыла йөреп кайнаштым.

Әй кайнаштым...
Җайлаштыммы әллә?..
Кире чыгыйм дисәм,
Юк хәлем.
Килгән юлым кисек,
Ялгыйм икән ничек?
Табыйм икән ничек әмәлен?

**Дәлилсез сүз**
Җеп җегерли җилләр җырлый-җырлый,
Айдан төшкән нурны бөтереп.
Сагына ул сине, бик сагына, диләр,
Сөендермәк хәбәр китереп.

Сагынадыр, бәлки, сагынадыр,
Дәлилсез сүз – күңел ышанмый.
Тәрәшле итеп күкне, җил җеп сава,
Ак ай нуры гына кыймшанмый.

**Юл чатында**

Җавап белән, ахры, соңардым, дип,
Үз җанымны үзем камчылыйм.
Татлы уйлар уйлап,
Белмим, әллә уйнап,
Йөрәгемне сиңа яучылыйм.

Уйга килә... – алга килсен иде,
Мәхәббәтнең килсен тигезе.
Парлы йөрәк белән,
Ныклы терәк белән
Корылсын ул Сөю нигезе!

...Юл чатында икеләнеп калдым,
Моңсуланып калдым кабаттан.

Тугры йөрәк кенә,
Көчле теләк кенә
Сүнгән учакларны яңарта.

**Чакыру**

Савыктыр син сулган гөлемне,
Терелтик бу чирле көнемне!..
(Бер мәртәбә сәлам биргәнгә
Мең бурычлы тоям үземне.)

Табигать-җир дәррәү уянган,
Чәчәгенә шомырт буялган,
Балкыталсаң балкыт бу җанны,
Сагыш сеңгән төссез дөньямны.

Өшегәннең, сулган, шиңгәннең
Дәвасы син, син ул мәрхәмәт.
Нәзакәтле җылы нур булып,
Күкрәгемә тул син, мәхәббәт!

**Йөрәгемнең әчетеп янган чагы**

Төтен җибәрепме күзләремә,
Гөл сибепме күңел үренә –
Шома гына үтеп кергән идең
Бәгыремнең иң түр җиренә.

Үткән идең үткенлегең белән,
Үкендереп өттең йөрәкне.
Артык гади булып яшәсәң дә
Бирә икән дөнья кирәкне.

Ак карларга күзем камаша да
Карый алмый торам беравык.
Йөрәгемнең әчетеп янган чагы,
Күңелемдә буран – бозлавык...

**Уйлыйм шул турыда**

Яман сүзләр әйтеп битәрлә дә
Яратам, дип аваз сал, имеш.

Ничек итеп җанга елышасың
Гамәлеңдә хәрам бар килеш.

Бу тәмсезлек, кадерсезлек белән
Су борылып агар юлыннан.
Тән ярасы китә, сүз ярасын
Дәвалап бак, килсә кулыңнан.

Сөй, сөел дә инде аерылыш –
Гөнаһысы, бәлки, бик зур да?..
Яратмавың белән бәхетлерәк
Булмам микән?
Уйлыйм шул турда.

**Рәхмәт әйтәм**

Рәхмәт әйтмим сиңа тапкан өчен,
Сине сөям, диеп ышандырып,
Күзләремә тутырып баккан өчен.

Рәхмәт әйтмим сиңа тапкан өчен,
Дәрья сулар, озын юллар үтеп,
Бусагама сукмак сапкан өчен.

Рәхмәт әйтмим сиңа тапкан өчен.

Рәхмәт әйтәм,
Асылыңа кире кайткан өчен –
Вәгъдәсез, кара йөрәгеңнән
Вакытында чыгарып аткан өчен...

**Иман нуры телим**

Иң әүвәл пакьләү кирәк эчнең керен,
Эчтә тулып ятмасын нәҗес, эрен.
Аһ, дәрига, эч тазарсын, эш тазарсын,
Булмаса, файда бирмәс коры белем.
*Акмулла*

Йодрык төйнәп кермә тормышыма,
Гайбәт чәчеп йөрмә янымда.
Син үзеңне үзең ямьсезлисең,
Тоз салам дип минем каныма.

Зур гыйлемле санап, буй-сыныңа
Соклануың һаман кимеми.
Тормыш күргән ирләр хатыннарның
Ипкә дәшкәненнән бизенми.

Зәһәреңне чәчеп кизәнсәң дә,
Күсәк, чыбыркыга үрелеп,
Күңелеңә иман нуры телим,
Шәфкать хисе кайтсын терелеп!

**Хыянәтең**

Һәр яңа яз бәгырьләрне телә,
Һәр яңа яз җанны яралый.
Язлар саен кошлар кире кайта,
Синең юклыгыңа карамый.

Һәр яңа яз тормыш бүләк итә,
Табигатьтә яшәү кузгала.
Шул чагында үксез улларыңның
Ничек сызлануын күзалла.

Телем әрәм итеп нигә сөйлим,
Күзалласаң әгәр шуларны,
Барыр идеңмени бу адымга?
Үксез-уксыз итеп улларны?

Юл яздырып, мәче балаларын
Адаштыра кайчак хуҗалар.
Тик алар да ия чыгар җиргә,
Җылы җиргә илтеп куялар.

...Язлар саен кошлар кире кайта,
Юклыгыңа синең карамый.
Синең дә шул безгә хыянәтең
Кайта-кайта җанны яралый.

**Өнәмим, ди**

Ялгыз-ятим кайгылардан арынмас,
Мәҗлесләрдә исеме телгә алынмас.
Аның өчен бер кеше дә аһ ормас,
Гел хәсрәттән торыр хәле ялгызның.

*Мәхтүмколый*

Күз яшедәй ачы язмышыма
Борынын җыерып карый берәүсе.
«Өнәмим, – ди, – зарлы бәндәләрне,
Көлеп яшәү – тормыш мәгънәсе!»

Бик яратыр идем мин дә, туган,
Гел елмаеп, көлеп йөрүне.
Бакыйлыкка күчми, фаныйлыкта
Тәмуг җәзаларын күрүне
Рәхәт диеп уйласаң соң әгәр,
Ал кайгымны, бирәм үзеңә:
Кадерлеңне үтереп тыксыннар да,
Шатлык нуры тутыр күзеңә!..

Гел елмаеп, авыз ерып йөре,
Ялгызлыгың тартсын чабудан.
...Уй-фикерең үзгәрмәсме шунда,
Авырлыкны бераз танудан.

**Хәрам микән?**

Баллы-майлы бу тормышның
Борычлысы гел безгә.
Алга китсәң, узынма, дип
Тибәләр астан тезгә.

Гөлләре хәрам микәнни,
Аллары әрәм микән?
Якты дөнья шатлыклары
Ник безгә саран икән?

Күз өстендә кашка тиңләп,
Җыен әрсезләр йөри.
Тормышның малын-мөлкәтен
Һаман комсызлар көри.

Безгә дигән бәхетләрнең
Бохарада орлыгы.
Ахры, анда да әшнәлек,
Кала көрпә, кырлыгы.

Намуссызлык кыса жанны,

Гаделсезлекләр белән.
...Ә шулай да мин дөньяга
Гөл үрчетим дип килгән!..

**Ышыклаучың юклыктан**

Өзелә инде яшел камыш,
Түгелә инде зәңгәр күл.
Җилгә уч-уч ком тоттырган –
Күзгә күчә шыксыз чүл.

Җир куптарып дулый дулкын,
Кызганмый һич зилзилә.
Тормыш кырыс, ни килсә дә,
Ышыксыз башка килә.

Ышыксыз – шыксыз буладыр,
Шыксыз – ышыксыз булгач.
Ничек ямьле булмак кирәк,
Ышыклаучың юклыктан гел,
Күзеңә ком-яшь тулгач...

**Хурлык шаукымы**

Кешенең асылы санап
Табынган идем,
Йолдызың булып яныйм дип
Кабынган идем.

Артыграк яндым, ахры,
Артык балкыдым...
Кадеремне ким күрдем дә
Җанны талкыдым.

Өтеп ала икән җанны
Хурлык салкыны.
Йөрәктә калган авырту –
Шуның шаукымы.

**Парлы килеш...**

Арыганда, назлау сорап,

Күзеңә бактым.
Бер дә исең китми генә
Җилкәмнән кактың.

Башкаема урын тапмый,
Тезеңә салдым.
Битараф карашың күреп
Хәйраннар калдым.

Дусларыңнан җәберләнеп,
Яныңа килдем.
Бер булса да җылы сүзгә
Бик мохтаҗ идем.

Карашыңнан калтыранып
Яндым, көйрәдем.
Парлы килеш ялгыз яшәп,
Тормыш сөйрәдем.

**Ямьсез әйттең**

Йончыган чагың булгандыр,
Булмагандыр, димимен.
Шул чагында бигрәк ямьсез
Итеп әйттең:
Сөймимен!..
Әмма синең уйларыңда
Хаклык бардыр, димимен...

**Һич югында**
Җирдән кубып, канатланып очам сиңа,
Очам сиңа, коңгырт күгем, зәңгәр күзем.
Очам сиңа кул-канатым җилпи-җилпи,
Яңгырый аваз: «Җилгә җилкән күлмәгең ки!»

Галәм ярып, арып-талып, уйга калып,
Очам сиңа, очам гына дөнья буйлап.
Хыялларда инде күптән табыштык без,
Кавыштык без, бәйрәм иттек никах-туйлап.

Табыштык без, кавыштык без синең белән,
Үзем уйлыйм, үзем елыйм, үзем көләм...
Ә чынлыкта җирдән барам бата-чума –

Сөенәмен,
Һич югында, уйларымда әкият күрәм,
Әкиятләр тамамлана уңыш белән!

**Яннарыңнан китмим, диеп**

Сары яфрак – сагыш төсе,
Яннарымда очма әле.
Бөтерелеп баш очында,
Иңнәремнән кочма әле.

Сагышларым тулып ашкан,
Үземнеке – үземә.
Тоташ сары пәрдә булып
Күренәсең күземә.

Япь-яшь килеш картайгансың,
Сарыга сабышкансың.
Яннарыңнан китмим, диеп,
Җиренә ябышкансың.

Кәүсәмнең аяк астында
Булыйм, диеп, туфрак,
Җир җылытып үләсең ич,
Сары, сары яфрак!

**Югалтасым килми**

Югалтасым килми үз ярым,
Син – сөекле, газиз, тиң парым.
Сөюемнән килми танасым,
Синең белән килә барасым.

Югалтасым килми үз парым,
Син – яңгырым, җилем, ак карым.
Бергә булсын юллар, сәфәрләр,
Ялгыз калу юлда хәтәр лә.

Югалтасым килми үз парым,
Ямьле җәем минем, көз, язым.
Бергә үтсен гомер юлыбыз,
Нәсел җебе – тусын улыбыз.

Югалтасым килми үз ярым,
Шатлыгым син минем, таң, назым.
Йөрәгемдә йөргән хисләрнең
Бәян иттем әле бик азын.

**Холык шул ук**

Күзләремә карап: асыллыгың, диеп
Әйтмәдеңме әллә?
Әйттең бит.
Мин мәңгегә синең белән, диеп
Антлар эчтең,
Әмма киттең ник?

Киттең,
Кайттың,
Тагын китеп бардың –
Сәер хәлме?
Түгел, аяныч.
Ямьле чакны шулай тиз оныткач,
Каян тусын сиңа ышаныч?

Каян килеп сиңа өмет баглыйм,
Терәк белән көнем үтәр дип.
Алтыдагы кире беткән холык
Алтмыш яшьтә башка җитә ник?..

**Чәчәктәй гомеркәем**

Бүләк иткән чәчәкләрең
Шиңделәр, корыдылар...
...Мине күреп кем елмаер?..
Сине сагынып кем елар?..

Кемнәр искә алыр,
Алар
Чәчәктәй яшәде, дип.
Мәхәббәткә дә кайчакта
Кирәк икән терәү, сип.

Кеше сүзе кеше үтерә –
Хак икән, бәгырькәем.
Нахак җәбер белән сүнде

Чәчәктәй гомеркәем.

**Җәйне көткәндә**

Колач кына җәеп, җәйгенәем,
Күкрәгеңә кысып җылыттың.
Син, солтанат егет, ямьле язга
Чыгу белән, мине оныттың.

Көзгә керсәм, көзге муллык белән
Сыгылып төште өстәл өсләре.
Сары яфрак үртәп көлде миннән –
Гүя сүнгән сөю төсләре.

Яңгыр гына ява дигән идем,
Кырпак төшеп, кырны агартты.
Табанымнан җир салкыны менеп,
Күзләремә кадәр кызартты.

Колач җәеп җәйне көткән чакта,
Кышы килеп буран уйнатты.
... Хәтта буран кагылмыйча үткән.
Хисләремне шул җәй чуалтты...

**Мөлдерәмә күңелемнән**

Тамчы-тамчы гөлләреңнән
Күзләрем алалмадым.
– Синең өчен юк, – диделәр,
Каберен табалмадым.

Табалмадым...
Тамалмадым,
Тамчы булып, чык булып.
Мөлдерәмә күңелемнән
Түгелде хисем тулып.

**Рәхәт икән**
Юк, минемчә булмады бу тормыш...
*Зөлфәт*

Язмышлардан узмыш юк, дибез дә
Буйсынабыз шулай тормышка.

Ә көнкүрмеш алдан әзерләнгән,
Хәстәрләнгән безнең тумышка.

Фикер йөртү, уйлау вазифасы
«Биекләргә» фәкать йөкләнгән.
Безнең зиһен, акыл, тәкъдим кертү –
Үзебез туганчы ук «бикләнгән».

...Бер өйрәнгәч, уйламыйча яшәү –
Бик рәхәт икән, рәхәт.
Синең өчен Әбрәй уйлап куйган,
Һәм хәл иткән инде Бирәхмәт...

**Язылмаган хат**

Әткәем, без сине көттек,
Ишек ачылган саен.
Айлар үтте, еллар үтте,
Тапмадың килү җаен.

Сау-сәламәт әти килеш
Үксезлектә калдырдың.
Күрәләтә утка салдың,
Күрә торып яндырдың.

Килер дидек, без бит аның,
Үз кызы, үз уллары.
Безнең туңганны чамалар,
Өшесә үз куллары.

Кара күннән пәлтә кигән,
Аяк йөзенә кадәр,
Дип сөйлиләр синең турда,
Безләргә юк бер хәбәр...

Көттек сине, һаман көттек,
Ишек ачылган саен.
Яшьләр кипте, еллар үтте,
Тапмадың күрү җаен.

...Бу минем күңелдә йөргән
Язылмаган хатларым.
...Күз алдыма сының басты,
Ашыгып шунда атладым...

**Мәсхәрә**
*(Поэма)*

**1**
Тәнеңнән ага гөрләвек,
Юалар мәетеңне.
Бөтен авыл сөйләр инде
Чыгарып бәетеңне.

Менә өең, менә гармуның,
Гармуныңда калды гарь-моңың.
Менә чалгың, менә кайрагың.
Походларга чыккан байрагың.
Менә тырмаң – сөяп куелган,
Кармакларың җепкә җыелган.
Шушмаларда* калды карашың,
Төнбоеклар алды карашып.

Хәбәр килгәч, җилләр үкерде:
Ул үз-үзен бүген үтерде...
Ул үз-үзен бүген үтерде,
Нәселенә кайгы китерде.
Асылынып ап-ак каенга,
Якыннарын салды ваемга.
Япь-яшь агач ничек сынмаган,
Йөрәк тынган, сәгать тынмаган –
Кул сәгате ята үләндә,
Вакыт кирәкми шул үлгәнгә.
Бәхилләшү хаты шунда ук,
Зар елаудан хәзер файда юк...

———

* Шушма – елга исеме.

* * *

Әткәй, нигә
Безне ташлап киттең?
Без ир бала – синең терәгең.
Үзең дә син ятим үскән егет,
Беләидең ата кирәген.
«Инәлепләр елый идем, – дидең, –
Зур-зур ирләр кагып-сукканда.
Әтиләләр ипи ашады,
Без
Ач карынга төкерек йотканда.

Әтиләләр алда, тавышлар көр,
Әтиләләр – тормыш кендеге.
Ә без артта, ә без бер кырыйда
Ятим-җилпе бала берлеге.
Бәлки әле, ятимнәрдән яман
Ач булгандыр алар,
Кем белә?
Тик әтиле алар!
Әтиленең
Дәрәҗәсе алдан йөгерә...»
Искә алып шулай офтанганың,
Үртәлгәнең һаман хәтердә.
Бүген менә үзең теләп үлеп,
Кереп яттың салкын кабергә.
Үзең теләп безне ташлап киттең.
Ташлап киттең, ташлап калдырдың.
Упкыннарга аттың тәнебезне,
Тәмуг шулдыр – терелә й яндырдың.
Сиңа ничек газиз булмады соң
Үз каныңнан туган улларың?
Көлә-көлә әкият сөйли идең,
Колакларда тавышың моңнары.
Гармуныңны алып кулларыңа,
Үзең уйнап, үзең җырладың...
Ә нигә соң безне алдадың син?
Безнең белән нигә тормадың?
Ә нигә соң уч төбенә куеп,
Өскә чөя идең безне гел?
Әни-бәгырь... бәхете ташый иде,
Гүя яңа чәчәк аткан гөл!
Күптәнме соң,
«Бик яратам сине», –
Дип, әнигә шигырь сырладың.
Ә беркөнне...
Кинәт,
Көтмәгәндә
Бәхетләрне безнең урладың.
Урладың да... соңгы куркак кебек
Китеп бардың әйтми, сөйләми.
Дөнья бит бу,
Тирес арбасын да
Эзгә кертеп булмый көйләми.
Их син, әткәй,
Хыянәтең белән
Күңелләрне таштай катырдың.

«Ышанычлы мин» дип, юлга дәштең,
Йөрәкләргә хәнҗәр батырдың.
...Печән өсте.
Кайнар җилне йота
Сөт кипмәгән алсу иренем.
Такыя үреп уйнар чәчәкләрем
Пакус-пакус кала тезелеп.
Үз алларын чыгып җитәләр дә
Зур абыйлар туктап ял итә.
Касыгымда нидер кадый башлый,
Артларыннан куып чак җитәм.
Тәмәкесен тартып, төкеренеп
Сүгенәләр өч-дүрт кат итеп.
Барып җитсә сиңа,
Күргәнемне
Язып салыр идем хат итеп.
...Бу дөньяны яраттың бит үзең.
Агачларның җыеп бар төрен,
Бакча иттең чокыр-чакырларны.
Сукмакларны алды гөл төреп.
Ул бакчада сирень чәчәк ата,
Шомырт пешә тулып, каралып.
Ул бакчада гөләп гомер итә,
Көзен шиңеп, язын яралып.
Без уларың – үз кулларың белән
Утырткан гөл, агач шикелле –
Синең теләк-ихтыярың белән
Бу дөньяга килгән бит инде.

Юлга чыга калсаң, үзеңнән дә
Яхшы булсын, диләр, юлдашың.
Ни хәл итик,
Ятим-җилпелектән
Башланды шай бүген юл башы...

* * *

Үзегез теләп үксез итмәгез,
Үксез итмәгез безне, әтиләр!
Елап-ялварып сорыйбыз сездән:
Мордар китмәгез, исән әтиләр!
Кемгә ышанийк бүген тормышта.
Безне үзегез әтисез иткәч,
Ирәеп кенә йөрер урында
Елап-кимсенеп көнебез үткәч?

Йөрәктә – әрнү, күңелдә – үпкә,
Кабер янында башны исәк тә.
Тәннәр күшеккән,
Җаннар өшегән.
Иясез калган туннар кисәк тә.

Үзегез теләп үксез итмәгез,
Үксез итмәгез безне, әтиләр.
Юк,
Хакыгыз юк,
Безне калдырып
Мордар китәргә,
Исән әтиләр!

**2**
Җир йөзендә өсте-өстенә золым,
Бер Ходаем, үзең ярлыка.
Кеше өчен җаныбыз көймәгәнгә,
Шушы мәсхәрәгә калдык та...

Зөбәер кайда дисезме –
Актаныш төбәгендә.
Яшел коймалы зираты
Авылның үзәгендә.
Халкының санын сорыйсыз,
Исәпсез түгел халкы.
Биш йөзгә тулар-тулмастыр
Җәмгысы – яше, карты...
Сабый чакта шул җирләрне
Зур дөнья дип уйладым
Ташыды күргән-белгәнем,
Күңелемә сыймады.
Ага ямансу уйларым,
Агымсуга кушылып.
Авыл җирендә берәү дә
Утырмый кул кушырып.
Балачак күзе җемелди
Тамчы-тамчы чулпыда.
Туган җирдә йомышыңны
Кемгә әйтсәң – шул тыңлар.
Чәчкә саен бер көй монда,
Агач саен хатирә.
Олысы да, кечесе дә
Синең хәлеңә керә.
Актарыла, дулый үлән,

Чуала чәчәкләре.
Мордарларны тәмуг көтә –
Алда күрәчәкләре.
Тиктормас чагы яшьлекнең
Торгын елларга тарды.
Аллар ут булып янды да,
Гөлләр чүп булып калды.
Бәян иттем йөзен-буен
Зөбәер авылының.
Инде тарихына керик
Көн итмеш кавеменең.

* * *

Заманында гөрләп торган ике
Мәхәлләле авыл булган ул.
Себерләрдән Семберләргә кадәр
Аның аша үткән олы юл.
Әүвәлендә чапкын хәбәр йөрткән,
Әмер килгән өяз, олыстан.
«Гаеплеләр» һаман табыла торган,
Чүпләнелә торган берочтан.
Чүпләгәннәр, чеби чүпләгәндәй,
Авылның иң асыл затларын:
Кулак дип тә, чит элемент дип тә,
Сөннәтче дип – авыл картларын.
Идел буен дер селкетеп алган
Сәнәкчеләр сугышы, мәсәлән, –
Тарих йотты,
Ләм-мим сүз дәшмәде.
Зөбәерләр анда нишләгән?..
Ачлык карап торган.
Ачлыгы да
Татар җирен изгән, нигездә.
Кая гына бакма, кан коела,
Әфган нигә иде соң безгә?
Афәт арты афәт, фаҗиганең
Ачылыгын тоймас өченме?
Әллә тышкы,
Әллә эчке әмер
Эчерде дә илне эчерде.
Эчте ирләр, айнымастан эчте.
Кайсылары эчте үлгәнче.
Ирен тыялмаган хатын эчте,
Эчте Рәсәй тәмам бөлгәнче.
Салым түләп үзе ач утырды,

Күтәрәмгә калды сугышта –
Гомер буе кыен күрде авыл,
Фәкыйрь һаман – сугыш, сугышма...
Нәселенә шундый бәла-каза
Кагылмаган ничә нигез бар?
Саный китсәң, һәрбер өйдә ятим,
Һәрбер өйдә сагыш-интизар.

Дәлил өчен тик берничә генә
Йортка кереп чыгыйк, әйдәгез.
Нәтиҗәсен һәркем үзе ясар,
Нигә мордар бик күп бәндәбез?!

* * *

Кояшкаем, Аем, Җирем, Күгем,
Танып беләсезме Гамбәрне?
Күрдегезме, ишеттегезме сез,
Агу эчкән, дигән хәбәрне?
Амбар өендә ул агу эчкән,
Әллә ялгыш, әллә мәҗбүри.
Халык телендәме?
Хәләл хакын
Алалмады, дигән сүз йөри.
Икмәк чәчте, һәрбер капчыгына
Чиләк-чиләк агу болгатып.
Кан каплады күзен кичкә таба,
Үзен үзе сүгеп, юатып,
Көчкә атлап өйгә кайта иде,
Таралганмы әллә буыны?
Бәриясе мунча ягып көтте,
Хәл алалды бераз юынып.
Чәчү арты шыта бәрәңгесе –
Тагын агу, тузан, гөрелте...
Колорадо кортын бетерәм дип,
Агу сибелмәгән җир бетте...
Әзмәвердәй ирләр китә сызып,
Яман чирдән китә – рактан.
Гамбәрнең дә китүләрен, хәер,
Эзлисе юк бер дә еракта.
Эче янып бәгыре өзелгәнгә,
Шул агуга барып тотынган.
Әйтәләр бит:
Зәхмәт җиңмәк берәү
Зәхмәт белән генә котылган.
Өмә ясап нарат өй күтәрде,

Келәт, мунча – калай түбәле.
Корал эшли, егет бәя ала,
Пар быбылын гына күр әле.
Такта кисәгеннән чәчкә уйды
Түшәменә, капка, ишеккә.
Гадел хезмәт белән тернәкләнү
Уе иде анда ничек тә.
Алтын иде кулы, әй чос иде,
Бөтен иде көткән дөньясы.
Кайчан чакырсаң да йөгереп килер,
Кешелекле иде, риясыз.
Зөбәердә ярты авыл халкын
Өйле итте, итте мунчалы.
Истәлеге булып сарай-йортлар калды,
Имән матча, имән тупсалы.
Түбәтәй Тау, Олы Бүләкләрне*
Аз урады, ул аз сөрдеме?
Авылының күз карасы кебек
Җан иясе түгел идеме?

---

***** Тау, басу исемнәре.

Сугым малын аңа чалдырдылар,
Калдырмады Корбан гаетен.
Бүген менә алмачуар атта
Апкайттылар салкын мәетен...

**3**

Октябрьнең якты, ал кояшы
«Нурлый» башлагачтын илемне –
Нәселкәем динен, денен җуйды,
Җуйды хәтта туган телемне.

Кирәк икән диеп җилкендек без:
Сахра ясатырбыз тайгада.
Елгаларның агымын борып куеп
Эшләтербез безнең файдага.
Кирәк икән, урманнарны кисеп,
Күлегезне күккә асарбыз.
Бака сазлыкларын чүл итәрбез,
Егетләрдән хатын ясарбыз.
Пионердан акыл тупласыннар
Искелекне сүгеп яшәргә.
Павликтан* үрнәк алсын бала
Үз атасы белән нишләргә?..

Хөррият, әй,
Теләгәнчә эчсен,
Айнымасын, күпне күрмәсен.
Исеректән тиле бала тусын,
Ник болай бу дөнья, димәсен.
Салмыш баштан бик сөйләнсә әгәр,
Партиядән чыгарып атарбыз.
Бер куркытсаң, телен тыя алар,
Шул җай белән яшәп ятарбыз.
Бүген менә ирләр чәч үстереп,

---

* Үз әтисен дошманнарга саткан Павлик Морозов күздә тотыла.

Толым-толым итеп үрәләр.
Үзләренә коммунизм төзеп,
Яшәп күрсәтәләр түрәләр.
...Кирәк икән, әйе, кирәк икән,
«Муллагызны кыйнап китәрбез...»
«...Аллаңны да, анаңны да!..» дигән
Җәмгыятьтә «гөрләп» үсәрбез...

*** * ***

Бәтке буе куе кара сазлык,
Бәтке быел тагын җан сорый.
Кашка Тауның итәгенә ятып,
Бер елады моңлы Миңнурый.
Бер елады.
Буган елга кебек,
Тыелып торган кайнар яшьләре
Акты гына кара күзләреннән,
Ышанып бит аңа яшәде.
Ышанып бит алты бала тапты,
Миңнурыем-Нурлым, дигәнгә.
Ул шатланып карый иде, улы
Зур итеген киеп йөргәнгә.
Зур итекләр тезелешеп калды,
Көтеп аның аяк җылысын.
Эшкә чыкты бүген тол Миңнурый,
Баласының алып олысын.
Баласының олы дигәненә
Ун яшь тә юк әле, тик җиде.
Бүтән түгел,
Алар бәхетенә
Яман карашлыдан күз тиде.
Келәт тикле келәт күтәргәнне

Сүз күтәрер гайрәт тапмыйча –
Гарьләнгән дә, имеш, түзәлмәгән
Үзен үзе суга атмыйча...
Үзен түгел, безне суга салды,
Судан алып утта яндырды.
Балигъ булалмаган алты бала –
Кемнәр хөкеменә калдырды?..
Авылда да имансызлык чире
Намуссызлык белән бергә гел.
Үксез бала барыбер «әти» диеп
Сыенырга тели кемгәдер...

*** * ***

Таягымны юлдаш итеп,
Җиде төннең утасында,
Улым, тагын сине эзлим,
Бәгыремне корытасың ла.
Кайда аунап ята тәнең
Бер кадерсез бәндә булып?
Өйдән чыгып киткәндә үк
Күзкәйләрең бетте тонып.
Машинада элдерәсең,
Үзең сәрхуш,
сәрхуш вакыт.
Куркып торам:
Ауган диеп
Кемнәр әйтер,
кайчан кайтып?
Кемнәрнеңдер газизләрен
Таптатмасаң, елатмасаң,
Кеше каһәрләрен алып,
Авыр уйлар уйлатмасаң –
Ярый да бит ялгыз булып,
Үз башыңа гына җитсәң,
Гөнаһ булса да әйтим соң,
Ак башымда шундый исәп.
Тапкан балам миннән алда
Туфрак булсын, димәдем мин,
Синнән ямьсез сүз ишетер
Өчен багып-сөймәдем мин.
Таягымны йөртәм алдан,
Караңгы төн ауган өскә.
Үзем уйлыйм, үзем елыйм,
Әлләниләр төшә искә:
Кеше диган зур исемне

Кайчан суга салдык соң без?
Дәвернең кай ноктасында
Шушы көнгә калдык соң без?
Сайлау җитсә, күңелләрне
Хәмер белән күреп мәллә?
Ур-ра кычкырсын өченгә,
Берәр ярты биреп мәллә?
Нинди дөнья булды соң бу –
Яшәп-яшәп киттек кире?
Кая барма – дөреслекне
Сәрхуш килеш яклау чире.
Сәрхуш килеш бар да даһи,
Сәрхуш килеш бар да батыр.
Әй юалар яңалыкны
Кызган баштан дөбер-шатыр.
Юалар бала тәпиен,
Юыла өй җиһазлары.
Туган көннәр, үлгән көннәр,
Юыла эш остазлары.
Юыла каз өмәләре,
Сугым ашы, эшнең башы.
Армиягә киткәннәрнең
Юыладыр керфек-кашы...
Сәбәпләр күп,
Юа-юа
Акылларын җуйганнарны
Җыя тора элмәк, агу –
Дөньясыннан туйганнарны.

*** * ***

Мордар китсә берәү элек заман
Үз-үзенә ягъни кул салып,
Кая ди ул зиратына кертү,
Җеназага чакыру ат чабып!
Канун каты булган.
Шуңа кеше
Тыелып калган барган җиреннән.
Инсаф булыр иде,
Элгәргечә
Оят көчле булса үлемнән.
Ата-баба кануннарын бозып,
Табигатьне тәмам корыттык.
Аны монда алып болгадык та
Моны анда алып ыргыттык.
Илсез итә, телсез итә яздык

Зур бер милләт, зур бер халыкны.
Шуның әҗере – яңа маңкорт туып,
Үз нәселенә бүген каныкты.
Шакшылыкка чумган бу дөньяда
Аек булсаң да әле бик таман.
Газиз авылым, синең күзләреңә
Өмет белән карыйм яңадан!
*1982–1994*

**Инша**
*(Поэма)*

*Сабырлык бир, тормыш, бу дөньяда*
*Наз күрмәгән моңсу ирләргә!..*
*Фәннур Сафин*

**1**
Инша яза сигезенче класс,
«Минем әти» – инша исеме.
Сорауларның берсе:
«Сезнең өйдә
Әти кирәк,
Якын кешеме?

Хатирәләр,
Истәлекләр аша
Әтиләрнең холкын ачыгыз.
Хуҗалыкта ниләр эшли алар,
Кайчан тәмле ризык-ашыгыз?

Тирә-күршегездән җайлап кына
Балачагын сорап белегез.
«Якын әби», «бабай» сүзләренең
Тарихына бераз керегез!..

«Ир кадере»,
«Ата»,
«Күрше хакы» –
Нинди сүз ул?
Нәрсә аңлата?
«Хак» дигәннең мәгънәсе нидә?
Нигезендә нинди сер ята?»

Менә шундый эш йөкләнде бүген
Унбиш яшьлек егет-кызларга.
Гамьле уйлар керде башларына,
Каләм кирәксенде куллар да...

*** * ***
Инша, инша...
Ничек башларга соң?
Аптырады тәмам Сөмбелә.
Әнисенә әйтсә,
Апасыннан

Кыйнатырга мөмкин,
Кем белә?

Болай да бит һәрчак кыерсытып,
Читкә кагып,
Үртәп көләләр:
– Атаң кызы,
Аны яклыйсың, – дип, –
Һәр көн саен бәгърен теләләр...

Инша, инша...
Ничә көннәр инде
Әти кеше кайтмый бит өйгә.
Бөтен кыюлыгын җыйды да ул
Кереп китте күрше әбигә.

* * *
– Аркылыны буйга салмассыз сез,
Ачык калса, ишек япмассыз.
Кыз сорыйлар әнисенә карап,
Тирә-юньдә кияү тапмассыз... –

Кызды гына күрше Кәримә әби:
– Битегезгә ыштыр япкансыз!
Ир чыгар ул анагызга, әмма
Атагыздай кеше тапмассыз!

Килүчесе булыр мондый йортка,
Хан сарае салып китте бит.
Бирәү булса, җиһаз бүләр иде –
Гомер буе билен бөкте бит.

Тәрбиясе артык затлыдан шул.
Гел юл куя килде үзе дә.
Әтиеңне әйтәм,
Кул күтәрү түгел,
Юк иде бит
Тавышларын
Күтәрепләр әйткән сүзе дә!..

Орышты да әби,
Юатты да.
Күзне ачты, телне тешләтте.
Оятымнан җиргә сеңәр идем,
Их син, әни,

Безне нишләттең?
Их син, әни...
Явыз дошман ясап,
Әтидән гел йөзең чөердең.
Әтине син авыз ачмас иттең,
Үзең һаман бугаз киердең.
Синңа кушылып без дә гайрәт чәчтек,
Кая ди чәй?.. –
Сәлам бирмәдек!
Чын ир-атлар «Мерседес»лар ала,
Акчаң аз, дип
Сүктек,
тиргәдек.

Эндәшмәгәч,
Аңа сыя диеп,
Йөрәгендә борчак куырдык.
Көн тудымы,
Яшел акча* сорап,
Сөлек булып канын суырдык.

Безнең шәфкатьсезлек телсез итте,
Күз төпләрен өтеп каралтты.
Нахак бәла һаман туа торды,
Әни көн дә ялган яңартты.

Беркөн шулай
Юкка чыкты эти:
Төн кунарга өйгә кайтмады.
Мендәремне кысып еладым мин,
Өскә беркем юрган япмады...

---

* Яшел акча – доллар.

*** * ***

Авыр иде бүген Сөмбеләгә...
Зәңгәр күкне, җирне күзләде.
Каләме дә бер йөгереп алды,
Бер туктады,
Тагын тизләде,
Әтисенә булган кайнар хисен
Җыр итәрлек
Сүзләр эзләде:

«Торган йортым – хан сарае,

Кәрнизләре челтәрле.
Инша язып,
Җырга салып,
Сагышларым бетәрме?

Безнең баскыч култыксалы,
Култыксасы бизәкле.
Әтием, моңсу карашың
Өзә генә үзәкне.

Син ясаган кошлар парлы,
Гөлләрең ак чәчәкле.
Язмыш микән ялгыз итте,
Әтием, киләчәкне?

Безнең баскыч култыксалы,
Култыксасы бизәкле.
Әтием, моңсу карашың
Өзә генә үзәкне...»

**2**
Язмый каләм. Инша тәмам түгел...
Мәктәбенә килде ул тагын.
Мөгаллимә апа каршы чыгып,
Ачып салды аңа бар җанын:

– Килә идем сезнең урам буйлап
Ашыга-ашыга дәрес бирергә,
Күз алдымда әкият үсеп чыкты,
Төшеналмый тордым серенә:
Балта белән чигү чиккән берәү
Тәрәзәгә,
капка,
коймага.
Рәссамнарча нечкә, нәфис тоем! –
Яктырыплар китә уйлар да!..

Хан сарае дисәм –
Гади бер йорт,
Күпме җылы сеңгән үзенә!
Челтәр итеп нәкышләнгән кәрниз –
Һәр детале төгәл, төз генә...
Тукта, тукта!
Гади сурәт кенә
Түгел монда – тулы поэма!

Менә Мәҗнүн – башына таш төшә,
Димәк,
Торалмаган тормыш җаена.
Тезләндергән тормыш...
Уклар оча,
Йөрәгенә төбәп атылган.
Ләйләсендә
Киресенчә – шатлык,
Фаҗигадән «балкып ачылган...»

Укыйм,укыйм,
Укып туя алмыйм,
Һәрбер сурәт серле вакыйга.
Шаклар каттым,
Үлемсез җыр
Бүләк иткән оста – бакыйга.

Шукланудан түгел,
Сокланудан
Әллә кемне килде кочасым.
Тыкрыктан шулчак берәү чыкты,
Шушы мәллә эшнең остасы? –

Бер атлады,
Бераз басып торды,
Бума ютәл өзде үзәген.

Башын иеп аннан китеп барды,
Ирексездән аңа иярдем.

Эчтән уйлыйм:
«Юктыр, бу эшне, – дим, –
Чәчрәп торган бүтән башкарган.
Ә бу агай?..
Сүнгән,
бөкрәйгән...
Ә бу агай
Тәмам таушалган...»

***

Әсәренеп шушы гүзәллеккә
Кире килдем,
Китә алмый торам кузгалып.
Янәшәмдә берәү пәйда булды,
Сүз кушкачтын, калдым югалып.

– Ушың китеп карап торасыңмы,
Матурлыкка җавап табалмый?
Фәрештәсен качырдылар йортның,
Гаугалы йорт изге булалмый!

Син үзең дә быел килдең бугай
Мөгаллимә булып авылга.
Дөрес укыт!
Шәкертләрең
Таш үстермәсеннәр бавырда!

...Хуҗасы, дим,
Япь-яшь егет иде,
Шәһәр кызын үзенә яр итте.
Ул чагында машиналар юнь чак,
Юк,
Пар атларда моны җилдертте...

Тарантастан кулларына алып,
(Сабый бала ничек сөенә),
Җиргә аягын да тигермичә
Алып кереп китте өенә.

Күрше булгач, бар да күз алдында:
Кайтты килен әзер ояга.
(Күпме яшьләр кеше өсләрендә
Гомер үткәрәләр заяга.

Тулай торак диеп аталганы
Һич кенә дә кулай түгелдер...)
Ә бу менә
Бәхете – аягына
Уралыплар туган килендер, –
Туй иттеләр.
Гөрләп торды авыл...
Әмма килен көйле булмады:
Ирнең туганнарын тиз биздерде,
Күрше хакы диеп тормады.

Ата хакын хак дип белмәделәр,
Кара тавыш булды көн димә.

...Музей итеп тотар нигез бит бу,
Ядкяр итеп саклар хәзинә!

Хыянәтнең ни икәнен белми,
Эчеп теңкәсенә тимәде.
Терсәк буе баласыннан башлап
Әтисенә каршы өндәде.

«Алтын балык» әкиятендәмени? –
Иргә урын – аяк очында.
Каен сеңелләрен тез чүктереп,
Биетмәкче булды учында.

Хөкүмәтнең айлар, еллар буе
Түләмәгән чагы хезмәткә.
Төрле кеше булды, кайберләре
Тиен табалмады икмәккә.

Ә бу хатын маена чыдый алмый
Ырлап менде ире өстенә.
Симергән эт иясенә каба –
Халык әйткән тәҗрибәле сүзләр
Буш сүз түгел, ай-һай, берсе дә!..

Алиментка бирде, искәрмәстән,
Көн-төн эшләп торган шул ирен.
Нинди абруй?.. –
Салып таптады ул
Калдырмыйча ирнең сау җирен.

Аңамы соң бу нәселне сүзләү?
Үз артына борылып карасын,
Энекәше пычак белән чәнчеп
Рисвай итте тапкан анасын.
Анасы да задур хатын, димәк,
Үз улым бит диеп тормаган,
Пычак ярасыннан төзәлүгә,
Баласына төрмә юллаган...

Кем акылын кемгә бирәсең соң,
Фигыле тар булгач тумыштан.
Ирне үз өенә кертмәс өчен
Йөрәк кирәктер ул корычтан?!

...Китим әле,
Килен кайтуына
Чәй әзерлим, әбәт җитәдер.

Бер-береңне хөрмәт итү кирәк,
Гомер кыска,
Бик тиз үтәдер.

Анасына карап кыз сайладык,
Шөкрана итәм Ходайга.
Үз кайнанам белән әйбәт тордым,
Шуңадыр дим эшебез уңайга.

*** * ***

«Сөйләшми ул,
Бер сүз алалмассың», –
Дигән иде аны белгәннәр.
Без сөйләштек,
Үзем телсез калдым,
Ник кадерсез
Өзелеп сөйгәннәр?..
Тормыш, тормыш...
Нинди язмышлар юк
Кечкенә бер авыл җирендә?
Укытуы бик җиңелдән булмас,
Сөйләшсәк тә ана телендә.

Бу агайның ике кызы миндә:
Белем бирәм,
Бирәм тәрбия.
Беренчесен эзгә кертеп булмас,
Икенчесен?
Анысы – Сөмбелә...

Гомер буе эшләп,
Картлыгында
Җылына бит учак утында.
Гайре сәер:
Хан сараен ташлап,
Гомер итә ферма йортында.

Дөнья телсез иткән бу агайның
Һай, беләсем килде уйларын.
Сорау бирдем җайлап,
Ул сөйләде,
Ялындырып һич тә тормады...

**3**

– Мәхәббәтне минем сөйли китсәң,

Боз кантары булыр сау җаның.
Сыенырга тере тән табалмый,
Агачларга күчте хыялым.
Агачларда нәфис гөл «үстердем»,
Түмәрләргә әнә «җан өрдем».
Мин аларда кеше тоялмаган
Сылу сәнгать,
Күндәм тән күрдем.

Агач булып, агач тойды мине –
Чәчәк булып «үсте» кулымда.
Мәхәббәтне аңлый белгәннәрнең
Гөлләр сибәр идем юлына!!!

Аһ, ул Сөю!
Актарылып кайный
Дәрья булып бәреп чыгарлык!
Таш бастырдым аңа...
Мондый мәсхәрәгә
Дәшмәсәң, тик
Җитә чыдамлык!

Минем исем күптән «түмәр» инде,
Сөйкемсезмен, ахры, бер дию.
Аңласагыз иде,
Ир затында
Нинди нәфис була ул Сөю!!!

Аһ, ул Сөю!..
Аның кайнарлыгын
Нинди сүзләр белән аңлатыйм?
Йөрәгенә тимер кадак кагып,
Сөюемне дарга кадаклыйм!..

*** * ***

Балаларың искә төшәме, дип
Сорап торасың бит, әй, наный.
Муеныма утырып йөргәннәрен
Искә төшерәм дә,
Җан кайный...

Ничек кенә сагынамын әле,
Ничек кенә өзелеп яратам!
Күз алдымда сабый вакытлары
Бөтен кайгыларым тарата.

Исән ата белән үксез итте,
Мин-минлеге белән ялгышты.
...Усаллык та кирәк булган икән,
Юк, үзгәртеп булмый язмышны.

Хатын-кызны алдау, елатуны
Анам рәнҗүенә тиңләдем.
Гаеп бардыр минем яшәүдә дә,
Үземне мин Йосыф димәдем;

Тәрәз кашагамны гөлгә төрдем,
Күз өстендә каштай торсын дип,
Балам кулы белән таш аттырды –
Күңел тәрәзәмне кырсын дип...

Кырылды ул,
Чәлпәрәмә килде,
Олы иде,
якты,
үтәли –
Яратуны саклап калу өчен,
Җәнҗал кирәк икән,
Кит әле!

Җаным туңды хәзер,
Илһам бетте,
Йөрәк куша –
Балтам тыңламый.
...Балаларың искә төшәме, дип
Сорап торасың бит, әй, наный.

Ничек кенә сагынамын әле,
Ничек кенә өзелеп яратам!
Күз алдында сабый вакытлары –
Бөтен кайгыларны тарата.

Телне чиштең, наный,
Сөйләтәсең,
Аптырашта кара күзләрең.
Җыру яздым Сөю хакында мин,
Тыңлап кара әле
Сүзләрен.

* * *

Мәхәббәттә минем язмышыма
Юлыкмасын иде бүтәннәр.
Түмәрләрне тишеп үсте гыйшкым,
Гөлгә әйләнде җансыз бүкәннәр.
Артык яратканнар артык була,
Тансык була сөяр-сөймәсе.
Артык сөйгәнннәрнең
Тормыш диңгезендә
Бата-калка йөзә көймәсе.
Өметләндем якты киләчәккә,
Кара төннәргә тиң үткәннәр.
Теләгем шул:
Минем язмышыма
Юлыкмасын җирдә бүтәннәр!
Артык яратканнар актык була,
Тансык була сөяр-сөймәсе.
Артык сөйгәннәрнең
Гаилә табынында
Сыек була икән өйрәсе...

***

Еллар түгел,
Гасыр белән хәтта
Үлчәү кирәк минем күргәнне.
Мондый газап нинди гөнаһ өчен
Өлешемә минем тигәнне
Аңлый алмыйм.
Сөйлә, агай, диеп
Сорашасың һаман, әй наным,
Һәммәсен дә тыңлап бетералсаң,
Боз кантары булыр сау җаның.

Караңгы бер каравылчы өе...
Мамык юрган да юк,
Ястык та.
Сирәк кенә барып әйләнәмен,
Алар өйдән киткән вакытта.

Ничә еллар хуҗасыннан башка
Каршылыйлар гөлләр иртәне.
Гөлләр булып,
Агач гөлләр сорый,
Чын ярату сеңгән ир тәнен.

Шуларны бер кайтып сыйпап киләм,

Сипләп киләм койма-киртәне.
Килеп йөргән ире,
Ничек әйтим,
Хәтта...
Танышыбыз иде күптәнге...

Күз яшеңне сөртә-сөртә, үзең
Сөйләтәсең һаман, әй наным.
Күргәнемне тыңлап бетералсаң,
Боз кантары булыр сау җаның...

**4**
Инша,
Инша...
Ничек тәмамларга?
Аптырады тәмам Сөмбелә.
Әтисенең моңсу карашлары
Яфрак-яфрак булып өзелә дә
Аяк асларына тезелә.
Җилдә аумый агач,
Ныклы була,
Тик сәламәт булса үзәге!
Балалар да шулай,
Тик тәрбия җитсә,
Була ала тормыш бизәге.

Ә без кемнәр?
Җавап бирә алмас
Генералша – әни үзе дә.
Яфрак-яфрак сары сагыш булып,
Җанга тия быел көзе дә!..

Ә без кемнәр?
Бер бизмәнме әллә –
Үлчәү өчен
Сөю белән нәфрәт арасын?
Нинди ана калкан итә алыр
Баласының йөрәк ярасын?..

Ә без кемнәр?
Тормыш бизәгеме?
Тизәгеме әллә явызның?
Тәмамлыймын...
Бу иншама
Кайнап торган яшем агыздым!

***

Инша,
Инша –
Сөмбеләнең
Уй-гамьнәре,
Иҗат җимеше.
Үкенечләре,
Үтенечләре белән
Укытучысына сузды ул эшен:

– Укытучым!
Күзләремне ачтың,
Рәхмәт әйтәм Сезгә,
Баш иям!
Гел Сездәйләр янда булса икән,
Мондый булмас иде тәрбиям!..

Укытучым!
Пәйда булганда Сез,
Безнең нәни ферма өендә,
Әтиемнең зәңгәр күзләрендә
Моңсулыкның
Калмый җөе дә!

Укытучым!
Сездәй чиста җанга
Әти минем лаек пар әле!
Тиң яр итсәң,
Ир-хан итсәң,
Йортлар гына түгел,
Шәһәр күтәрерлек
Көч-гайрәте аның бар әле!...

Очратуым Сезне юкка түгелдер, шәт,
Эч серемне салдым иншама.
Җылыналса җаны әтиемнең,
Барысы да
Үз урынына кайтыр...
Иншалла!

*Түбән Кама–Казан,*
*1999–2004*